Флёра Тарханова
Язмышлар язылганда
**Шигырьләр, хикәяләр**
Казан
Татарстан китап нәшрияты
2007

УДК 821.512.145-1:3
ББК 84 (2Рос=Тат)-4:5
Т21

**Тарханова Ф.Г.**

Язмышлар язылганда: шигырьләр, хикәяләр / Флёра Тарханова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 239 б. — 2000 д. — ISBN 978-5-298-01509-7

Җыентыкка авторның күренекле шәхесләр, милләт, кеше язмышын үтәли кисүче аскормага, төрле вәзгыятькә нигезләнгән, шулай ук Көнчыгыш классик лирик поэзиясенең байтак үрнәкләре калыбында язылган өр-яңа лирик-фәлсәфи шигырьләре, чәчмә әсәрләре тупланды.

ISBN 978-5-298-01509-7
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Тарханова Ф.Г., 2007

# Тамырлар

## Тамырлар

Борынгыда калган Болгар илен
Күз алдыма китерәсе килеп,
Гасырларны үтәм уй аша.
Ни дисәң дә, безнең тирән тамыр
Буталчык һәм борма юллар белән
Болгарларга барып тоташа.

Йөзәр генә түгел, меңәр еллар
Аерса да безне тамырдан,
Тарих катламнары арасында
Әллә ничә тапкыр үзгәрсәк тә,
Без барыбер шул ук «камырдан».

Заманында Бөек Болгар иле
Затлы читек, кайнар мунчалары,
Җир астыннан үткән торбалары,
Алтын-көмеш балдак, алкалары,
Чуен кою, суккан акчалары,
Бодай, арпа, тары... басулары,
Төрле балыкларга бай сулары
Һәм башкалар белән танылган.
Табигый ки: моңа сөенүче,
Болгарлардан явыз көнләшүдән
Кара көюче дә табылган.

Колач җитмәс нарат бүрәнәдән

Өелгәннәр шәһәр өйләре.
Имән диварларга сарыла-сарыла,
Шәһәр чикләреннән сызылып үткән
Кыл кубызның моңлы көйләре.
Болгарларда булат кылычларның
Зеңгелдәве киткән еракка.
Афәт килсә, яугир ир-егетләр,
Батыр кызлар кылыч уйнатканнар,
Сикереп менеп җилдәй мең атка.

Ибн Фадлан килгәч Багдадлардан
Зур бүләкләр, зур өмет белән,
Каршы алган аны шәһре Болгар
Икмәк, тары һәм дә ит белән.

Яңа хөтбә дәррәү яңгырагач
Ярларында гүзәл Ителнең,
Ислам иңгән Болгар киңлегенә
Чәчкәле һәм ямьле май аенда
Тугыз йөз егерме икенең.

Ител буе болгар төркиләре,
Кайбер хәзәр, бортас, сувасы...
Ислам динен кабул иткән чакта
Илчеләрне, Ханны, диндарларын
Кочагында ике айлап тоткан
Яушир(мә)нең Ханнар буасы

Тирәләтеп тезгән тирмәләргә
Алмыш патша җыйгач аларны,
Ачыклагач хәләл, хәрәмне,
Янә бер кат яңа хөтбә укылып,
Болгар иле ислам кабул иткән —
Төрле якка атлы чапкын киткән
Кичекмәстән тирә-күршеләргә
Җиткерергә ошбу хәбәрне.

Шул еллардан бирле без — мөселман,
Табынабыз тик бер Аллага,
Йөзебездә балкый иман нуры,
Инкарь итеп булмый: ни дисәк тә,
Мең кат үлеп, мең кат терелсәк тә,
Безнең тамырларда әле һаман
Болгарлардан кергән кан ага.

*2006*

# Тукай язмышы

*Шагыйрьнең 120 еллыгына*

Бу дөньяда белмәгәннәр юктыр
Бөеклеген мәшһүр Тукайның.
Әйтер сүзем бу турыда түгел.
Шигыремдә,
Йөрәк әрнүемне белдерим дип,
Акрын-акрын аның үлеменә

Китерүче байтак сәбәпләрнең
Кайберсенә килеп туктaлдым.

Акылларга сыймас, уйлап баксаң:
Шул ятимне кайсы ныграк баскан —
Рәнҗетүме, әллә каргышмы?
Әллә Ходам шыксыз дөньялыктан
Даһи булып китсен өчен аңа
Бирде микән ачы язмышны?

Йөрәгенә яткан мең җәрәхәт:
Көтмәгәндә әтиләре үлеп,
Әнисеннән кинәт аерылгач,
Идәнендә калып чит бер ятта
Өзелеп-өзелеп сулкылдаган чакта
Канатлары сынып каерылгач.

Бәлки, бүген кайтып алыр, диеп,
Тәрәз саен күз нурларын түгеп,
Көткән чакта газиз әнкәсен,
Уйларына теркәп куйгандыр ул
Кочагына сыенып әнкәсенең
Иң ягымлы сүзен әйтәсен.

Үксезлекне йөкләп татыгандыр,
Карыны ачка, суырылып бетеп,
Күз яшьләре тулып акканда,
Ишек төптә, кертүләрен көтеп,
Бер кат күлмәк аша суык өтеп,
Аяклары бозга катканда!

Калтыранган нәни кулларында
Эзе калган канлы тасма булып
Өтеп алган тимер тотканың.
Күңелендә иблис торды микән,
Бәгырьләре таштан булды микән,
Бетсен, диеп, үлем теләп йөргән
Миһербансыз шушы кортканың?

Өстәвенә салкын бер иртәдә,
Алып китеп шәһри Казанга,
Шыңшып яткан бер эт баласыдай,
Сатып җибәргәннәр базарда.

Сикәлтәле юлны үткән чакта,
Каршы җилдә ничек сүнми калган
Ышаныч һәм өмет учагы?
Орчык хәтле генә шул сабыйны
Җылытмаган хәтта туганнары,
Авылының, аны үксез күреп,
Үги иткән салкын кочагы.

Ни кызганыч:
Борынгыдан күчкән хакыйкать бар —
Туң йөрәктән килгән явызлыклар

Һәр заманда талант иясенең
Язмышына үтеп кыйнаган.
Рәхим-шәфкать җирдә күбрәк булса,
Хезмәте һәм зирәк акылы белән
Бөеклеккә күтәрелгән Тукай,
Утызын да тутырмаган килеш,
Китеп бармас иде дөньядан.

*2006*

## Җәлил

*Сугыш елларында үз җиреннән сөрелергә дучар ителәсе булган Казан т а т а р л а р ы М у с а Җ ә л и л һ ә м а н ы ң көрәштәшләре геройлыгы ачыклангач кына депортацияләнми кала.*

### I. Татарлар

Шовинизм сөреме козгыннары,
Төрле сәбәп табып,
Милләтемне
Сөрер иде дөнья йөзеннән,
Тик татарның чиксез батырлыгы
Әйләнә дә кайта тора һаман
Шәһит киткәннәрнең эзләреннән,
Герой шагыйрь Муса эзеннән.

Әйт син миңа: бармы башка милләт
Бер дистәгә якын шагыйренең
Фашист тоткынында бер үк көнне
Бер-бер артлы башы чабылган,
Төрмәләрдә язган шигырьләре
Төрле илдән, төрле юллар белән
Күп еллардан соң да табылган?

Юк! Булмас та! Чөнки татарларда
Халкы өчен көю,
Туган илен сөю көчлерәк.
Тылда калу зур батырлык түгел,
Беренчеләр булып ут эченә
Керү өчен гайрәт, көч кирәк.

### II. Йөз аклыгы

Үлем балтасына башын куйгач,
Йөгерек уйларында Муса Җәлил
Газизләре һәм дуслары белән
Бер хушлашты, янә күреште...
Сагыш булып гөрләп аккан каны,
Чоңгылларны ашып, үз халкына
Моңлы җырлар булып иреште.
Шушы җырлар, көчле ташкыннардай,
Җиткерделәр данын иленә.
«Татар — сатлык» диеп көлгәннәрнең
Үткен хәнҗәр сыман кадалдылар
Агу чәчеп торган теленә.

Яман сүзен кисте, меңгә турап,
Милләтемнең
Йөзен каралтасы килгәннең,
Татар гаярьлеген санга сукмый
Ил-җиреннән сөрдерергә теләп,
Кара мөһер сугып йөргәннең.

Сатлык булып түгел,
Хаклык булып
Кайтты Җәлил Алман ягыннан.
Әйтерсең лә, башын салган чакта,
Милләтеңне, илең акла, диеп,
Фәрештәләр килеп кагылган.

Йөрәкләргә сеңеп, уелып калсын
Алишларның,
Зиннәт Хәсәннәрнең, Кормашларның,
Җәлилләрнең... каһарманлыгы,
Илнең Геройлары арасында
Курку белмәс,
Даны мәңге үлмәс
Меңәрләгән татар барлыгы.

*2006*

# Пәйгамбәрләр кебек...

*Композитор Ф.Әхмәтов*
*истәлегенә*

Бер яше дә тулар-тулмас аңа
Язмыш салган йөрәк ярасы.
Күрәчәген яшьли күрсен, диптер,
«Халык дошманы»ның баласы.

Тәпи басып атлап китәр чакта
Йөрмәс иткән кинәт ул аны.
Унбиш яшькә кадәр кагылмаган
Җир өстенә аяк табаны.

(Әмма табигатьтә бар тигезлек:
Берәр ягың зәгыйфь булганда,
Башка якны ясый көчлерәк,
Тик аны да кабул итәр өчен
Үзеңнән дә шактый көч кирәк.)

Дистә елдан артык шуышып кына
Йөргән бала гайрәт, көч табып,
Аягына басып туры киткән,
Култык таягына таянып.

Гаделсезлек, рәхимсезлек белән
Гомер буе ялгыз көрәшеп
Эзләп тапкан биек бөеклекне,
Юл үткәндә җанын өләшеп.

Салих Сәйдәш, Фәрит Яруллиннар
Моңнарыннан килгән сихрилек
Бер этәргеч булган алга таба
Яшәп китәр өчен иң элек.

Иңнәренә баскан газаплардан
Бәреп чыккан хисе, ялкыны
Симфония, җырлар булып яткан
Йөрәгенә татар халкының.

Хөсеткә юл куймый, хәтта Мәскәү
Хезмәтенә күрә түләде.
Зур талантны танымаганнарга
Аяз көндә яшен кебек булды
«Фәрид...» өчен Глинка бүләге.

Кешелеккә «Аккошлар»дай очты
Милли моңнар татар улыннан.
Үз чорында, пәйгамбәрләр кебек,
Миссиясен үтәп китеп барды
Язмыш сызган авыр юлыннан.

*2005*

# Яшә, халкым!

*Казанның 1000 еллыгына*

Күпме милләт, күпме халык
Ирек даулап башын салды.
Яу кырында тураклашып,
Тарихлардан төшеп калды.
Кылычлардан кыелса да,
Горур халкым тез чүкмәде.
Күтәрелде, үргә менде —
Якты киләчәген күрде,
Явызлык юлын чикләде.

Кушымта:

Газиз халкым, мәңге яшә!
Тарихларда калган буын
Сине көрәшләргә дәшә.
Яңа гасырларга күчеп,
Чиксез бөеклеккә үсеп,
Яшә, халкым, мәңге яшә!

Имин тормыш алып килсен
Аткан һәр таң, һәр көнебез.
Даны җиһанга таралып,
Күкрәп яшәсен илебез.
Көтә халкымны сынаулар —
Барын да җиңеп үтәр ул.
Киртә булмас авырлыклар:
Илебезне яшь көч белән
Дус милләт йорты итәр ул.

Кушымта.

*2004*

# Башланмасын иде набаттан

*Бөек Ватан сугышында Җиңү*
*яулаган ватандашларга*

Канлы дәһшәтләрдә җиңгән көннән
Дистәләгән еллар үткәндә,
Шул вәхшәтнең кара кайгысына
Уралган йомгакны сүткәндә,
Ватан өчен утка кергән яуны,
Фашистларны кырган гаярь җанны
«Очратабыз» сугыш кыры буйлап
Солдат юлын урап киткәндә.

Шул юлларда тирән яра алды,
Чит туфракта мәңләп ятып калды
Илне саклап башын салганнар.
Дошманны үз оясына кертеп,
Тамырына хәтле утта өтеп,
Кайтты Ауропаны азат итеп,
Җирнең астын өскә әйләндергән
Гарасатта исән калганнар.

Җиңү яулап биргән өчен безгә —
Теләкләрнең иң изгесе Сезгә:
Яу кырында калган сәламәтлек,
Капкалардан керми узган бәхет
Кайтсын иде, кайтсын кабаттан.
Киләчәкнең туар бер көне дә,
Йолдызлы һәм айлы бер төне дә
Башланмасын иде вәхшилектән,
Башланмасын иде набаттан.

*2005*

# Көзге урман

*(Этюд)*

Көзге урман хозурында ял иткәндә,
Табигатьнең илаһи бер сәләтенә
тап булдым мин:
Иңнәренә иңнәр куеп, дивар ясап
сыенышкан агачларның
Җәйнең нәфис гөлләредәй балкып янган
Яшел, кызыл, алтын-сары яфрагына
Хәйран калып, сокланып карап тордым мин.

Гаҗәп бер хәл: яшел чыршы куенында
Төз буй-сынын саклап калып
корыган бер серле каен,
Яшерергә теләгәндәй шәрә калган ботакларын,

Ап-ак җептән өрфә челтәр ябынган да,
Гүзәлләрнең гүзәленә әверелеп,
Үлемсезлектә калуның тапкан җаен.

Һаман яшел үләннәрнең өсләрендә
Баскан саен чыштыр-чыштыр килеп торган
яфрак-палас
Көзге урман матурлыгын мактый-мактый
җырлый төсле,
Күңелләрне дәртләндергән әлеге җыр
Сайрар кошлар моңнарына кушыла да
Гүзәллеккә тагын бер мәдхия өсти.

*1995*

## Вәхшилек

*Россия телевидениесеннән балаларын фәхешлеккә, аерым әгъзаларга саткан аналар турында тапшыру карагач.*

Йөзләренә сары сагыш сарган
Сигез-тугыз яшьлек кыз бала,
Бу газаптан килеп коткарыр дип,
Тилмерепләр үз әнкәсен көтә —
Күзләреннән канлы яшь тама.

Белми шул ул шушы газапларга
Үз анасы гына салганын.
Чит-ятларга ияреп китәргә дә
Риза булган, газиз әнкәсенең
Тыңлый-тыңлый матур ялганын.

Бала сатып, байлык җыйганнарны
Ана диеп әйтеп буламы?
Бәгыреннән өзелеп төшкән җанны
Долларларга алыштырып кына
Төпсез нәфесләре туламы?

Фәхешлектә йөреп акылын җуйган,
Акча колы булган вәхшиләр,
Балаларын шушы юлга атып,
Өстәвенә, әгъзаларга сатып,
Үз баласын «ашап» яшиләр.

Бу аталар нигә миһербансыз,
Бу аналар нигә бәгырьсез?
Бөтен тормышлары — вәхшилектә,
Яшәүләре киткән гел ireккә —
Балалары шуңа кадерсез.

«Демократия» дип җәелеп китеп,
Комсызларга яман көч бирдек.
Бандитлык һәм азгынлыкны татып,
Калигула заманына кайтып,
Илдә каннибаллар үстердек.

Бу ни дөнья? Кая барабыз без?
Чын адәми затлар, кайда сез?
Дилбегәне кулга алмасагыз,
Ил тормышын җайга салмасагыз,
Бу турыда күпме аһ орсаң да,
Җиһаннарга чыгып кычкырсаң да,
Елап илерсәң дә файдасыз.

Ник күрмисез шушы вәхшилекне,
Йөрәгегез ничек әрнеми?
Канечкеч, рәхимсез ерткычларга
Сатылган шул җаннар арасында
Сездән туганнары әзмени?

Мескен илем! Вөҗданыңны сатып,
Ник бу кадәр түбән төшәсең?
Күп гамәлләр киртәләргә сыймый:
Кайчакларда, һич тә тайчынмыйча,
Үз каныңны үзең эчәсең.

Янә шундый берәр ил бар микән —
Төрле яшькә җиткән аналары
Үзе тапкан газиз балаларын
Үтергәнче кыйнап ташлаган,
Әгъзаларга туракларга биргән,
Бетсен, диеп, чүплекләргә күмгән,
Фәхешлеккә сатып «ашаган»?

Акылларга сыймый бу вәхшилек.
Югыйсә бит
Өченче мең елны вакладык.
Тик әхлакка кайтасы урынга,
Йөзебезне буяп гел корымга,
Кабат таш гасырга атладык.

*2006*

# Этләр

*(Мәсәл)*

Кара эт баласе — ак эткә.
*Мәкаль*

**I. Өйләр тулды явыз этләр белән...**

Бу тормышны күптән күзәтеп киләм —
Ушны алган әллә ниләр күрәм:
Төннәр кайный, көннәр — бераз сүрән,
Бик күпләрнең җаны, рухы үлгән,
Кеше хакын ашап йөргәннәрнең
Тамагы тук, урыннары — түрдән,
Үчен алмый калган көчсезләрне
Торгызалар кайчак хәтта гүрдән.
Өстәвенә (күбесен танып беләм)
Урам тулды, хәтта өйләр тулды
Бер сәбәпсез ташланырга торган
Күзе тонган явыз этләр белән.

Элек сирәк иде мондый ерткыч —
Нык күбәйде соңгы дистә елда.
Бар гамәле — тайгак кыек юлда.
Бер ишләре «туксан тугыз» булса,
Кайберләре мескен марионетка
Канга баткан юан, йөнтәс кулда.

Шаккатмалы хәлләр: «курчак этләр»
Ишләренә хәтта өреп тора,
Алдар өчен мәкер, хәйлә кора,
Әйтерсең лә бик зур эшләр кыра.
Җиңә калса, муеннарын бора,
Киртә булса юлда, һич аямый,
Башы белән диварларга ора.

**II. Таң сызылып аткач, җан биргән...**

«Мин кем?!» диеп йөргән шундый бер эт,
Чын асылын яшереп, гомере буе
Этлек кылды «дусты» Ак euкә.
Койрык кысып, үзе аның арттан
Өстерәлде, әгәр ул булмаса,
Төшеп бетә иде иң төпкә
(Шул гадәте өчен кайчакларда,
Иш күргәне аны якласа да,
Бүтәннәрдән алды мең типкә).

Умырып алыр теше тулмаганга,
Бәреп куар кеше булмаганга,
Үзе ияреп йөргән шәригына
Канечкеч бет булып кадалды.
Теләсә кайда аунап арганнан соң,
Көн дә килеп, аның канын суырып,
Үзенә көч җыйды, хәл алды.

Шулай түзә торгач еллар буе,
Җир җимертеп чабып йөргән Ак эт
Акрын-акрын җуйды дәрманын.
Аяклары сүз тыңламас булды,
Күңеленә шик-шөбһәләр тулды —
Баш күтәрер хәле калмады.

Беркөн килеп янә бу канечкеч,
Соңгы канын суырып Ак этнең,
Төнгә каршы аны ташлап киткән.
«Үлсә үләр, калса калыр, — диптер, —
Беркемгә дә хәзер кирәге юк,
Моның канын инде күп эчтем».

Авыр хәлдә ятып калган «дусты»
Ишек төптә, бөтен көчен җыеп,
Ярдәм сорап шактый күп «өргән».
Кара үлем белән нык тартышып,
Бусаганы тырнап елый-елый,

Таң сызылып аткач, җан биргән.

**III. Явызлыгы китте артык күпкә...**

Иртәгесен җирбит әбүҗаһил
Килеп җиткән,
Калыйм диеп ярап,
Үзен бик тә якын дуска санап,
Җинаятен башкаларга «ямап»,
Гаепсезгә гаеп ташлап, янап.
Ә бит юкса үз гаебен белеп,
Ярлыкавын сорап, гафу ит, дип
Өреп-өреп куйды, читкә карап...
Эшне белгәннәрнең, моңа рәнҗеп,
Бәгырьләре торды сыкрап, канап.

Бу хәлдән соң астыртын гуҗ этне,
Дошманнан да болайрак күреп,
Үз дуслары тибәрделәр читкә,
Йөрәкләрдә — ачу белән үпкә.
Башка чыдап булмас бу этлеккә —
Явызлыгы китте артык күпкә...

**IV. Этләр өрә, белми көнне-төнне...**

Кызганыч ки,
Бар дөньябыз шундый хәлгә килде —
Урам тутырып йөргән комсыз этләр,
Башка басып, югарыга менде.
Ни хикмәттер: күтәрелгән саен,
Кайберенә төрле зәхмәт иңде.
Затлылары ярлыланды, бөлде,
Намус, вөҗдан яраксызга килде.
Аек акыл каһкаһәләп көлде:
Аклап була микән инкыйлабны,
Барысын тигезлим дип биргән антын,
Үзенең халкын канга күмгән илне?
Бар да кире кайтты алып өнне —
Этләр өрә, белми көнне-төнне...

*2006*

# Сандугачлар мине юата*

Синсез генә хәзер кояш бата,
Синнән башка гына таң ата.
Сандугачлар җыры — җанга дәва:
Сине генә сөйде,
Бары син дип көйде,
Дия-дия мине юата.

Җәйләр үтте, көзләр, кышлар китте,
Инде кабат кердем язларга.
Сандугачлар бәгырьләрне телә:
Кайта алмый аннан,
Өмет итмә һаман —
Килмәс инде, күммәс назларга.

Хәсрәт калды, үкенечләр калды,
Әйтер сүзләр калды телләрдә.
Сандугачлар җыры сагыш өсти:
Искә төшереп ярым,
Кайтаралар тагын
Без бәхетле булган көннәргә.

*2006*

## Саба юлы*

Карлар китү белән
Яткач яшел киләм,
Гөлгә күмелә Саба яклары.
Шушы гүзәллекне
Кабат күрер өчен,
Күптән таныш юлдан атладым.

Кушымта:

Саба юлы — көзге,
Кавыштырды безне:
Сөенечләр тулды күңелгә.
Авылымның яме,
Суларының тәме
Калсын иде гомер-гомергә.

Ара ерак — талдым,
Утырып хәлләр алдым
Өй каршында үскән чирәмгә.
Йөгереп чыкты күреп,
Йөри бөтерелеп
Әти-әни минем тирәмдә.

Кушымта.

Сагыш сарган чакта
Кайтам туган якка,
Күз яшемне юлда куз итеп.
Яшел урамнарым,
Кырлар, урманнарым
Каршы ала мине үз итеп.

Кушымта:

Саба юлы — көзге,
Кавыштыра безне:
Сөенечләр тула күңелгә.
Авылымның яме,
Чишмә суы тәме
Калсын иде гомер-гомергә.

*2006*

## «Дөнья матур, дөнья киң...»

*(Уены-чыны бергә)*

И тартыша соң берәүләр:

Зур бәйге — туган һәр көн.
Уйлыйдыр: «Мин кемнән ким соң?
Әле күпләр миннән ким».
Моңа карап ниләр диим,
Моны күреп ни әйтим? —
«Дөнья матур, дөнья киң...»

Һич туймас нәфес юлында
Алар арысланга тиң.
Курыкмый хәтта алырга
Зәхмәтен вә ләгънәтен.
Моңа карап ни диим соң,
Моны күреп ни әйтим? —
«Дөнья матур, дөнья киң...»

Әллә ни эш кырмаса да,
Аннан файда булмаса да,
Баш — югары, күкрәк — киң,
Чынлап та, ул кемнән ким?
Моңа карап ни диим соң,
Моны күреп ни әйтим? —
«Дөнья матур, дөнья киң...»

Гаделлек саклап йөргәннәр
Авызын ачып торганда,
Ертлачлар хәйлә корганга,
Малыннан кала ятим.
Моны белеп ни диим соң,
Моны күреп ни әйтим? —
«Дөнья матур, дөнья киң...»

*2006*

# Син сәфәргә янә җыенасың

Син сәфәргә янә җыенасың —
Яңартасың моңлы чагымны,
Бусагадан әле чыкмагансың —
Ә мин инде үлеп сагындым.

«Озакламам!» — диеп кысып кочтың,
Тәнең уты мине төргәнче,
Шул ялкының тагын саклап тотсын
Син әйләнеп кайтып кергәнче...

Сәфәреңә янә чыгып киттең —
Эзләреңә кабат табынам,
Көзгеләрдә калган йөзләреңә
Керфекләрем белән кагылам.

*2000*

# Үтә гомер

Күршем безгә бер хикәят сөйли иде,
Мут күзләрен хәйләкәрлек илә кысып.
Яныбыздан, аксый-туксый, көч-хәл белән,
Үтте кортка, сулы кувшиннарын тотып.

Аны күргәч, күршем сөйләр сүзен бүлде —
Ихтыярсыз аның арттан ияреп киткән
Күз карашы туктап калды, җитеп чатка.
Аннан кинәт әкрен генә әйтеп куйды:
«Бигрәкләр дә чибәр иде, һай, яшь чакта!»

*Рәсүл Гамзатов*

Әле кайчан гына,
көянтәләр асып,
Суга йөри идек чишмәгә.
Каршыбызга чыккан егетләрнең,
Чиләкләрне кулларына алып,
Дәррәү күтәрешеп кайтулары
Керми хәзер хәтта төшкә дә.

Үтә гомер —
без дә гел икенче:
Аксамасак, кайчак туксыйбыз.
Йөрәк җилкендергәч, онытылып,
Яшь чактагы кебек йөгереп китсәк,
Тын кысылып, кинәт туктыйбыз.

Йөзебез дә нык үзгәрде хәзер —
Олыгая барган битебезгә
Элеккечә ефәк япмаган.
Күзләр әле нурын сакласа да,
Тирәләрен челтәр каплаган.

Нинди көчле асыл егетләр дә
Үзгәрделәр, бездән калышмый:
Ап-ак чәчләр, буразналы йөзләр
«Исәнме?» дип сорау биреп китә,
Гомерләрен узып барышлый.

*2006*

## Фатыйх Нурлатының икмәге

*Алты ел буе икмәк уңышы буенча*
*беренчелекне тоткан Нурлат*
*хакимияте башлыгына*

Бер тамчы тир тамган җирдә хәтта
Гөрләп үскән ашлык,
Берәмтекләп түгел, көлтәләп.
Өстәвенә, таң нурына кушып,
Һәр көн саен йөргәч син аларны
Күз нурларың белән иркәләп.

Көн җылысы гына түгел икән,
Җан җылысы кирәк ипигә.
Шуны белеп, дәрт һәм дәрманыңны
Син бүләсең һәрчак икегә.
Бер өлеше калса гаиләңдә,

Икенчесен ала басулар.
Тук башакның һәр бөртеге саен,
Синнән күчкән көчле ярсу бар.

Юкса болай котырып уңмас иде
Фатыйх Нурлатының икмәге.
Ул гынамы?
Торган саен уңыш арта бара,
Гаҗәп хәл бит — исең китмәле.

Халык та бит синдә бигрәк уңган,
Кемгә карап ялкау булсын ул?
Җитәкчесе ут уйнаткан чакта,
Кул кушырып ничек торсын ул?

Бүген исә нәтиҗәсе шуның —
Синең Нурлат
Беренчегә чыкты быел да.
Илдә-көндә муллык һәм хозурлык —
Нурлат гөрли уңыш туенда.

*2006*

# Юллар буйлап китте тик уйлар

Тезеп салдым яшьлек фотоларын —
Шул елларга юллар ачылды.
Миңа карап торган таныш йөзләр
Җан тынычлыгымны качырды.

Сузылса да юллар яшь гомергә,
Алар буйлап китте тик уйлар.
Бар нәрсәгә ышанып йөргән чакта
Безне җилкендергән «яшьлек йорты» ,
Еллар узгач, кайтып кералмаслык
Кальга булыр диеп кем уйлар?

Бер генә сүз әйтсәгезче, диеп,
Фотоларга кергән һәрберсенең
Күзләренә багам инәлеп.
Беркем дәшми, бары елмаялар,
Юксынудан күңеле мөлдерәгән
Мине «күргәненә» кинәнеп.

Яшьлегемдә бергә йөргәннәрнең,
Бергә елап, бергә көлгәннәрнең
Кайберләре төрле сәбәпләрдән
Китеп барды ташлап дөньяны:
Кемдер бандитлардан үлем алды,
Кемдер Әфганнарда башын салды.
Ә бит әле исән калганнар да
Бер генә дә яшәп туймады.

Кушылалмый калган яшьлек ярым,
Тормышыма дөрләп кергән парым —
Сез дә юк бит. Инде кайда сез?
Югалттым мин күптән үзегезне,

Таба алмыйм хәтта эзегезне —
Әллә Җирдә, әллә Айда сез.
Эзләсәң дә хәзер — файдасыз.

Сихерләнеп карыйм фотоларга:
Әти-әни, якын туганнарның,
Ахирәт һәм таныш булганнарның
Япь-яшь йөзе калган сурәттә.
Минеке дә калыр. Ходай кушса,
Мине белгәннәр һәм якыннарым,
Сагынып куйса, карап искә алыр,
Яшьлегенә кайткан сурәттә,
Вакыт җитеп, мине газиз Аллам
Үз янына алган сурәттә.

*2006*

## Әни

Һәр көн саен нурлы йөзең күреп,
Безнең күңелне дә нур баса.
Җаныбызга урын табалмыйбыз,
Күзеңнән наз сибелеп тормаса.

Көннәребез һәрчак матур безнең
Син гел көләч һәм сау булганда,
Йөргән юллардагы һәр эзебез
Догаларың белән тулганда.

Мең-мең рәхмәт, әни, барысы өчен! —
Без дә сиңа изге теләктә.
Син бит һәрчак безнең җаныбызда,
Син бит һәрчак безнең йөрәктә!

*2005*

## И әнием!

И әнием!
Яннарыңа кайткан саен гел ашыгам —
Бу юлы синең яныңда бераз гына онтылыймчы:
Бер читкәрәк этеп куеп мәшәкатьне,
Кызың булып кына эреп утырыймчы.

И әнием!
Дөнья гаме вакытымны бик нык били —
Әниеңнең эргәсендә озак итеп яшә дими —
Торып булса, иң күбесе ике-өч көн,
Хәтта туган-тумачага вакыт тими.

И әнием!
Рәнҗеп калма яныңнан чыгып киткәнгә,
Синнән аерып ала торган эш көткәнгә.
Мин үзем дә эчтән янам, урын тапмыйм,
Үпкә тулы карашың мине өткәнгә.

*2006*

## Сауллармы сез, газиз милләттәшләр!

*Финляндиядән кайткач*
*язылган сәлам хаты*

Сауллармы сез, газиз милләттәшләр,
Имин генә яшәп ятумы?!
Инде сагындык та Хельсинкины,
Аеруча Фридрих катуны.

Шушы урамдагы изге мәчет
Берләштерә татар милләтен.
Иман шартын тоткан кеше генә
Яхшы белә яшәү кыйммәтен.

Тормышыгыз матур икән, шөкер!
Сокландырды һәрбер гаилә.
Гаҗәп игътибарлы мөнәсәбәт
Иң борынгы буыннан килә.

Ни дисәң дә, алар рухы белән,
Алар исеме белән яшисез.
Ихтирамга күмеп искә ала
Нәсел башын карты-яшегез.

Төркән, Өлкән — Абдулла Алилар,
Айнур, Ирхан һәм дә Җәмилә,
Гөлтән, Айтән, Фидә, Окан, Рахил,
Раиф, Әнвәр, Гүзәл, Фәридә... —

Һәрберсенең тормыш дилбегәсе,
Чыганагы үзенең кулында.
Бөтен көче хезмәтенә китсә,
Җаны фида милләт юлында.

Күтәргәнсез милли байрак итеп
Туган тел һәм милләт зурлыгын:
Мәңгелеккә күчкән затлы буын
Күпләп чәчкән «уңдырышлы җиргә»
Горурлык һәм әдәп орлыгын.
Күңелләрне, рухны сафландыра
Сездәге иң күркәм сыйфатлар.
Сезнең белән җан савыга, чөнки
Һәрбер сүзегездә сихәт бар.

Туганнан да ныграк артык күреп,
Бирдегез сез бөтен рәхәтне.
Дәррәү килеп елап озаттыгыз —
Барысы өчен чиксез рәхмәтле,
Барыгызга да мең-мең рәхмәтле!!!

Сау торыгыз, газиз милләттәшләр,

Йөзәр яшькә җитеп кимендә.
Капка ачык Казан каласында —
Күрешү язсын татар илендә,
Бер күрешик милләт җирендә!

*2005*

## Ирхан белән Җәмилә

Ярвинпә дигән калада
Яши бер яшь гаилә.
Исемнәре дә бик матур —
Ирхан белән Җәмилә.

Музыка, җыр тавышыннан
Өйләре шау-гөр килә.
Үрнәк булып яши белә
Ирхан белән Җәмилә.

Дөньяларын бөтен итеп,
Өч угыл үсеп килә.
Өзми нәсел дәвамлыгын
Ирхан белән Җәмилә.

Күңел киңлеге һәркемгә
Бәхет-шатлыктан килә —
Тормышыгыз имин булсын,
Ирхан белән Җәмилә!

*Финляндия, 2005*

## Бала зары

*Ана назын күрми үскән,*
*интегеп яшәүче бала зары*

Яшәвемнән арып китәм кайчак,
Тәртибе юк кылган эшемнең.
Һәр гамәле акланырга тиеш
Җир йөзенә килгән кешенең.

Кушымта:

И әнкәем, нигә сабый чактан
Өйрәтмәдең мине тәртипкә?
Син күрсәткән булсаң гадел юлны,
Китмәс идем яман кәсепкә.

Бишек җырың тыңлап тирбәлмәдем,
Ана назын күрми үстем мин.
Кочагыңа алып бер сөймәгәч,
Урам кочагына күчтем мин.

Кушымта:

И әнкәем, нигә күңелемне
Иман белән назга төрмәдең?
Йөрәгемдә шәфкать булмаганга,

Мин тормышта рәхәт күрмәдем.

Бала чактан син өйрәткән булсаң
Һич югында изге бер дога.
Язмышымда бер нур булыр иде —
Төшмәс иде миңа бәддога.

Кушымта:

И әнкәем, хаклык, миһербанлык
Сеңдерәсең калган каныма —
Мин йөрермен хәтта җиһаннарда,
Урын табалмыйча җаныма.

Кабатлау өчен:

И аналар! Газиз балагызны
Этәрмәгез урам чатына.
Тәрбиягез һәрчак туры килсен
Аллаһ сүзе — иман шартына!

*2005*

# Фин җирендә кабат җырлый Хәйдәр

Фин җирендә кабат җырлый Хәйдәр,
Йөрәгеннән алып моңнарын,
Очрашуга килгән һәр татарның
Зар елатып күңеле кылларын.

Фин татары чыккан Нижгар ягы —
Туган җире Хәйдәр Бегичнең.
Җырчылар бар ике төбәктән дә,
Тик моңарчы әле беркайчан да
Булганы юк иде беришнең.

Ваһапов һәм Раиф Низаметдин —
Милләтебез даны, сүз дә юк.
Әмма Хәйдәр кебек абруйлысы
Әле һаман илдә-көздә юк.

Хәйдәр җырлый үзәкләргә үтеп,
Кушыла кайчак аңа Зөһрәсе.
«Җәлил», «Герман»,«Отелло»сы белән
Тагы да арта Хәйдәр шөһрәте.

Җырлый Хәйдәр, киң күкрәген киереп,
Әйтерсең лә эчтә янган уттан
Иреннәре чатнап кипмәгән,
Йөрәкләре туктап, бер мизгелдә
Дөньялыкны ташлап китмәгән.

Агылып килде халык, ишетүгә
Кабат аның «кайту» хәбәрен.
Моңга сусау могҗизалар тудыра,
«Киткәннәрне» гел кайтарып тора —
Мир онытмас үзенең Хәйдәрен!

*2005*

## Исеңдәме?

Исеңдәме, миңа унбиш яшьләр,
Ә син инде җиткән ир-егет.
Очраштык без шушы көллияттә,
Бер күрүдә назлы ике күңел
Бер-беренә калды берегеп.

Җиткән кыз булырга тырышсам да,
Балалыгым әле чыкмаган.
Син әйткән һәр сүзне көтеп алам.
Булмагандыр сүзең, хәрәкәтең
Йөрәгемдә саклап тотмаган.

Исеңдәме: бии, җырлый идем,
Ә син баяныңда
Уйный идең, юри котыртып,
Кичләр буе фото ясый идең,
Алларыңа мине утыртып.

Син укуны алдан тәмамладың,
Китеп бардың Алман ягына.
Күпме хат языштык, саф сөюне
Куша-куша һәр сүз янына.

Гади генә кебек хат эчендә
Сүз аралаш — үлеп сагыну,
Тик икебез тоя ала торган
Бер-беребезгә сүзсез табыну.

Язмыш үзенчәләп язган икән:
Безне кабат кавыштырмады,
Син узачак гомер юлларына
Минем юлны ябыштырмады.

Әмма калды күңел төпкелендә
Сиңа булган матур, саф хисем.
Һич шикләнмим: яшьлегеңә кабат
Бер кайтарыр әле бу исем:
Флёра Тарханова —
Яшьлеккә кайтарыр бу исем.

*2005*

## Гаҗәп якын идең...

Яшьлегемә кайткан кебек булдым,
Күзләреңдә очкын күргәч тә,
Янәшәмә утырып сөйләшкәндә,
Тән җылыңа мине төргәч тә.

Гаҗәп якын идең шул минутта,
Элеккечә хисләр берләште,

Ничә еллар күрешмәгән җаннар
Бер-берләрен сагынып серләште.

Иркәләнде күзләр карашында
Үбү көткән кайнар иреннәр.
Тик... ярсу көч кинәт тыелып калды,
Бәгырьләрне өтеп, суык алды —
Араларга сарды сөремнәр:
Чынбарлыкка кайтты күңелләр, —
Кушылалмый калды иреннәр.

*2006*

# Дуслар булып калыйк гомергә

Сагынып көткәнеңне шундук сиздем:
Йөгереп чыгып каршы алуың,
Көттергәнгә кәефең булмаса да,
Бер сүз әйтми тыелып калуың —
Бар гамәлең шуны сөйли иде,
Җаның сагыну көен көйли иде.

* * *

Кунак иттең мине, елак иттең:
Көчкә тыйдым күңел яшемне.
Тик, бер генә җан да сизмәсен дип,
Мин ул яшьне төпкә яшердем —
Булдырмыйча калдым кинәт кубып,
Дулап килгән давыл-яшенне.

* * *

Онытмадым сине, онытмам да —
Син бит минем тәүге ярымсың,
Язмышларда кушыла алмаганга,
Миннән аеры йөргән парымсың.

* * *

Беләсеңме:
Кырык еллык кайбер фотоларны
Зәңгәр бәрхет тышлы альбомнардан
Алып ташладым мин, искергәч.
Фотоларның инде яңаларын,
Элеккечә алларыңа утырып,
Ясар идем көн дә кич кергәч.

* * *

Тәвәккәллек җитеп бетмәгәндер,
Кулларыңа кунган асыл кошны
Тотып калалмадың син шуңа.
Хәзер менә яшьлек кайтавазы
Ераклардан урап-бурап килгән
Бер моң булып йөрәккә тула.

* * *

Син гаепле, мин гаепле, диеп,
Яра салмыйк әле күңелгә.
Аны эзләр өчен вакыт беткән,
Шуңа күрә
Бер-беребезгә үпкә тотмый гына
Дуслар булыйк соңгы гомердә,
Дуслар булып калыйк гомергә.

*2006*

## Ике Аккош

*Җәвит һәм Зөлфия*
*Шакировларга*

Сәхнәләрдә йөзә Ике Аккош —
Бер-берендә назлы күзләре.
Моң дәрьясы ташкынында туган
Җырларында әйтер сүзләре.

Бәгырьләрдән төшкән җыр-моңнары
Халык йөрәгенә юл алды.
Милләтенең сөю дулкынында
Җиһаннарга китеп таралды.

Каурый-каурый очкан бу авазлар
Сихәт булып җанга яттылар.
Яраталмый йөргән йөрәктә дә
Дөрләп торган учак яктылар.

Сәхнәләрдә йөзә Ике Аккош,
Бормаларны үтә ашыкмый.
Гомере озын, бәхете тулы булсын
Ике Аккош — ике гашыйкның.

*2007*

## Исеңнән чыгарма берүк

Сагындым сине, кадерлем,
Үлеп сагындым сине.
Китү-кайтуларың белән
Сыныйсың мәллә мине?

Көн дә көтәм ишегемнән
Йөгереп кергәнеңне.
«Ни хәлдә тордың, Гөлчәчкәм?
Кайттым мин», — дигәнеңне.

Сагынуым күңелемне
Кылдан да нечкә итә.
Сине эзләп нечкә күңелем
Эзләрең буйлап китә.

Син җанымның һәм тәнемнең
Бер кисәге икән бит.
Эчкерсез ярату белән
Яратамын икән бит.

Җан гына түгел, тән сыкрый
Син янымда юк чакта.
Тынычлап калам бары тик
Синең генә кочакта.

Оныттырма берүк миңа
Күзләреңнең төсләрен.
Юлларда югалып торсаң,
Синнән башка нишләрем?

*2006*

## Якташым

*(Экспромт)*

Галиәсгар театры
(Мин моны шәхсән беләм)
Ике дистә ел эчендә
Гаҗәп зур абруй казанды
Шамил Зиннурыч белән.

Ул тырышса, артистларның
Өсте бөтен, тамак тук,
Чөнки данлы театрның,
Халык мәнфәгатен яклап,
Милли рухыбызны саклап,
Йөрмәгән бер җире юк.

Зурдан кубып үткәрә ул
Исхакый укуларын.
Идел ярларына чыгып,
Милләтебезгә тарата
Салих Сәйдәш моңнарын.

Бармы карар, юкмы карар —
Аның анда эше юк.
Эшлим дисә, ду китерә —
Ни үзенә, ни сүзенә
Буйсынмаган кеше юк.

Шуңа Шамил Зиннурычны
Хөрмәтлиләр һәр җирдә.
Бар белгәне — дөрләп китү
Һәм дәртләнеп хезмәт итү
Үз халкына һәм илгә.

*2005*

## Сигез дистәң тулган көннәрдә

Хатирәләр дәрьясына чумып,

Йоклый алмый яткан төннәрдә
Истәлекнең тик яктысы күчсен
Сигез дистәң тулган көннәргә.

Хәсрәте дә, дәһшәте дә калсын
Хәтер сандыклары төбендә.
Янып торсын бары бәхет, шатлык
Йолдыз булып тормыш күгеңдә.

Алтыннардан сарай салмасаң да,
Корган ояң гаҗәп бай булды:
Өең тулды бала-чага белән,
Бишек җыры белән өй тулды.

Күпме еллар үтте. Әле дә булса
Һәрбер балаң өчен янасың.
Хәзер инде бары оныкларда
Күңел тынычлыгы табасың.

Хафаланма, гомер узды, диеп,
Искә төшкән саен яшьлегең.
Сигез дистәң тулган көннәрдә дә
Җаның әле һаман яшь синең.

*2005*

## Күңелеңдә ярату белән наздыр

*Наилә апага*

Синнән дә ачык күңелле
Бер кеше дә тапмадым.
Кайгы-хәсрәт килгәндә дә,
Дус-дошманга сиздермим дип,
Йөрәгеңнең яраларын
Калкан белән капладың.

Синнән дә ярдәмчел кеше
Бу дөньяда бик аздыр,
Чөнки синең күңелеңдә —
Мәрхәмәтлек һәм изгелек,
Ярату белән наздыр.

Нинди генә хәлләрдә дә
Дусларыңны сатмадың.
Синнән ышанычлы кеше,
Ягымлы һәм көчле кеше
Тапмадым һәм тапмамын.

Гомерләрең озын булып,
Саулык бирсен Ходаем!
Матурдан матур теләкләр
Киләчәк туган көннәрдә

Теләрмен әле тагын.
Яме!

*2005*

## Син миңа сөю телисең

Син миңа сөю телисең —
Кабул итәм теләгеңне.
Әмма берүк исеңдә тот
Минем сөю хисләремә
Үзеңнең дә кирәгеңне.

Миндә кайнарлык сүрелмәс,
Ялкын өстәп торсаң әгәр.
Җылысын тоеп яшәрбез,
Әле яшьләрчә яшьнәрбез
Бакыйга күчкәнгә кадәр.

*2006*

## Кабат язлар җитте

Моңга күмеп, кабат язлар җитте,
Пар канатлар кунды иңнәргә —
Очыртты да мине алып китте
Кояш балкып янган көннәргә.

Күзем тутырып, кояш очкын сипте,
Очкыннардан ялкын тусын, дип.
Дәрләп янган кайнар йөрәгеннән
Сөю уты ташып торсын, дип.

*2007*

## Җырлап җибәр

Керфегеңә яшь эленсә,
Йөзең капласа сагыш,
Җырлап җибәр матур бер җыр —
Сизелмәс авыр язмыш.

Хәсрәт йөрсә тирәләтеп,
Килеп торса борчулар,
Җырлап җибәр күңелле җыр —
Бетәр бөтен йончулар.

Җырла, шатлык өелсә дә,
Кайгы килсә дә, җырла.
«Кеше нәрсә әйтер икән,
Яхшы түгел» дип торма.

Шунда белерсең җырлауның

Җанга шифа биргәнен,
Сыкрап торган күңелләрне
Җылы назга төргәнен.

*2006*

## Нурлар

Көзгегә барып карыйм да,
Күңелемне моң сара:
Узган еллар йөзләремә
Вакыт эзләрен сала.

Көлеп куйсам, күз тирәсе
Нурлар сибә як-якка.
Елмайган күзләрем һәрчак
Охшап кала Кояшка.

Һаман көлеп торган Кояш
Нурсыз була димени?
Тик бу нурлар минем йөзгә
Сызыклар булып сибелсә,
Кояшның кайнар йөзендә
Бер тамчы да сизелми.

*2006*

## Миләш белән Нарат мәхәббәте

Биек күккә ашкан бер төз Нарат,
Миләш кочагына сыенып,
Үткән-сүткәннәргә сәлам бирә,
Алар сипкән нурга коенып.

Уттай янып торган җимешләре
Учак итә иркә Миләшне.
Барган җирдән бар да, туктап калып,
Алар сөюеннән көнләште.

Хәйраннарга кала узган берсе —
Ничек кергән Нарат «учакка»?
Әллә Миләш, аңа сыенып үсеп,
Алган микән кайнар кочакка?

Искиткеч зур һәм киң «канатларын»
Ике яклап урап, таратып,
Кыю бөркет кебек тора Миләш,
Төз Наратын назлап, яратып.

Нараты да бер горурлык белән
Карап тора өстән Миләшкә.
Узганнарга әйтә сыман: «Әй, сез,
Чын сөюнең бер үрнәге бит без —
Сөя белмәгәннәр, читенсенми
Килегез, — дип, — безгә киңәшкә».

Яннарыннан үткән яше-карты

Сокланыплар китә аларга.
Җаннарында җылы хисләр туа,
Сөю хисе туа аларда.

Бер-беренә берегеп үскәнгәме,
Әйтерсең лә алар — пар канат.
Урман кырыенда кочаклашып
Сарылышкан килеш күккә ашып,
Саф сөюгә һәйкәл булып тора
Купшы Миләш белән төз Нарат.

*2006*

## Меңнәр йөрәгенә сыйгансыз

*Р.Р.Вәлиулловага*

Күңелегез бигрәк йомшак Сезнең,
Яхшылыкны гына җыйгансыз.
Шуңа күрәдер дә бу дөньяда
Меңнәр йөрәгенә сыйгансыз.

Чибәрлеккә кушып ягымлылык,
Зирәк акыл биргән Ходаем.
Һәр эшегез — нәтиҗәле хезмәт:
Бала вакыттан ук гаҗәп уңган,
Тырыш булгангадыр, мөгаен.

Килер көннәр Сезне күмеп торсын
Сәламәтлек белән уңышка.
Балаларның игелеген күреп,
Җаныгызны һаман назга төреп
Яшәгез Сез тигез тормышта!

*2005*

## Асия

*А.Маликовага*

Ак кәгазьнең чиста битләренә
Җайлап салыр өчен фикеремне
Алтын каләм көтә кулымда.
Бүген сезгә җыеп әйтер сүзем —
Үтә тырыш, гаҗәп миһербанлы
Хезмәттәшем Асия турында.

Мәңге бетмәс дөнья мәшәкатен
Бала чактан төпкә җигелеп тарткан,
Мин — кыз бала, диеп тормаган.
Яннарыннан китми караганга,
Әллә ничә айлар авырып яткан
Әтисе дә, мең рәхмәтле булып,
Китеп барган ошбу дөньядан.

Кечкенәдән, өелә-өелә килеп,
Иңнәренә яткан авыр йөкне

Әле һаман чаба күтәреп.
Өстәвенә гомерләрен кичә,
Туганнары, дус-иш моң-зарларын
Үз йөрәге аша үткәреп.

Һич чамасыз кеше зарларыннан
Арыйдыр да инде кайчакта.
Шәфкатьлелек анда бер Ходайдан:
Үтенечләр белән килгәннәргә
(Хәтта әле килмәгәннәргә дә)
Ярдәм кулын суза һәрчакта.

Әйтерсең ул — Ходай тарафыннан
Җиргә иңдерелгән фәрештә:
Нинди генә гамәлләр кылмасын,
Нигә генә килеп тотынмасын, —
Кулы ятып тора һәр эшкә.

Йөрәгендә янган ут ялкыны
Бер чибәрлек өсти йөзенә.
Кешеләргә шатлык өләшкәнгә,
Гаделсезлек белән көрәшкәнгә,
Ходай саулык бирсен үзенә,
Ходай бәхет бирсен үзенә!

*2006*

# Борчыма

Юкка борчыма син мине —
Бер-беребезне югалтканга
Күп еллар үтте инде.
Миндә янган кайнар хисләр,
Гел ут өстәп тормаганга,
Суынды, бетте инде.

Хисләр яңартасың килеп,
Юлларыма чәчкә сибеп,
Сүзне кабат башлама.
Янә бергә яшәп булмас:
Син дә инде бүтән белән,
Мин дә хәзер башкада.

*2002*

# Хуш, көллият!*

*Арча педагогия көллиятенә*

Әле кайчан гына тәүге тапкыр
Ачып кердек синең ишегең.
Бүген исә саубуллашу көне —
Күзендә яшь һәрбер кешенең.

Кушымта:

Хуш, көллият! Бәлки әле безне
Онытмыйча искә алырсың.

Ә син безнең йөрәк түребездә
Гүзәл мизгел булып калырсың,
Бер могҗиза булып калырсың.

Узып китте матур бер төш кебек,
Укып йөргән студент еллары.
Язмышларга инде сукмак ярды
Йөгереп үткән яшьлек юллары.

Кушымта.

Шул сукмактан сагынып сиңа килгәч,
Безнең күңел янә сафланыр.
Һәр бүлмәңдә, бер истәлек булып,
Эзләребез мәңге сакланыр!
Без көлешкән, без сөйләшкән тавыш
Кайтавазлар булып сакланыр!

Кушымта.

*2005*

# Вәгъдәләрең шампан күбегедәй

Вәгъдәләрең шампан күбегедәй —
Болгатмасаң да шәп күперә.
Чынлап әйткән кебек тоелса да,
Буш булуы белән үтерә.

Күкрәк сугып биргән вәгъдәләрең
Булды инде бигрәк гомерсез.
Баш әйләнгән кебек була әүвәл,
Биш минуттан үтә бер эзсез.

Вәгъдәләрең бигрәк арзан икән —
Бертуктаусыз тора коелып.
Башкайларың акыл иңдермичә,
Телең торсын иде тыелып.

Вәгъдәләрең шампан күбегедәй —
Күперә дә ташып югала,
Пыш-пыш килеп төшкән күбекләрдән
Юеш кара тап кына кала.

*1999*

# Салырбыз тик яралар

Дус булып калабызмы
Йә бергә барабызмы?
Күңел миннән таләп итә:
Ачыкла арагызны!

Иң якын дустың булырмын,
Ризалык бирсәң әгәр.

Бары дус булып яшәрбез
Соңгы сәгатькә кадәр.

Бергә барып булмас инде:
Шактый ерак аралар.
Аңлашалмый, йөрәкләргә
Салырбыз тик яралар.

*2000*

## Бу ни җанвар?

Чит җирдәге милләттәшләр арасыннан
Кайтып кына кердек бит әле югыйсә.
Бергә йөргән кайбер затлар авызыннан,
Зәһәрләнеп, инде гайбәт җиле исә.

Хәйран вә вәйраннар калып утырамын,
Гаҗәп матур йөреп кайттык бит югыйсә.
Кер эзләүче булгандыр дип һич көтмәдем —
Ник соң болай ямьсез гайбәт җиле исә?

Бер-береңнән көнләшүме, этләшүме —
Артык гамәл кылынмады бит югыйсә.
Нигә ашый кайберләүләр берсен-берсе —
Шул хөсетләр авызыннан ник җил исә?

Кеше чәйнәп һәм каралтып йөри торгач,
Адәми зат йөзен җуяр бу эт җаннар.
Ыслап-шыңшып йөргәннәрен күргән һәркем
Җирәнүбән сорап куяр: «Бу ни җанвар?»

*2002*

## Янымда йөри зур бәхет

*(Экспромт)*

Килде миңа яңа хәбәр:
Янымда йөри зур бәхет —
Минем бәхетем микән?
Әллә инде соң гомердә
Мине җилсетеп торучы,
Барыннан өстен куючы
Иң якын кешем микән?

Янымда йөри зур бәхет —
Мин аны җуймас идем.
Очрашып күрешә алсам,
Мәңге эргәсендә калсам,
Бу дөньяда яшәвемнән
Беркайчан туймас идем.

Очкын кебек ике күзе —
Йолдызлары күгемнең.
Аңа соклану да рәхәт,

Масаймавына мең рәхмәт —
Очынып уйный хыялы
Ләззәтләнгән күңелнең.

Янымда йөри зур бәхет,
Ничек тоткарлыйм икән?
Үземне авыр толлыктан,
Йөрәгемне бу коллыктан
Ничек коткарыйм икән лә,
Ничек коткарыйм икән? —
Киңәшегезне көтәм!

*2006*

## Җырларга күчкән идем...

*(Р.Фәйзуллинга тәкълид)*

Кайгы-хәсрәт дәрьяларын
Колачлап кичкән идем,
Күңелгә шатлык иңсен дип,
Соңарган бәхет килсен дип,
Җырларга күчкән идем.

Җырларымны бер-бер артлы
Мең тарафка тараттым.
Белмим, барып җитмәдеме,
Әллә дөрес китмәдеме —
Кайтавазын көтә-көтә,
Җанны гына канаттым.

Хәсрәтен дә, сагышын да
Кушучлап эчкән идем.
Бәгырьне көйдереп торган
Әрнүләрдән качар өчен,
Йөрәгемне басар өчен
Аннан ваз кичкән идем.

Әмма дөнья тарлавында
Хиссез яши алмаганга,
Җанда җылы калмаганга,
Нечкәдән нечкә күңелгә
Кабат Кояш иңсен диеп,
Җырларга күчкән идем...

*2006*

## Китәбезме?

*(Шаяру)*

Ай-й!
Күр әле, минем каршыма
Нинди егет утырган!
Күзләре уйнаклап тора —
Бигрәк матур, чукынган.

«Хатының бармы?» Булса соң.
Кемнең хатын, ире юк.
Мин бит гел үземә башка —
Бер килмәгән җирем юк:

Үзем тегәм, үзем бәйлим,
Үзем элеп киптерәм.
Өйләрне бик тиз чистартам,
Бар җирне ялт иттерәм.

Карале миңа, әйтерсең
Гөлчәчкәсе розаның.
Икенче хатының булып
Яшәргә дә ризамын.

Татарга бит ярый, дигән,
Дүрт хатын алырга да.
Әзермен, бәйгедә җиңеп,
Беренче калырга да.

Озак уйлама, сүземне
Кире алуым да бар.
Өметләрең шартлап сынып,
Минсез калуың да бар.

Шуңа күрә җыен әйдә!
Хатының булганчы пәйда,
Парлашып кайтып китик,
Барын да кызык итик!
Китәбезме? Тор әйдә!..
Булмыймыни? Бигайбә!

*2006*

## Хәзер син бөтенләй башка

Минем янда йөргән чакта,
Бар дөньяны гөлгә күмгән
Кояш кебек балкый идең.
Хәзер син бөтенләй башка:
Әллә инде йөзләреңә,
Риямны  күрмәсеннәр дип,
Сөремләнгән битлек кидең?

Минем янда йөргән чакта,
Һәрбер сүзең үлчәнгәнгә,
Син гаҗәп акыллы идең.
Ә хәзер бөтенләй башка:
Әллә инде «онытылып»,
Хәтерең эчкә йотылып,
Маңкортлар бүреге кидең?

Минем янда йөргән чакта,
Артык биек булмасаң да,
Хәйран гына «буйлы» идең.
Хәзер син бөтенләй башка:
Әллә инде буй-сыныңны,

Тураерга ирек куймый,
Бөгеп йөрткән бер кын кидең?

Минем янда йөргән чакта,
Уйлаганны ярып салган
Туры сүзле, гадел идең.
Хәзер син бөтенләй башка:
Әллә инде хакыйкатьне,
Чынбарлыкны җимереп-ватып,
Иблискә җаныңны сатып,
Ялган дөньясына иңдең?

Хәйраннарга калам шуңа:
Синең бөтен матурлыгың,
Кыюлыгың, батырлыгың,
Акылың һәм тапкырлыгың,
Мәхәббәттә затлылыгың
Вакытлыча булган икән.
Тик мине өзелеп сөйгәнгә,
Мин сине назга төргәнгә,
Бу сыйфатлар төрле яклап
Сине бизәп торган икән.
Хәзер син бөтенләй башка...
Кызганыч!!!
Түгелсең шул күздә-кашта!

*2006*

## Ай өстендә күрәм йөзеңне*

Кай якларга китеп бардың икән
Дөньяларың ташлап бик иртә?
Бу җыр сиңа дога булып ятсын,
Фәрештәләр илтеп җиткерсә.

Саубуллашмый китеп, йөрәгемә
Уеп-уеп салдың мең яра.
Исән чакта исәпләнми икән —
«Киткәч», сөю кабат яңара.

Күзләреңне, бәлки, онытырмын —
Оныталмам синең үзеңне.
Кичләр җиткән саен күзем күктә —
Ай өстендә күрәм йөзеңне.

*2006*

## Акыллы Патшаның зирәк уллары

*(Хөсрәү Дәһләвигә тәкълид)*

Шактый элек заманнарда
Яшәгән, ди, бер Патша.
Хәйран гайрәтле булган, ди,
Зиһен дә булган башта.

Патшалыгы бик зур икән,
Байлыгы да бихисап.
Чит илләр ясак түләгән —
Исәптән арткан хисап.

Акыллы Патша булган бу —
Алган күптөрле белем:
Дөньяви фәннәргә әле
Өстәгән дини гыйлем.

Тирә-яктан иң булдыклы
Галимнәрне чакырткан.
Алардан өйрәнгән Патша
Һәртөрле осталыкка.

Патшаның булган өч улы —
Әкияттәге кебек.
Бик зирәк булу өстенә
Булганнар сөлек кебек.

Төрле фәннән гыйлем алып
Менгәннәр бөеклеккә —
Кайберләрнең хәтта уе
Җитмәгән биеклеккә.

Беркөн Патша исәп иткән
Чакыртырга улларын.
Нияте: белү аларның
Нинди уйлар уйлавын.

Җаннары һәм йөрәкләре
Ни диеп туза икән,
Патша тәхетенә кайсы
Нәфесен суза икән?

Дәштергән әүвәл олысын.
Сүз башлаган болай дип:
«Әле генә үсмер идең —
Инде булдың баһадир.
Күркәмлек тә шактый синдә —
Әйтерсең гүзәл Таһир.

Гомер утым сүнеп бара,
Егәр дә кайчак китә.
Тәхеттә озак утырмам:
Миңа Аллаһ хозурына
Китәргә вакыт җитә.

Сиңа әйтәсе сүзем шул:
Син киләсең алмашка.
Хакимлек ит, шәфкатьле бул,
Һәрчак табын Аллаһка!

Ярлыларны, гарипләрне
Ярдәмеңнән ташлама.
Көчлене гайрәтең җиңсен,

Үзең сугыш башлама!

Байлыгыңны да тота бел —
Черемәсен чүп кебек.
Саклаучысы зәһәр булсын:
Көтүдән бүре куучы
Өйрәтелгән эт кебек».

Патша улы, башын иеп,
Әйткән, ди, болай диеп:
«И атам, сөекле Патшам!
Дәүләтеңнең ныклыгына
Чит патшалар таң калсын!
Тәхет турында уйлаудан
Мине Ходай сакласын.

Син әле исән-сау чакта
Кем уйласын бу хакта?
Син булмасаң, без — бер нокта,
Синең угылың булсак та.

Тәхеткә бит бер надан да
Менеп утыра ала.
Ә ул нәрсә кыла алсын,
Тик утырудан кала.

Син ашыкма тәхетеңне
Башкаларга бирергә.
Әле шактый озак еллар
Син патшалык иткән чакта
Язсын гомер сөрергә».

Олы улының сүзеннән
Канәгать калган Патша:
Димәк, тәхет кызыктырмый —
Мәкер юк моның башта.

Инде икенче угылын
Дәштергән бүлмәсенә.
Бусы зирәклеге белән
Атасы салган хәйләнең
Тиз төшкән мәгънәсенә.

«И атам, син исән чакта
Сүзләрең безгә — фәрман.
Озаклап хаким булсын, дип
Телим сиңа дәрт-дәрман.

Тәхет турында уйласам,
Бик зур гөнаһ алырмын.
Аллаһыбыз каршысында
Җирбит булып калырмын.

Әгәр дәрманың төкәнсә,
Әйтерсең катгый сүзең —
Арабыздан лаеклыны
Сайлап куярсың үзең.

Минемчә, олы абыем
Лаек булыр тәхеткә.

Затлы таҗны кидермәсәң
Үзе кебек затлы башка,
Китермәс зур бәхеткә».

Бу сүзләрдән олуг Патша,
Монысында да явыз уй
Юк икән, дип шатланган.
Тик тәхеткә тартылмавы
Җанына борчу салган.
Кәефе киткәндәй булып
Кыланган да зур Патша,
Икенче улын куган да
Чыгарган кайнар баштан.

Өенчесен — кечкенәсен
Дәштергән хәзер Хаким.
Әтисе сүзенә каршы
Дигән ансы: «Мин әйтмим,
Үсеп җитмәгәнмен, диеп.
Үсүен үстем инде,
Үсмерлектән егетлеккә
Шактыйдан күчтем инде.

Тик хакимлек итәр өчен
«Түбә дә кыек» әле,
Дәүләтне карап тотарга
Буыннар сыек әле».

Патша һәр өч җавапны да
Бик нык ошатып калган.
Өч улы — өч алтын икән:
Димәк, Аллаһы Тәгалә
Боларга акыл салган.

Әмма Патша шул ук көнне
Җиткергән үз фәрманын:
«Өч углым да, бергә йөреп,
Гизеп кайтсын дөньяны.

Үз биләмәләребезне,
Чит җирләрне күрсеннәр,
Акыл-гыйлем тупласыннар,
Гыйбрәт алып йөрсеннәр».

Саубуллашкан да өч угыл,
Баш иеп җиргә кадәр,
Кирәк-ярakларын алып,
Чыгып киткән ерак юлга.
Телик хәерле сәфәр!

Ел китәсен ай китеп,
Таулар, диңгезләр кичеп,
Үз дәүләте җирен үтеп,
Килеп чыкканнар болар
Кара Патша җиренә —
Гарәбстан иленә.

Бу өч туган, хәлдән таеп,
Утырганнар ялга дип.
Эссе, ди, бер дә харап.
Сусыннарын басар өчен
Эчеп куйганнар шәраб.
Кузгалыйк диеп торганда,
Яннарына килеп чыккан
Чуендай кара гарәп.

«Мосафирлар! — дигән ул. —
Юл газабы, кайгы-хәсрәт
Читләтеп үтсен сезне!
Борчысам да сорыйм инде:
Килгән чакта йөк күтәргән
Дөя күрмәдегезме?»

Олы угыл болай дигән,
Дөяне күрмәсә дә:
«Синең дөяңнең бер күзе
Сукыр идеме әллә?»

«Әйе, әйе», — дигән гарәп,
Шатлыктан сикреп куйган.
«Бер теше дә сынык икән», —
Дигән иң кече углан.

«Әле аның бер аягы
Аксак та икән, туган», —
Икенче углан да, түзми,
Үз сүзен әйтеп куйган.

Өлкәне янә өстәгән:
«Дөяңдә бит шактый мал:
Бер ягында — майлы кувшин,
Икенче ягында — бал.
Дөя өстендәге хатын
Бик тилмерә эченә,
Йөкле булырга охшаган —
Юлны авыр кичерә».

«Нәкъ үзе — бу минем дөя,
Сүзне тәмамлыйк тизрәк.
Инде әйтегез: мин аны
Кай якка китим эзләп?»

Өч бертуган бу адәмгә,
Китәр якны күрсәтеп,
Үз юлларын дәвам иткән,
Бисмиллаларын әйтеп.

Тиз арада күтәрелгәч
Кояш күк түбәсенә,
Болар тәмам әлсерәшеп,
Үрмәләп кереп ятканнар
Агач күләгәсенә.

Карасалар, шунда гына
Чишмә дә ага икән.
Юынып, суларын эчкәч,
Бераз хәл кереп киткән.

Ул да булмый, өермәдәй
Килгән дә чыккан гарәп.
Сулышы хәйран ешайган,
Йөзе-күзе чалышайган:
Ачуы — бер дә харап.

«Йөгереп эзләп гарык булдым,
Очратмадым дөямне.
Мәҗбүрмен сезгә бирергә
Тагын шул ук сөальне.

Кая киткән шул арада,
Кайлардан табыйм икән?»
Кинәт, усал уйга кереп,
Дулап, тузынып киткән.

«Әһә, сез үзегез урлап,
Дөямне суйдыгызмы?
Хатынны, малымны алып,
Яшереп куйдыгызмы?» —
Дип акырган тирә-юньгә,
Гарәпләр тиз җыелган.
Аптырашкан өч туганны
Шәһәргә алып киткәннәр
Җәза бирү уеннан,
Бауга тезеп муеннан.
Барып кергәннәр туп-туры
Кара Патша янына.
Кара гарәп, каракларны
Хөкем ит, дип ялына.

Сөйләп бирәдер Хакимгә
Ничек, ниләр булганын,
Бу өчәү күрсәтмәсенең
Туры килеп торганын.

Аклану сүзен әйтергә
Өчәүгә чират җиткәч,
Өлкәне башлаган сүзне:
«И Падишаһ, кодрәтең зур —
Син әйткән сүз — аткан ук.
Тик хөкемең чыгарганчы,
Бу хәлләр, эшләр турында
Сөйләп бирим баштан ук.

Бик ерак илдән киләбез —
Булмаган җир калмады.
Байлык безгә кирәк түгел,
Гыйбрәтләр алып йөрибез,
Бер дип белеп Алланы.

Әллә ничә чикне үтеп,
Синең җиргә кергәндә,
Кинәт кенә каршыбызда
Пәйда булды бу бәндә.

Юктан зур шау-шу күтәрде,
Әйтерсең без караклар,
Дөясен, малын күрмәдек —
Бездә бары фаразлар.

Безнең гаеп шунда гына:
Без аңлатып тормадык.
Ул әйткәнчә бернинди дә
Явыз тозак кормадык».

Бу сүзләрне ишеткәч тә,
Хаким гаҗәпкә кала:
«Бу ни дигән сүзләр тагын? —
Ялганнан яман кала.
Зинданда бераз торсагыз,
Тиз иманга килерсез —
Урлаганның барысын да
Иясенә бирерсез».

Шулай итеп, Кара Патша
Ышанмаган боларга.
Өч туганны бик тиз генә
Ябып куйган зинданга.

Андагы хәлдән өчәүнең
Чыгып очкан котлары.
Ошбу төндә өч гаепсез
Таш идәндә йоклады.

Икенче көн иртә таңнан
Кояш нурлары белән
Дөяне бер адәм, табып,
Гарәпкә илтеп биргән.

Сөенечен әйтергә дип,
Гарәп киткән Патшага:
«И Хөкемдар! Мал табылды —
Китмәгән ул башкага.
Алдагы көннәремдә дә
Ярдәмеңнән ташлама».

Патшаның ачуы килеп,
Ялганчы икәнсең, диеп,
Бу гарәпне суктырган.
Җәзадан котылу өчен,
Башта гарәп лаф орган.

Тик файдасы булмаганга,
Күп сөйләнеп ташлаганга,
Ялгышканын аңлаганга,

Бөтен авыртуга түзеп,
Телен тешләп тик торган.

Бу хәлдән соң Патша үзе
Нык оялган — янды бит.
Бер гаепсез егетләрне
Зинданнарга салды бит.

Ялгышын танып, аларны
Алтын сарайга дәшкән.
Гафу сорап, һәрберсенә
Зур бүләкләр өләшкән

Һәм әйткән: «Мин ни булганын
Төгәл белергә тиеш,
Дөяне, хатын, малларны
Ничек тасвирлый алдыгыз
Күзегез күрмәгән килеш?

Бар чынын сөйләп бирсәгез,
Кулыгыз алтын кочар.
Әгәр хәйләләп торсагыз,
Башыгыз кыелып очар».

Патшага хөрмәт белдереп,
Баш ордылар егетләр.
Өлкән углан телгә килде:
«Без бит дәрвиш кебекләр.

Мәсәлән, мин үзем эздән
Билгеләдем дөянең
Бер күзе сукыр булуын —
Мин чын дөресен сөйләдем:

Чөнки ул бары бер яктан
Үләнне кыркып үткән.
Аның ише нәрсәләрне
Беләбез инде күптән».

«Ә мин, — дигән икенчесе, —
Аксак булуын сиздем:
Бер аягын сөйрәп барган,
Авыртуына түзми».

Башын иеп, Падишаһка
Әйткән иң кече туган:
«Бер теше сынган булуын
Шунда ук аңлап алдым.

Фаразның чынга чыгуын
Белеп хәйранга калдым:
Үлән рәттән кыркылмаган —
Гел ара калып барган,
Өзелгән үлән янында
Өзелмәгәне калган».

Падишаһ сүзсез килешкән:
«Монысына ышанам:
Бар да дөрес, бар да чын.
Әмма әйтми калдырдыгыз
Өч табышмак җавабын».

Өлкәне шундук сүз алган:
«Падишаһым, солтаным,
Беләсең киләдер инде
Кайдан белеп әйткәнемне
Кувшиннарда ни барын.

Юл буенча үләннәргә
Гәрәбәдәй матур сары
Тамчылар тамып калган.
Тамчыларның бер ишесен
Кырмыска яратып эчсә,
Икенчесен, безелдәшеп,
Чебеннәр сырып алган.

Һәркемгә мәгълүм ки: балны
Үлеп ярата чебен,
Ә кырмыска май ярата —
Шуңа калмады шигем».

Икенче туганы әйткән:
«Дөя өстендә хатын-кыз
Барганын белү безгә
Авыр эш түгел бер дә:
Бик еш кына төшеп йөргән —
Эзләре калган җирдә».

Өченчесе өстәп куйган:
«Бу өлкәдәге фаразым
Чынга ашадыр күптән —
Әлеге хатынның инде
Бәбиләр вакыты җиткән.

Чүгәләгән һәр җирендә
Аяк эзе генә түгел,
Кул эзләре дә калган:
Көмәне авыр булганга,
Торып китәр өчен, мескен,
Дүрт аякланып алган».

Боларның зирәклегенә
Исе киткән Патшаның.
Караңгы төшкәнгә кадәр
Сөйләткән ул өч туганны,
Кабул итми башканы.

Берничә көн, шулай итеп,
Бу хәлгә мөкиббән китеп,
Тыңлап, уйлап утырган.
Башына белем өстәсә,
Эченә шәраб тутырган.

Сөйләтеп түйгач, аларны
Сыйларга ният итеп,
Китерткән тәмле ризыклар:
Куе кызыл салкын шәраб,
Кыздырган сарык ите.

Бу өч туган, рәхәтләнеп,
Утырганнар ашарга.
Ашап туйгач — аптыраштa:
Тик берсе дә әйтер сүзне
Белми кайдан башларга.

Олы туган әйтеп куйган:
«Без эчеп алган бу шәраб
Шәраб түгел — кеше каны,
Булмасак ярый харап».

Икенчесе әйткән шунда:
«Һич тә сарыкныкы түгел
(Бер дә тартмады күңел)
Без ашаган йомшак ит.
Бәти чагында имезгән
Көтү көтә торган эт».

Өченчесе әйткән: «Хаким —
Патша канынннан түгел,
Пешекче малае бит ул,
Чын Патшага ул — үги».

Бу сүзләрне, яшеренеп,
Хөкемдар тыңлап торган.
Бер сүзне дә калдырмыйча,
Бәгърәнә салып куйган.

Җен ачуын басалмыйча,
Бу егетләр янына
Дуфан кебек килеп кергән,
Чыдый алмый җанына.

Егетләрнең өчесе дә
Сикереп торып баскан.
Куркуларыннан котлары
Әллә кайларга качкан.

Падишаһ шундук аларга
(Зәһәр йөзенә карауга
Язмасын өчен һуштан)
Әле сөйләгән сүзләрен,
Бер җирен дә үзгәртмичә,
Кабат сөйләргә кушкан.

Яңабаштан тыңлап чыккач
Егетләр хикәятен,
Йөзләре каралып чыккан,

Бәгырьләрен көйрәтеп.

Аннан әйткән өч туганга:
«Бу хәлләрне һичбер кеше
Белергә тиеш түгел!!!
Телегезгә — иң зур мөһер,
Авызга — тимер бигем».

Таң сызылып аткан чакта
Чакырткан шәрабчыны.
Шәрабын ничек ясаган —
Сөйләткән бөтен чынын.

Шәрабчы әйткән: «Баш өсте,
Җинаять юк югыйсә.
Сатып алам мин йөземне
Йөземченең үзеннән,
Тик аның йөземе исә
Каберстанда үсә.
Зират өстен тигезләтеп,
Бакча ясаган, мөртәт.
Шунда үстергән йөземен
Шәрабка сата күпләп».

Падишаһ түзми кычкырган:
«Бу гөнаһтан йөземчене
Тиз көндә Аллаһ орыр,
Канлы йөзем куаклары
Тамырыннан ук корыр.

Ә син, ахмак, шәрабыңның
Янә шундыен китерсәң,
Башың киселгән булыр!» —
Дигән дә куып чыгарган
Аны үз бүлмәсеннән.
Шәрабчы чыгып йөгергән
«Абынып» тәүбәсенә.

«Ярый, хуш, бер серне белдек,
Икенчесен дә белик», —
Дип чакырткан көтүчене
Падишаһ, янып-көеп.

Эшнең ни икәнен белгәч,
Көтүче, куркуыннан,
Ялган сөйләргә керешкән:
«Чып-чын сарыктан туган
Бәрән иде, чын әгәр.

Гел әнисе белән генә
Үсте җирдә тәгәрәп.
Аннан һич аерылмады,
Әнисенең сөтен имде,
Башкага кагылмады».

Бу сүзне ишетеп, Хаким
Янә бер дулап алган:
«Хәзер зинданга ташлатам,
Кызган тимердән көйдереп,
Башыңны чабып өздереп,
Этләремә ашатам,
Әгәр сөйләсәң ялган!»
Көтүче, коты алынып,
Тиз үзгәрткән сүзләрен.
Авызларын мимылдатып,
Челт-челт китереп күзләрен,
Сөйләп киткән ашыгып:

«Бу сарык бәрән чагында
Көтүгә төшкән бүре
Әнисен ботарлады.
Нәкъ шул көнне көтмәгәндә
Зур этем балалады.

Бәрәнне үзенеке дип
Уйлап һаман ялады.
Читкә какмады беркайчан —
Имезде дә ул аны,
Баласыдай карады.

Әле сарык булгачтын да
Бергәләп уйнадылар.
Көннәр буена куышып,
Чабышып туймадылар.

Мин, юньсез, китердем сиңа
Алдан ук белгән көе
Тәмле булмасын ашың.
Кем белгән болай буласын,
Ялганым ачыласын».

Моны ишеткәч, Патшаның
Башы әйләнеп киткән.
«Тирә-юнем ялган икән»
Дигән шомлы уй үткән.

Көтүчене җилтерәтеп,
Чыгарып җибәргәннәр.
Малының яртысын алып,
Җиңел җәза биргәннәр.

Инде Патша зур хәвефтә:
«Өченчесе дә шулай ук
Туры килер микәнни?
Бу шом салган табышмакның
Җавабын бирер әни», —
Дип, Падишаһ тиз-тиз киткән
Әни Патша янына.
Ишегеннән керү белән:

«Нинди сер бар мин белмәгән,
Сөйлә! — диеп ялына. —

Минем тамырда кем каны,
Кем минем газиз атам,
Бәлки, ул патша түгелдер,
Кем иде, кайсы яктан?»

Бу сүзләр ана җанына
Хәнҗәр булып кадалган.
«Нәрсә сөйлисең син, углым,
Нинди мәгънәсез сорау,
Кем сиңа коткы салган?

Ничек оялмыйсың болай
Анаңа сүз катарга,
Атаңнан башка кем хаклы
Миңа гаеп атарга?»

Әнисе сүзеннән Хаким
Сикереп торган урыныннан:
«Әйт дөресен яхшы чакта,
Мин ана диеп тормам.
Әйттерү җаен табармын —
Бу мәхшәрдән котылу өчен
Әрнеп янган йөрәгемә
Хәнҗәремне кадармын».

«Улымның ачуы көчле —
Миңа үч итеп, чыннан да
Берәр хәл кылмагае», —
Дип, әнисе дөреслекне
Ачкан, китереп җаен.

«Тыңла, улым, бу серне мин
Гомер буе сакладым.
Дөнья болганмасын, диеп,
Беркемгә дә ачмадым...
Матур көннәрнең берендә
Падишаһ ауга киткәндә,
Мин йоклап калган идем.
Ул вакыт яшь, матур чагым,
Көн дә кояшлы күгем.
Балабыз булмавы гына
Борчый иде кайчакта.
Сәбәбен белмәдек, юкса
Көн дә кайнар кочакта.

Йокы аралаш ишетәм:
Пешекче күтәреп кергән
Миңа иртәнге ашны.
Күземне ачып карадым,
Бераз күтәреп башны.

Култабын тоткан гаҗәеп
Зифа егетне күреп,

Башларым китте әйләнеп,
Күңелләр китте бәйләнеп —
Тыелырлык түгел идек.

Чибәр егет минем янда
Иде шушы мизгелдә...
Шул мизгелдән син яралдың,
Шатлык китереп безгә.

Бәхет иңгән булыр иде
Бәгырьдән төшкән баламны
Падишаһтан табалсам.
Инде көтәм хөкемеңне,
Бу дөньяга килүеңне
Зур гаепкә санасаң?»

Бу сүзләрдән горур Патша
Бер мәлгә каушап калган.
Яшерен серне ачтырганга,
Йөрәге чәнчеп алган.

Әнисенә сүз әйтмичә,
Борылып чыгып киткән.
Йөрәк ярсуын басалмый,
Кайнар яшьләрен түккән.

Өч туганны тиз эзләтеп
Китерткән үз янына.
«Сез әйткәннәр — дөрес, — дигән, —
Үзем белдем барын да.
Тик шулай да әйтегезче,
Кайдан моны белдегез,
Тирәндә яткан серләрне
Ничек итеп күрдегез?»

Падишаһка туры карап,
Олы углан сүз алган:
«Шәрабны эчә башлагач,
Күңел өзгәләнеп куйды
Шәрабта сагыш бардан.

Ә бит шәраб, киресенчә,
Күңелгә — ял, җанга ләззәт
Бирергә тиеш иде.
Туганнарыма карадым:
Шәрабтан соң аларның да,
Бәгырьләре телгәләнеп,
Күзләре юеш иде.

Шуннан аңлап алдым инде
Эшнең нидә икәнен:
Шәрабта — кара күз яше,
Аның да гадие түгел —
Гомерләрне кискәне».

Икенчесе сүз башлаган:

«Сарык итен кабу белән
Мин тиз аңладым шуны:
Итнең бернинди тәме юк,
Авызда — төкерек тулы.

Хәтта эт исе килгән күк
Булып тоелды миңа.
Бу билгеләр сарыкларда
Этне имгәндә була».

Кечесе Патшага әйткән:
«Әллә ни курыкмасам да,
Ант эч, тимимен, диеп.
Исән-сау кайтып китәсең,
Башың кисмимен, диеп».

Хаким ант эчкән ихластан
Барлык изгеләр белән.
Тик әйтсен генә, ничекләр
Әнисе серен белгән.
Яшь егет шунда, тынычлап,
Сүзләрен дәвам иткән,
Могҗизалы сернең серен
Бар да дүрт күзләп көткән.

«Гафу ит мине, Падишаһ,
Синең һәрбер сүзеңне
Игътибар биреп тыңладым
Һәм күзәттем үзеңне.

Күзгә бәрелгән һәрнәрсә
Нидер турында сөйли.
Шулар буенча беләбез:
Кем батыр, кемнәр шөлли.

Тотыш-хәрәкәте нинди,
Кайсы катлау сөйләме.
Игътибар итәсең әле —
Ул катлауны беләме?

Ни турында сөйләшсәк тә,
Син сүзне ашка бордың.
Ашауга кагылган сүздән
Син ләззәт алып тордың.

Сүз тәртибең, хәрәкәтең
Әллә ни сатмаса да,
Гади сүзләр рәсмиләрдән
Әллә ни артмаса да,
Патша каны түгеллегең
Әллә кайдан сизелә».

Падишаһ телсез үк калган,
Бу сүзләрне ишеткәч,
Үзен көчкә кулга алган,
Зәһәрлек пары киткәч.

Өч туганга исе китеп

Карап-карап торган да
Бер уйга килгән: «Боларны
Тизрәк моннан куарга.

Мин белмәгән серләр күптер,
Барын ачып салсалар,
Яшәрлекне калдырмаслар,
Тагын торып калсалар».
Падишаһ тынычланганчы
Берара вакыт үткән.
Аннан, сабырлыгын җыеп,
Болай дип дәвам иткән:

«Нинди Патша булыйм ди мин,
Ачу кабарган чакта
Гаепсезне утка салсам,
Үч алып, башын чапсам?

Тик шулай да кузгалыгыз:
Дөяләр көтә, кабаттан
Сөйләшмибез бу хакта.
Озын-озак җыенмыйча
Китегез яхшы чакта».

Бераз уйланып торган да,
Гафу итүләрен сорап,
Өч туганга рәхмәт юллап,
Инде ул болай дигән:

«Сезнең зирәк акылыгыз —
Бар нәрсәдән дә бөек.
Хәтта байлык биек булмас,
Куйсаң да өеп-өеп.

Сезнең сүзгә колак салдым —
Файдалы сабак алдым:
Һәркемнең үз урыны —
Атның да үз колыны».

Аннан соң ул аларны,
Алтын акчалар биреп,
Озаткан өйләренә —
Бәхетле көннәренә.

Ел үтәсен көн үтеп,
Озын юлларны кисеп,
Тирән дәрьялар кичеп,
Тозлы суларын эчеп,
Кайтып кергәннәр болар
Әтиләре янына —
Үз патшалыкларына.

Бар да өзелеп сагынган —
Җыелганнар табынга.
Өч бертуганны тәбрикләп,

Җылы сүз әйтмәкче була
Һәммәсе үз ягыннан.

Карт Падишаһ шатлыгыннан
Яшәргән, ди, ун елга.
Җитендәй ап-ак чәчләре
Каралып киткән шунда.

Сөйләткән угылларыннан
Чит патшалык турында:
«Яшәү ничек, халык нинди,
Хакимлек кем кулында?»

Уллары бәян кылганнар
Башларыннан үткәнне,
Ул җирдәге хикмәтләрне,
Хикмәтләр серен ачканга,
Көчкә котылып киткәнне.

Патша, катгый уйга килеп,
Сүзен бик кыска тоткан:
Олы улын Патша итеп
Тәхетенә утырткан.

Калган улларына биргән
Бик матур шәһәрләрне.
«Идарә итегез, — дигән, —
Көчегезне җәлләми».

Шулай үз хакимлегенә
Нокта куйган Падишаһ.
Килгән халык, дәррәү килеп,
Яшь Патшага тез чүккәннәр,
Чапан итәген үпкәннәр —
Бар да разый, бар да шат.

Патшаның соңгы гомере,
Уллары кадерен тоеп,
Гел рәхәтлектә үткән.
Ни хикмәттер: шуның белән
Сөйли торган хикәятем
Кинәт беткән дә киткән.

*2006*

# *Шәрык поэзиясе үрнәгендә*

## Робагыйлар

* * *

Сөйгән җаннар газабының чиге юк,
Утта янып тилмерүнең тиңе юк.
Кайчакларда боз да керә йөрәккә —
Ни күңелнең, ни йөрәкнең биге юк.

* * *

Йөрәкне йә күмер итә мәхәббәт,
Кайчагында гөлләр итә мәхәббәт.
Бер-беренә туры килгән ярларның
Икесен кушып бер итә мәхәббәт.

* * *

И көнләшү!
Кешеләргә бирәсең авыр җәза.
Көнләшеп, берәүләр акылдан яза.
Саласың йөрәккә тирән җәрәхәт,
Аның әрнүе үзенә бер каза.

* * *

И гүзәлем, сине күпме көтеп була,
Йөрәк белән җанны күпме өтеп була?
Менә сиңа көем, бусы менә өем:
Иясе бул! Юкса җеннәр кереп тула.

* * *

Йөзләреңне күрмәгәнгә «ел» бит инде,
Сагынудан ике күзем күл бит инде,
Арабызда ике атлам юл бит инде —
Киртә булырдай һичнәрсә юк бит инде.

* * *

Тормышыңда яр булырмын мәңгелек,
Аңласаң әгәр җанымны иң элек,
Терәк булсаң бөтен гомерем буена —
Тумас синдә һичберкайчан көнчелек.

* * *

Мең газап күрсәм күрермен,
Мең назга сине төрермен.
Мәхәббәт салган ялкынның
Кыл уртасында йөрермен.

* * *

Йөрәккә аттың ук белән —
Шуңа утка үзем керәм:
Укны алсаң йөрәгемнән,
Мин бит шундук егылып үләм.

* * *

Күргәч тә кайнар яшьләрең,
Акты минем дә яшьләрем.
Синнән соңгы гомерләрдә,
Белмим, ничекләр яшәрмен?

* * *

Бик моңсу итте юлларны
Моңлы сазыңның кыллары.
Ике күзем — ике диңгез:
Чумдың, бетәм дип тормадың.

* * *

Авыр уй биләсә башны,
Җан урын табалмый башлый.
Синең күкрәктә ни икән:
Назлы йөрәкме йә ташмы?

* * *

Бар нәрсәгә борының тыкма
Һәм нәфсеңне авызлыкла.
Ихтыяр көчен югалтсаң,
Буйсынырсың явызлыкка.

* * *

Сәламәт кеше аңламас
каты авыру хәлен,
Йокыдан айный алмаган
белмәс йокының тәмен.
Рәхәтен күрмәс яшәүнең
мал дип башын югалткан,
Хәтта сизмичә уздырыр
тормышның гүзәл мәлен.

* * *

Күпме генә селтәнсә дә,
кылыч кыймас черки башын,
Яңаклый алмас чебенне,
тырышса да горур лачын.
Мескен тычкан азык эзләп
кыр буйлатып йөгергәндә,
Һич башына китермидер
тәмләтәсен бөркет ашын.

* * *

Розадан да матур чәчкә
дөньяда табылмады,

Энәләрен тырпайтканга,
беркем дә кагылмады.
Күпме генә кылтайса да,
берәү тиеп китү белән
Зур булып ачылган иде,
яңадан ябылмады.

* * *

Кеше гомере буена
белем һәм гыйлем ала.
Шул гыйлемне тормышының
һәр сукмагына сала.
Ни кызганыч, күпме җыйган
белеме дә, гыйлеме дә,
Бер көн килеп, аның белән
кабергә китеп бара.

* * *

Әгәр җиргә һәм халыкка
яхшылык чәчсәң өеп,
Утырып эшләгән урның
булыр тәхеттәй биек.
Син кылган яхшылык кайтыр
үзеңә хөрмәт булып,
Бер кеше әйтмәс, тормышта
юкка яшәде, диеп.

* * *

Кешеләргә бер китерсәң
хәтта кечкенә зыян,
Ярдәм кирәк чакта качсаң,
булып бер куркак куян,
Элек кылган игелегең
минутта юкка чыгар —
Яхшы исмеңнең эзе дә
гомер булмаган сыман.

* * *

Ауясыз орыш кырында
мәгънәсез көрәш бара:
Егарсың, бәлки, берәвен,
салып үтергеч яра.
Моның белән һич мактанма:
юк итү авыр эшмени —
Үлемгә хөкем иткәнче,
син яшәү биреп кара.

* * *

И гашыйклар, бер-берегездән
ераклашып йөрмәгез.
Берең артыннан икенчең
гөлләр кебек үрләгез.
Калдырмагыз һич зур бушлык
икегез арасында,
Шул арага дошман кереп,
аеры кала күрмәгез.

* * *

Үз халкыңа хезмәт итсәң,
күрсәтсәң зур игелек,
Син яшәрсең мактауларга,
ихтирамга күмелеп.
Китеп барсаң уйламыйча
гел начарлык юлыннан,
Бу юл сине тезләндерер
һәм калырсың җиңелеп.

* * *

Тулы камил акылыңны
син башыңда тотмасаң,
Үз фикереңне расламый,
дошман сүзен хупласаң,
Караңгылык биләп алыр
тирә-ягың тоташтан.
Югалырсың, дусларыңның
туры сүзен кабул итми,
үпкәләрне «йотмасаң».

* * *

Төш белән өнне бәйлисең —
үзең кайта алмыйсың.
Күзләреңдә гел ялвару —
сүзең әйтә алмыйсың.
Көн дә килеп төшләремә
коча-коча елыйсың.
Китә алмаслык булгачтын,
өндә нигә калмыйсың?

* * *

Кешегә бер этлек кылсаң,
йөзе белән үзеңә кайтыр.
Ярдәм сорап килгәннәрне
кусаң, җаның нәфрәт татыр.
Йөрәгеңдә боз торганга,
изгелекне күзең күрмәс.
Явызлыгың, хаким булып,
үзеңне хөкемгә тартыр.

* * *

Бер сулып корыган гөлләр
яңадан чәчәк атмый.
Тарихларга киткән еллар
әйләнеп кире кайтмый.
Очратырмын, дигәннәр дә,
күпме генә күзләмәсен,
Яшьлектә калган көннәрнең
хәтта эзләрен тапмый.

* * *

Кичен ятып, иртәгесен
торасыңны белмисең.
Шуңа көн дә яхшылык чәч,
югыйсә өлгермисең.
Уңышыңны җыеп ал да
янә чәч зуррак җиргә.
Шул чакта үзең күрерсең
игелекнең төрлесен.

* * *

Яңа дуслар таптым диеп,
иске дусны ташлама.
Тормышыңда күңелсезлек
кайчак шуннан башлана.
Эш күрсәтер өчен генә
кылма кирәксез гамәл —
Файдасы булмаган эшне
беркайчан да башлама.

* * *

Йөрәгеңне кальга итеп,
бәхет керт өем-өем,
Уздырма тик гайбәтченең
кисаптай озын телен.
Аның сүзенә ияреп,
бәхетең ташлап китәр,
Йөрәгеңә кан саудырып
кискәнгә телем-телем.

* * *

Мин кем, дип, артык тырышма —
зиһенең зәгыйфьләнмәсен.
Эшләрең хупланмый икән —
моңа гаҗәпләнмә син.
Барсына да ярыйм дисәң,
яра, хәлеңнән килсә,
Тик, онытылып, үзеңә
ярап куя күрмә син.

* * *

Акыллы, зирәк сүзеңне
алтын-көмештәй сакла.
Башта сөйләгәнне тыңла —
сүзне бүлеп, сүз катма.
Телең телгә йокмаса да,
кайчакта тый телеңне.
Бөтен кеше сөйли бит, дип,
дөнья гайбәтен сатма.

* * *

Биеккә менәсең килеп,
кат-кат өймә мәетләр.
Бу эшне кайчан да булса
бөтен халык гаепләр.
Үзең җибәргән әрвахлар
өерелеп бер килер —
Ярдәм итә алмас шунда
сиңа хәтта сәетләр .

* * *

Әгәр кешенең башында
камил акыл булмаса,
Акылы белән йөрәге
чын дуслыкта тормаса,
Таба алмас мондый кеше
туры юл гаделлеккә —
Бары алар ярашканда
юлны якты нур баса.

* * *

Хакыйкать уты янганда,
ялганнан җилләр исә,
Ялган сөйләүчеләрнең ул
пычранган телен кисә.
Кайчакларда хакыйкать тә
китерә байтак «зыян» —
Явыз нияттә гамәлләр
кылырга юлны кисә.

* * *

Яхшылык белән Явызлык
дусмы, дошманмы диеп,
Сүзләреңдә һәм эшеңдә
ачыклап куй син элек.
Чөнки тормышта һәрвакыт
гамәлне кылу кирәк,
Аларның һәр икәвенең
кая илтәсен белеп.

* * *

Баш өстендә үлем белән
уйнап торган кылычны
Башың иеп каршы алсаң,
теләп бары тынычлык,
«Игән башны кылыч кисми»
дигән әйтем рас килмәс, —
Шәһит китәрсең, халкыңа
калып чиксез бурычлы.

* * *

Бәхетсезлек килгәннәргә
исән чакта кыл ярдәм.
Йөрмә булышырмын диеп
үлгәчтен дә бу адәм.
Вөҗданың булса, һич көтмә
килгәнен аңа үлем —
Явыз ниятләрең белән
китәр җаныңнан садәң.

* * *

Явызлыкны, вәхшилекне
гафу итмәскә кирәк.
Вәхшилек агачы һәрчак
агулы җимеш бирә.
Кара эшләр башкарганнар
үзе дә рәхәт чикмәс,
Газап күрерләр халыкның
үпкә-рәнҗеше илә.

* * *

Дөньяда таты барын да:
тозын, әчесен, балын да.
Киләчәккә илтер юлда
кичсәң яңгырын, карын да,
Максатыңа ирешерсең,
дуфаннары дуласа да,
Үтәрсең бик җиңел генә
юлларның киңен, тарын да.

* * *

Юлларыңда туктап калма —
юлаучы барып җитәр,
Җиңел тормыш эзләгәннәр —
табалмый йончып бетәр.
Сынау өчен җибәрелгән
ачы кайгы-хәсрәттән
Гыйбрәт алсаң, сабыр булып,
авырлык үзе китәр.

* * *

Хакыйкатьтән рухың белән
аерылма, бул горур,
Югыйсә башың очыңда
бәла өелеп торыр.
Кешегә ләгънәт яудырма,
гайбәткә төрмә җанын —
Шушы пычракка буялып
каралган телең корыр.

* * *

«Кешегә чокыр казыма,
үзең төшәрсең» диләр.
Мондый эшне эшләр бары
кабахәт яки җүләр.
Үзеңә ни теләмәсәң,
шуны ятка теләмә —
Бу хаклыкка буйсынмаган
артык зур бәя түләр.

* * *

Соңгы юлга җыенганда,
барла изге эшеңне:
Исәбен ал син булышкан,
рәнҗетмәгән кешеңнең.
Гомерең буе һичкемгә
зыян салмаган булсаң,
Теленнән төшермәс халык
синең изге исмеңне.

* * *

Карунлык әсирлегенә
төшә күрмә син ялгыш —
Тынычлык белән бәхетне
китермәс сиңа язмыш.
Кеше хакын ашап йөрсәң,
бер килеп тончыгырсың.
Ниятләрең изге булса,
алмассың рәнҗү-каргыш.

* * *

Кайчакларда яман чирләр
саулыкны алыштыра,
Шатлыкка дигән урынны
хәсрәтләр алып тора.
Шатлыгы да, хәсрәте дә
үтә вакыты җиткәч —
Сабырлыгын җуйган гына

бу хәлләргә аһ ора.

* * *

Мәхәббәт белән дошманлык,
агу — балга янәшә.
Әле берсен, әле берсен
кеше ярдәмгә дәшә.
Кемгә агу, кемгә сөю
ярдәм итә тормышта —
Ялгышмас өчен аларның
тәэсирен белеп яшә.

* * *

Җаның кайнарлыгы сине
сүнмәс утка салмасын.
Акылың олыгайса да,
йөрәгең картаймасын.
Яшь йөрәккә зирәк акыл
кирәк гомер буена —
Бу ике зур байлыгыңнан
берүк читкә тайма син.

* * *

Шатлыкта да, хәсрәттә дә
дустыңны сынап кара,
Чөнки кеше бу тормышта
төрле хәлләргә тара.
Таяныч, сердәш булырлык
дус итеп шуны сайла —
Гамәле һәм теле белән
уймаслык булсын яра.

* * *

Чын дус дип әйтеп буламы
дусларын сөймәгәнне,
Ярдәм сорап килгән чакта,
сәлам дә бирмәгәнне?
Якын җибәрмә яныңа
явызлык чыганагын —
Колагы ишетмәгәнне
теле ни сөйләгәнне.

* * *

Дөреслек, зирәклек белән
рухың бай булса әгәр,
Таптым дип уйла хәзинә
алтын таулары кадәр.
Алдауга син кереп китсәң,
ана йөзен пычратып,

Киләчәккә узар юлың
булыр тайгак һәм хәтәр.

* * *

Баласын яки туганын
алтынга саткан кеше
Барыбер бай була алмас,
чөнки каргышлы эше.
Әтисен дә, әнисен дә
андыйлар тиз рәнҗетер,
Әмма каргыш, рәнҗешләргә
җитмәс беркайчан көче —
Үзе күмергә әйләнер
кылган зәхмәте өчен.

* * *

Акыл белән эш иткәндә
бәхетсезлек тә китәр.
Мохтаҗларга яклау килер —
хәерчене бай итәр.
Тик үз көчең җитмәгәнгә
алынма, мин кем, диеп, —
Акылсыз кылган гамәлләр
надан башыңа җитәр.

* * *

Аксакаллар әйтсә әйтә:
«Ходайның зирәк улы
Кап-караңгы төн эченнән
эзләмәс кояш нурын.
Дус булып йөргән дошманнан
мәңге көтмәс яхшылык —
Зирәклеге белән яулар
хөрмәтнең шактый зурын».

* * *

Хәйләкәрне күзгә карап
ант иттерсәң мәҗбүри,
Көлтә-көлтә вәгъдәләрне
биргән дә булыр юри.
Син борылып китү белән,
бозар антын, вәгъдәсен —
Ышансаң аңа бетәрсең,
боздан тиз эри-эри.

* * *

Өелеп килгән сынауга
баш иярргә ашыкма.
Йөрәк шифасы — бәлзәмне
эчсәң дә син кашыклап,
Акрын-акрын ычкынырсың

сине кыскан капкыннан.
Түземең хәтта давылдан
тотар саклап, ышыклап.

* * *

Ашыгу, кызулык белән
ирешмәссең җиңүгә.
Йөгәнсезлек белән нәфрәт
һич китермәс юньлегә.
Усаллыкка җавап бирмә
үтә кайнарлык белән —
Бар гомерең кайтып калыр
бары ике көнлегә.

* * *

Нияте изге адәмнең
бар гамәле уң була,
Эшләре белән сүзләре
бер-беренә тиң була.
Авызыннан сибелгәннең
тузга язмаган сүзләр —
Тырышлыгы, сүзе кебек,
җилгә очып юк була.

* * *

Хаким булырга рухыңның
чиста булуы кирәк
(Тик хакимнәр арасында
андыйлар үтә сирәк),
Хакыйкатькә — дус, рияга
дошман булырга тиеш —
Бары шул очракта гына,
халкым, дип тибәр йөрәк.

* * *

Һәркемгә сәләт Ходайдан
чама белән бирелгән:
Яшь егет кыю булса да —
тәҗрибә аз белемнән.
Беркем дә бөтен җиһаннан
була алмый хәбәрдар:
Беразы — ачык, калганы
ак томанга төрелгән.

* * *

Күзләрем күрмәсен иде
телемнең җуелганын,
Ата-баба йоласының
җиремнән куылганын.

Милләтемнең үсүенә
ярдәмен бирсен Ходам —
Күтәрә алмам халкымның
корбанга куелганын.

* * *

Кемнең кем икәнен тану —
үзе бер зур хикмәттер,
Кемнәр бүре, кемнәр сарык —
тормыш үзе күрсәтер.
Сарык тиресеннән бүре
чыгачак, бер көн килеп.
Кальбенең нинди булуын
кылган гамәле әйтер.

* * *

Хәйләләмә моннан ары —
карт төлкедәй калкынма.
Гел хәйләләп йөри торгач,
бер каптың бит капкынга.
Сүзеңнең бер мәгънәсе юк —
билчәннән дә болайрак,
Риалы сүзеңне сөйлә
бары зәгыйфь акылга.

* * *

Җаныма якын итәрмен
изге җанлы булганны,
Абруе белән тиң яки
миннән өстен торганны.
Җебегән белән эшлексез
пар да, дус та булалмас —
Картлар белми әйтмәгәндер,
белеп тарт, дип, юрганны.

* * *

Яманлыкны күмеп куеп,
юл бирсәк иде башка,
Гранит, бетон калаларда
гөлләр үстерсәк ташта,
Кешеләрнең күңеленә
тулыр иде матурлык —
Җимерү, вату турында
уйламас иде башка.

* * *

Чүп өеменнән һичкайчан
зөбәрҗәтләр эзләмә,
Үзеңә тиң булмаганны

тының бетеп күзләмә.
Тегесе дә, монысы да
кермәс синең кулыңа —
Тырышлык бушка китте дип,
аннан ары сүзләмә.

* * *

Йөрәктән ташкан хисеңне
кире яшереп куйма —
Саф сулы челтер чишмәгә
юлыктым диеп уйла.
Чишмәңнең суын эчер син
иң кадерле кешеңә —
Тыеп торып хисләреңне,
берүк гаклыңны җуйма.

* * *

Тәмам эшне кирәк әүвәл
күрсәтергә остага.
Оста мактаса, бу хезмәт
күп очракта дус таба.
Дус янында дошман туып,
йөри башлый чүп эзләп —
Миннән узмасын, дип, эшкә
шакшы ялганын яба.

* * *

Хезмәтеңне сөеп башкар,
эзе калырлык итеп.
Дәрәҗәгә ирешмәсәң,
күңелең булыр китек.
Эшен хөрмәт итмәгәннәр
тиз югалтыр абруен, —
Даның онытмаслык итсен,
күп гасырларга китеп.

* * *

Ата-анаңны хөрмәт ит,
кан кардәшеңне зурла.
Ачуың килгән чакта да
үпкәдән ары узма.
Яманлык алардан килмәс —
моны аермас булма,
Юк сәбәп белән арага
чикләүче ызан сызма.

* * *

Яман дәртне тыяр өчен
безгә көч бирә Күкләр,

Мондый көч булмаса, аны
йөгәнли алмый күпләр.
Бозыклык һәм явызлыкны
тоткарлама яныңда —
Алар сине генә түгел,
бөтен нәслеңне «чүпләр».

* * *

Сүзләреңдә генә түгел,
эшеңдә дә гадел бул.
Акыл һәм канун кушканча
булсын син барасы юл.
Исеңнән чыгарма берүк:
ялган тудыра нәфрәт —
Үчләшүгә күчеп кайчак,
үлемгә китерә ул.

* * *

Җиңел генә кергән байлык
шулай тиз чыгып китә
(Бәрәкәтсез булганына
борчылу җанны өтә).
Кызыкмагыз андый малга —
рәхәте булмас алда:
Гөлт итеп кабынган ут та
балкый да сүнеп бетә.

* * *

Язмыш салган сынауларны
сабырлык белән күтәр.
Сабырларга Ходай бирмәс
күтәрә алмас йөкләр.
Авырлыкны җиңү юлы
төрледән төрле булыр,
Намусың чиста калырлык
юлны сайла да үткәр.

* * *

Әгәр дөньяда яман сүз
хаклыктан өстен чыкса,
Зирәклек чәчелгән җиргә
янәшә ялган шытса,
Сайлаганың киләчәктә
кайгыларга салмасын.
Җиде кат үлчә, бер кат кис,
акылың китәр юкса.

* * *

Башың җитмәгән эшләргә
беләм мин дип алынма —

Башкарып чыга алмасны
өеп куяр алдыңа.
Шунда барыбер ачылыр
синең бөтен асылың.
Әйтерләр: «Әллә зәгыйфьлек
килгән моның аңына?»

* * *

Тормышыңны тәртипкә сал,
зур байлыкка омтылма,
Чамасын белми мал җыеп,
дөньяларда онтылма.
Рәнҗештән кергәне — хәрәм,
бетмим, дисәң, тотынма,
Чиксез нәфсең «ярдәмендә»
кыңгыр эштә тотылма.

* * *

Кем башканың «канын эчә»,
бәгыре каты булып.
Килер вакыт, үз җаны да
көячәк, хәсрәт тулып.
Рәнҗеш һәм каргыш уклары
йөрәген челтәр итәр:
Гөрләп яшисе урынга
саргаер, кинәт сулып.

* * *

Сөю уты яктың, шашкын хисләр сибеп,
Ярсу дулкыннардан «ярда» ап-ак күбек.
Миңа күчте нурың, торам балкып, көлеп.
Яңа үсеп җиткән асыл мәрҗән кебек.

* * *

Мәхәббәттән тик наз көткәннәр
Күз яшьләрен күбрәк түккәннәр.
Сөю юлын кат-кат үткәннәр
Көл булганчы янып беткәннәр.

* * *

Гаскәр кебек ябырылган газаплар,
И Ходаем, тагын күпме азаплар?
Яннан китмичә сагалый борчулар,
Әйтерсең тезелгән атлы казаклар.

* * *

Гармуның бер якта торсын,
кыл кубызлар уйнаганда.
Оста барда телеңне тый,
дәшмә, факир уйлаганда.
Гыйбрәт алып торсын яшьләр,
олыларны зурлаганда,
Бозау боз яласын, сыер
тозны ялап туймаганда.

* * *

Йомшак, татлы җил исмәсә,
чәчкәләргә хуш ис сеңмәс.
«Эчләренә корт кермәсә»,
тавыклар да җырлый белмәс.
Йөрәкләрдә хис ташмаса,
күңелгә дәрт, коткы кермәс.
Сайрар өчен хәтта былбыл
зифа талга очып менмәс.

* * *

И көнләшү! Җәзаң каты —
өеп-өеп бирәсең.
Бәгырьгә хәнҗәрең кадап,
ярага тоз сибәсең.
Хатын-кызны, ир-егетне
син бертигез күрәсең —
Акылын юкка чыгарып,
көл иткәнче «сөясең».

* * *

Йөрәктә сөю булмаса,
күңелдә — дөм караңгы,
Хәтта балкыган кояш та
яктыртмый шул араны.
Мәхәббәте сүнгәч, ай да
салкын баз булып кала.
Сагышка сарылган күзләр
күрми акны-караны.

* * *

Бу заманда һәр адымда
явызлык көтеп тора.
Аңа каршы тору юлын
аксакаллардан сора.
Аерылу белән сынап,
хәсрәтне өсти кайчак.
Бәхет килсен дип ялварыйк,
башларны ора-ора.

* * *

Туган өйнең капка баганасын
кочагыма алып тын тордым.
Чәлпәрәмә килгән йөрәгемнең
кисәкләрен җанга тоттырдым.
Эз суынган салкын идәненең
үбеп чыктым һәрбер тактасын,
Аннан күзьяшь белән юып алдым —
язмышымны читкә оттырдым.

*2006*

## Газәлләр

* * *

Язмышым сызган юллардан һаман ялгыз атладым:
Мәңге таяныч булырлык терәгемне тапмадым.

Үтеп бара гомерләрем сәхрәләр, чүлләр аша,
Иреннәр кибеп ярылды — кояш миңа тоташа.

Яндырды да, көйдерде дә шул кояшның нурлары,
Һаман михнәткә чыгарды язмышымның юллары.

Күтәрдем мин ул михнәтне, урталай бөгелсәм дә,
Сиздермәдем башкаларга, сөенсәм, көенсәм дә.

И Гөлчәчкә , бу тормышта ничек авыр булмасын,
Ходай күрсәткән сукмактан барыбер тайпылма син!

*2003*

* * *

Янымда башка булса да,
алдыма төшкән идең.
Миңа бәйсез тормышыңнан
шундук ваз кичкән идең.

Үткәннәрне сагынудан
аккан иде күз яшем.
Син аларны, бергә җыеп,
бәлзәм дип эчкән идең.

Эзләремә басып йөрдең,
китмәсен дип чит-ятка.
Гел янымда булыр өчен
дөньяма күчкән идең.

Беркемгә якын җибәрми,
юлымны кискән идең.
Гашыйк итәргә тырышып,
үпкән дә кочкан идең.
Асыл ташларга тиң куеп
күтеп алдың сүземне.
Сүзләремнән канатланып,
күкләргә очкан идең.

Мине шашып сөюеңне
җырларыңа күчердең:
«Мин дөньяга сыймый идем,
сыйдым кушучка», — дидең.

Инде хәзер чәчләрең — чал,
йөзеңдә — буразналар.
Үтте гомер — калды күмер,
янганга эчтән, димен.

*2006*

* * *

Дистәләгән еллар элек, башым хәсрәткә тарып,
Җаным үтәли тишелде, өзлексез яшем тамып.

Колагымда — ыңгырашу, күзләремдә — тилмерү.
Хәсрәтем гомерлек булды, йөрәккә уелып калып.

Күкрәк сөтем балам гомрен озайтты тик беразга.
Сулды йөзе, сүнде күзе, бер тәүлек уттай янып.

Кулларымда җанын бирде — күзләрен йомды арып.
Ташлады-китте, башымны тирән кайгыга салып.

Озын керфек, кыйгач кашлар күз алларымнан китми.
Сурәте һаман саклана, күз алмасында калып.

И балам, мине калдырып, кайларга киттең, кая?
Илерү кайтты әйләнеп, бәгырьне меңгә ярып.

Бала хәсрәтеннән авыр ни бар җирдә, Гөлчәчкә?
Бу хәсрәтне дә күтәрдең, башкадан гыйбрәт алып.

*2003*

* * *

Җанкисәгем, син һаман да минем моңлы җырымда,
Йөрәгем — синең кулыңда, күзем — кайтыр юлыңда.

Ак чәчкәләр җыйган идек гашыйклар болынынннан,
Иң матур җыр туган иде яратышу турында.

Күз алдыма киләсең дә, тетрәнә бөтен җаным.
Бер мизгелгә дә югалтмыйм — син һәрвакыт уемда.

Йөгереп килеп чумар идем капкындай кочагыңа.
Рәхәт бер кайнарлык тоям бары синең куйныңда.

Сибелә чәчәк, түгелә җыр мәхәббәт иңгән җирдә.
Сөюнең керсезе туа хис дәрьясы буенда.

Тагын җыр язды Гөлчәчкә, каләмен хискә манып,

Бу җыр — янә бер мәдхия илаһи көч турында.

*2003*

* * *

Суга иелгән талларга былбыл килеп кунамы —
Тал — былбылсыз, былбыл талсыз бу дөньяда буламы?

Каен белән чагыштырма сылу кызның гәүдәсен —
Төз үскән матур кәүсәнең хәрәкәте буламы?

Зарыгып көтмәсәң, килми очрашуның рәхәте —
Чәчкә аткан роза гөле чәнечкесез буламы?

Сөйгәнем белән аерылу сызлавына түзәмен —
Мәхәббәттә түзми янган берәр гашыйк буламы?

Йөрәгемнең яралары, син карауга, җөй булды —
Сөеп туймаган карашлар бер сихәтсез буламы?

Җимерелгән диварларның шәүләсе төшмәс җиргә —
Күңелдән киткән ярларның шәүләләре буламы?

И Гөлчәчкә, ташкын хистән күңелләрең туламы —
Синең дә челтер чишмәңдә су кипкән чак буламы?

*2003*

* * *

Чын сөюне татымаган, мәхәббәттән шашынмаган
кеше дә була икән.
Кызык: андый адәмнәрнең күңелләре, йөрәкләре
ни белән тула микән?

Зур сынаулар алып килгән, хәсрәтләргә күмеп йөрткән
үтә авыр көн туганда,
Юатучы, тыны бетсә, үз сулышын сулатучы
кешесе була микән?

Бар дөньясын оныттырып, сөю уты үзәкләрен
өтеп-өтеп алмаса да,
Күзе төшкән, якын иткән җанны уйлап сагынудан
йөзләре сула микән?

Гашыйклар янында йөреп, өзелеп сөюләрен күреп,
көнчелек уты кабынса,
Бөтен җанын-тәнен биреп, үлеп яратасы килеп,
кызыгып куя микән?

Мәңгелек гашыйклар булып, һушлардан язарлык итеп
янып сөясе килгәндә,
Көткәннәре акланмаса, кемнәргәдер үпкә тотып,
кайнар яшь коя микән?

И Гөлчәчкә, мәхәббәттә яндың, көйдең, хисләреңне

мәңге сулмас гөлгә төрдең —
Күңелләрең, бәгырьләрең сөюнең илаһи көчен
һаман да тоя микән?

*2003*

* * *

Иреннәрең балдан татлы — мондыйлар сирәк, дидең.
Беркемне дә кагылдырма — үземә кирәк, дидең.

Күзләреңне каймалаган керфегең — тирәк, дидең.
Сыендырма башкаларны — үземә кирәк, дидең.

Күңел дәрьяңда йөзәмен, рәхәттән изрәп, дидең.
Башка беркемне чумдырма — үземә кирәк, дидең.
Тының кайнарлыгы өтә — сызамын көйрәп, дидең.
Сүзең уты дәрман өсти — миңа шул кирәк, дидең.

Синнән иңгән зур ләззәттән каламын иңрәп, дидең.
Сине беркемгә бирмәмен — үземә кирәк, дидең.

Китәсең, җаныңны калдыр — йөрәгем төргәк, дидең.
Гөлчәчкә, алдана күрмә — үземә кирәк, диген.

*2003*

* * *

Мин Ходайдан күпме үтендем,
йолдызларны урап мең килдем.
Күз яшемне гөлгә эчердем —
тиңем мине күрми микәнни?!

Ничә еллар бөреләнмәгән
гөлем чәчкә атты күзьяшьтән.
Ә мин сулып, койдым чәчкәмне —
парсыз йөрүләрдән микәнни?

Юлларыма чыккан күп лә ул,
шашып сөйгәннәр дә сер түгел.
Тик канатым һаман ул түгел —
үз насыйбым килмәс микәнни?

Кай тарафта икән эзләре,
күрмәс булды мәллә күзләре?
Теләкләрем нигә үтәлми —
зарыкканны белми микәнни?

Бәлки әле, ул да парсыздыр,
өлешенә дигән ярсыздыр.
Дөнья буйлап эзләгән яры
мин икәнне белми микәнни?

И Гөлчәчкә, берүк сабыр бул,
сабыр төбе, диләр, саф алтын.
Бәхет ул ярата көткәнне —
син шуны белмисең микәнни?

*1993*

* * *

«Сөя алырсыңмы мине? —
ярым итеп сайладым.
Өеп-өеп бирәм сиңа
хисләремнең кайнарын.

Хыянәтләргә юл куйма —
күтәралмам ул йөкне.
Хурлыгы җанымны сытар
һәм юк итәр аннары.

Миннән башка беркемгә дә
елмаеплар карама,
Юкса көнләшү зәхмәте
гел агулар каннарны.

Гайрәтле ир булсам да мин,
чыдамам кимсенүгә.
Барын да хәзер үк белим,
йөрмәс өчен алданып.

Шартларыма күнәр булсаң,
китик атлап бер эздән.
Риза бул, җанымны терелт,
йөрмә инде сайланып», —

Дидең миңа, рияланмый,
бары турысын ярып...
Тик таллары сынып төште
икәү басып сайрарлык.

*2006*

* * *

Юклыгыңны белеп яшәү —
мең газапның берседер.
Тилмерүләр дәрьясына
бәхет кошы кермидер.

Йөздә елмаю торганга,
авыр дими берсе-бер.
Җанымдагы өермәне
һичбер адәм белмидер.
Мәхәббәттә ут ялкыным
көл итте — кырга сипте.
Хәлиткеч囲 эштә кайнарлык
акылыма сеңмидер.

Кайнар башлар өзеп куя
тотып алган урыннан.
Хис белән акыл юлында
хисләр алдан йөрмидер.

И Гөлчәчкә! Хисне син дә
буйсындырдың акылга.
Бәлки, шуңа да эргәңә
бәхет кошың килмидер.

*2006*

* * *

Үзеңне өстенгә санап, һаман кеше хурлыйсың,
«Тегермәнең шәп тарта соң» — бер дә уйлап тормыйсың.

Пычрак аткан бу сүзләрең телеңне тешләтмәсен.
Явызлык кылып, үзеңнән яхшылыкны урлыйсың.

Башканы чүпкә чыгарып, гел үзеңне зурлыйсың —
Бу дөньяда миннән кала оста юк, дип уйлыйсың.

Синең осталыкны да бит әле раслату кирәк.
Хөсетлек эчендә кайнап, ничек үзең туймыйсың?

Шул агуың, бер көн килеп, тик үзеңне агулар,
Котылалмассың хөкемнән — ник башыңны ормыйсың.

И Гөлчәчкә, бөтен сүзең алдан үлчәнгән булсын,
Авызыңнан сүз чыкканда, акылың кизү торсын!

*2007*

# Мөсәмманнәр*

* * *

Хатларыңда яздың:
— Син булмагач, киптем:
гел сагышта бит мин.
Җаным сыкравыннан
ничек качып китим?
Синнән башка хәзер
читлектәге кош мин —
Бәргәләнәм һаман —
ничек сабыр итим?
Нишләттең син мине?
Исәрләнәм бит мин.
Төнем көнгә күчте —
ничек дөнья көтим?
Саклыйм назларымны,
башкаларга түкмим.
Кушыйк язмышларны —
синсез бетәм бит мин!

Кояш йөзләреңне

күрми күрәм бит мин.
Атлап йөрүләрең
күз алдымнан китми.
Кодрәтлем син минем,
Алиһәгә тиңем,
Тотма ут эчендә —
көеп үләм бит мин.
Гомер йомгагымны
тагын күпме сүтим? —
Кайт, дип әйтүеңне
мең ел көтәм бит мин.
Саклыйм назларымны,
башкаларга түкмим.
Кушыйк язмышларны —
синсез бетәм бит мин!

* * *

Тормыш куйган сорауларга
юньле җавап тапмадым,
Гаҗизлектән йөрәгемне
мең җәрәхәт каплады.
Михнәтләр тулы дөньяга
берьялгызым атладым,
Йөрәгем җәрәхәтенә
һичбер дәва тапмадым.
Син генә дип, чит-ятларга
хәтта керфек какмадым,
Ә син, моңа ышанмыйча,
миңа ачу сакладың.
Ничә еллар бары сиңа
күңелемне багладым,
Тик синең пар түгеллекне,
кызганыч, соң аңладым.

Ачу тулы күзләреңне
куе томан каплады —
Көнләшүдән яуган сүзләр
күңелемә ятмады.
Мәшәкатьле бу дөньяга
синнән башка атладым,
Тик шулай да йөрәгемнән
сине алып атмадым.
Читләшсәм дә, мин бит сине
беркайчан да сатмадым.
Кайда йөрсәм дә, һәрвакыт
ышанычың акладым...
Ничә еллар бары сиңа
күңелемне багладым,
Тик синең пар түгеллекне,
кызганыч, соң аңладым.

*2003*

# Мөстәзадлар*

* * *

Күл камышыдай төз егет
бүлде барыр юлымны —
Исем китмәгән иде.
Үземнән җибәрмим, диеп
тотып алды кулымны —
Арттан йөртмәгән идем.
Күземә карады сөеп,
алмыйм хәтта тынымны —
Сүнеп бетмәгән идем.
Йөрәккә ут якты өеп,
күреп нәфис сынымны —
Җанга кертмәгән идем.
Хәзер, саф сөюен белеп,
үзем алмыйм кулымны —
Моны көтмәгән идем.

* * *

Йөрәгемнең иң түренә
салдым сөю хисемне —
Яшердем нык тирәнгә.
Хисемнең якты җиренә
яздым синең исемне,
Сине өзелеп сөйгәнгә.
Мендем мәхәббәт үренә,
алып синең төсеңне —
Синсез янып көйгәнгә.
Анда синең йөз күренә —
сыный минем көчемне,
Түзәрме, дип бу хәлгә.
Салдың сагышлар чиренә
хисеңә тиң җисемне,
Тилмерсен дип бер мәлгә.
Киттең айрылар иленә,
калдырып сөючеңне —
Җансыз дип белдең мәллә?

*2006*

# Мөхәммәсләр*

* * *

Сине көтеп ала алмый интектем мин,
Төннәремдә мендәр тешләп яшь түктем мин,
Язмышымны бер чорнадым, бер сүттем мин,
Сине йөрткән сукмаклардан йөз үттем мин,
Эзләгәнем табалмадым — ни кызганыч!

Тавышыңны ишетим дип колак салдым,
Һичбер аваз килмәгәнгә гаҗиз калдым,
Килер юлларыңны күзләп тәмам талдым,
Керфекләрем янә кайнар яшькә мандым,
Юлың ятмый бу якларга — ни кызганыч!

Бөялеп торган хисләремнән кайчан тулам,

Һаман син дип яшәгәнгә кибеп сулам,
Синең хактагы уйлардан качмак булам,
Күңелемне башкаларга ачмак булам,
Тик буйсынмый йөрәккәем — ни кызганыч!

Юлларыма киртә булып нигә яттың?
Дөрли-дөрли шашкан утлар нигә яктың?
Бәгыремә нинди уклар киереп аттың?
Җанга салган кармагыңа килеп каптым,
Ычкыналмыйм кармагыңнан — ни кызганыч!

* * *

Милләтеңнең бөеклеген онытма,
Үз җиреңне каплаттырма «болыт»тан,
Сакла аны давыллардан һәм уттан,
Дошманнардан ябырылган мең уктан —
Бары шунда яшәп калыр милләтең.

Мохтаҗларга изгелекләр кыла бел,
Үзеңә кылган яхшылыкны күрә бел,
Күңелеңне шәфкатьлеккә төрә бел,
Азгынлыкны, явызлыкны сөрә бел —
Бары шунда абруй алыр милләтең.

Бисмилланы әйтеп башла юл башың,
Һәрвакытта сөю булсын юлдашың.
Башын иеп, сәлам бирсен кордашың,
Синең белән горурлансын чордашың —
Бары шунда сине таныр милләтең.

Сөйсәң илне, сөйсәң ата-анаңны,
Истә тотсаң һәрчак газиз Ватанны,
Тиз танып, төзәтсәң ялгыш-хатаңны,
Каршыласаң намус белән һәр таңны —
Бары шунда дан казаныр милләтең.

* * *

Дөньяң онытып үпкән эзләр әле дә яна,
Ни хикмәттер, хис-тойгылар һаман яңа:
Бер-беребезне эзли-көтә күзләр тала,
Ә телләрдән сүзләр түгел, гөлләр тама —
Бу илаһи хистән күпләр мәхрүм кала.

Ничә еллар тыелып килгән хисләр ташты,
Күңел түрендәге хыял чынга ашты,
Бәйгеләрдә чапкан аттай йөрәк шашты,
Санга сукмыйча вакытны һәм дә башны —
Кемнәр шулай сөя микән бездән кала?

* * *

Газаплардан сынып төшкән күпме кеше күрдем мин,
Хәсрәтләрдән агу эчкән күпме кеше күрдем мин,
Изгелек эшләп, нур чәчкән күпме кеше күрдем мин,
Бер-берен сөеп яшәгән күпме кеше күрдем мин,
Тик үлемнең барысын да тигезләвен күрдем мин.

Уңганлык белән ялкаулык — һәрвакыт капма-каршы,
Ялкауларның көнчелеге — ямьсез низаглар башы,
Җанын мәче тырнаганга, тамактан үтмәс ашы,
Хөсетлеге куенында тотар һәрчак үч ташы —
Шул ташларның күз чыгарып, баш тишкәнен күрдем мин.

Сакланырга кирәк һәрчак сүзендә тормаганнан,
Күзеңә карап, кадерле кешеңне урлаганнан,
Иң якын дустын барсына бетереп хурлаганнан,
Бернинди әдәп-канунга буйсынып тормаганнан,
Чөнки аларның күзендә җимергеч көч күрдем мин.

*2006*

# Мөрәббәгъләр*

* * *

Сөя дип әйтеп буламы — газабында көймәсә,
Бар дөньясын оныттырып сөелмәсә, сөймәсә,
Үзе янып, сөйгән ярын ялкынына төрмәсә? —
Ярата дип әйтеп булмас, бу хисләрне белмәсә.

Батыр дип әйтеп буламы — яу кырында йөрмәсә,
Дошманны юк итәр өчен көрәшләргә кермәсә,
Ябырылган илбасарны җиңмәсә һәм сөрмәсә? —
Кыю диеп әйтеп булмас, бу эшләрне белмәсә.

Даһи дип әйтеп буламы — акыл хисне төрмәсә,
Яманлыкны, явызлыкны үткен күзе күрмәсә,
Чын йөзен күрсәтмәс өчен мең төрлегә төрләнсә? —
Бөек диеп әйтеп булмас, эш күрсәтә белмәсә.

* * *

Ап-ак чәчәккә күмелгән алмагачка кундым да
Сандугач булып сайрадым мәхәббәтем турында.
Сөйгән йөрәкләр очраша ике гашыйк юлында —
Тик шул кавышу сәгате бары Ходай кулында.

Көтмәгәндә аерылу кисте куйды юлларны,
Гыйшкым белән очрашуга янә берәр юл бармы,
Күрешүләр насыйп булса, җанга шатлык туллармы? —
Тик шул кавышу сәгате бары Ходай кулында.

Иртә сүтәм, кич тә сүтәм сәгатьнең минутларын,
Һәр мизгел кабыза җанда сары сагыш утларын,
Шул утлар, бәлки, яктыртыр аның килер сукмагын —
Тик шул кавышу сәгате бары Ходай кулында.

* * *

Бәгыремә әрнү-сагыш тулмаса,
Телләреңә яман сүзләр кунмаса,
Төннәремдә яшьле мендәр тормаса —
Кадерленең кадерлесе булырсың.

Әйтер булсаң телеңә ни килгәнне,
Ишәр булсаң мин тилмереп өйгәнне,
Әйләндерсәң яшькә минем көлгәнне —
Утта көеп, кара күмер булырсың.

Эшләреңне киңәшләшеп эшләсәң,
Беркайда да түбәнлеккә төшмәсәң,
Җаның сатып, яманлыкка күчмәсәң,
Кадерленең кадерлесе булырсың —
Йөрәгемнең иң түрендә торырсың.

*2006*

# Тәрәҗҗибәнд*

* * *

И җаным! Сиңа багышлап
язам бу сүзләремне —
Исән булсаң, укыр идең
чылатып күзләреңне.
Көтмәгәндә китеп бардың —
каралттың көзләремне,
Сине югалту хәсрәте
саргайтты йөзләремне.
Күргән саен кочып алып,
күмдең кайнар назларга,
Моннан гайре ишеталмам
иркәләү сүзләреңне.
Аеры йөреп сагыныштык —
юллар гел кисешмәде,
Кисешкән чакта һәрвакыт
эзләдең күзләремне.
Өзелеп-өзелеп сорар идең:
«Син мине эзләдеңме?» —
Белә идем гомер буе
үзәгең өзгәнемне.
Күзәттең яшертен генә
баскычлар тезгәнемне,
Баскычлардан менгән чакта
калган чук эзләремне.
Күрә идең бит үзең дә
боларны сизгәнемне.
Сизгәнемә кыенсынып,
теш кысып түзгәнеңне...
Син бакыйга киткән көннән
бернәрсә дә көтмимен,
Янымда үзең булмагач,
берни өмет итмимен.

И җаным! Юксынуымны
сиздерә алсам иде,
Бакыйдан терелеп кайтып,
фанида калсаң иде.
Беренче күрешкән кебек,
яңабаштан җан атып,
Яулар өчен йөрәгемнең
ишеген каксаң иде.
Ачып кертсәм сине анда,
рәнҗетмәсеңне белеп,
Тирән җәрәхәтләренә
дәвалар япсаң иде.
Беребез өчен беребез
яшәгән чактагы күк,
Яшь баладай сөеп, мине
күтәреп алсаң иде.
Күкрәгеңә кыса-кыса,
җан җылысына төреп,
Кулларыңнан төшермичә,
үбеп йоклатсаң иде.
Элеккечә янып-көеп,
и бәләкәчем, диеп,
Бары тик назларың белән
күңелгә ятсаң иде.
Бөтен зәхмәттән арынып,
инде борчуга тарымый,
Исән-сау килеш күрешү
юлларын тапсаң иде...
Шулай да син «киткән көн»нән
бернәрсә дә көтмимен.
Үзең янымда булмагач,
берни өмет итмимен.

*2006*

# Кыйтгалар*

* * *

Күрәм кайчак шундый адәмнәрне:
Буй-сыны да, йөз дә килешле.
Әмма үзе — хайван,
әдәп керми калган.
Эче белән тышы килешми:
Әйтерсең ул — бер хат,
бизәк төшереп язган,
Ләкин эчтәлеге
үтә дә бер ялган.

* * *

И бичара! Күпме чаптың
байлык арты байлык куып.
Алтын белән көмеш сиңа
гомер бакый булды богау.

Тормышың кордың мактанып,
шул байлыгың белән бизәп,
Бала үстерәсең килде
бары картайгачтын кисәк,
Тик булмады: китте рәтең,
чәчләрең күптән агарды,
Ата-анаң, онык күрми,
дөньялыктан китеп барды.
Кемгә кала бу байлыгың?
Җавап көтә шушы сорау.

* * *

Туган чакта бар кеше дә тигез була,
Белем белән сәләт безгә соңрак тула.
Нәселнең нинди булуы әүвәл башта мөһим түгел:
Акылы һәм зирәклеге иң беренче чутта тора.
Элеп куелган кылыч та саф алтыннан арзан була;
Көрәшкә керсә, бәясе бар нәрсәдән кыйммәт тора.

* * *

Сүз — бәһасез. Кычытып торса да телең,
Кирәксез сүз сөйләгәнче, дәшмәвең мең кат яхшы.
Тыңлап кына утыручы әйләнә дә зирәк затка,
Акылы белән аера: кемнәр — керсез, кем — шакшы.
Теләсә ни сөйләнгәнгә тоттыра күрмә ташны,
Уйламый бәреп тишәчәк йә күкрәкне, йә башны.

*2006*

* * *

Итагатьле булыр өчен
дөрес тәрбия кирәк.
Теленнән гөлләр сибәрдәй
кеше гомумән сирәк.
Тупаслыкны байрак итеп
күтәргән адәм дә бар —
Андыйларның күңеле бозык,
фикер тирәлеге тар.

* * *

Үпкә-рәнҗүне тиз генә
күңелдән алып булмый.
Туктаусыз әрнеп торганга,
йөрәк-бәгырьне кыйный.
Телеп кискән шул кыенның
тирән ярасы кала,
Ярадан аккан кара кан
гөнаһсызны рәнҗеткәннең
үзен хәсрәткә сала.

*2007*

# Мөсәддәс*

* * *

Чәчләремне тарап үрдем
ике зур толым итеп.
Алар матурлыгын күрдең —
сокландың, ушың бетеп.
Сөю сөременә төрдең —
сүзләрең торам көтеп:
Буйсынырга әмер бирдең,
карашың белән өтеп.
Давыл булып җанга кердең,
бөтен дөньямны сүтеп.
Йөрәгемә ялкын өрдең —
куз булдым, янып китеп.

И сөйгән яр! Алтын көзне
чәчкә яуган яз иттең.
Сөю тулы чиксез сүзне
күңел бакчама сиптең.
Ут иттең дә ике күзне,
үзең үк көеп киптең.
Бәгырең канатып түздең —
мин сине «күрми» йөрттем.
Гел тибәрдем синең йөзне,
ә үзем көн дә көттем.
Хисләрне хисләргә үрдең,
үз булдың, парың итеп.

Тик язмыш торды ялгыштан,
чикне куя белмәдек.
Күп көннәр үтте алышта —
ни буласын күрмәдек.
Нигәдер гомер агыштан
ялгышларны сөрмәдек.
Җаннар сыкрап айрылышкан —
инде назга төрмәдек.
Ходай язган бу язмыштан
узыйк диеп йөрмәдек.
Йөрәгемә салкын өрдең —
юк булдым, калдың көтеп.

*2006*

* * *

Аклы күлмәгеңне кидең —
йөзең калды сафланып.
Чәчләреңне тарап үрдең —
әйтерсең лә ак мамык.
Рәнҗемәгез миңа, дидең —
рәнҗерлек эш тапмадык:
Бары тиргәп ала идең,

җаның белән саф калып,
Яна-көя саклап йөрдең
безне бала чактан ук,
Шул чагыңны күрер идем,
еллар — күптән аткан ук.

Әтине сөйдең чук итеп —
ансыз ризык капмадың:
Көтә идең, кичләр җитеп,
ачылганын капканың.
Тарткалашсак, тыннар бетеп,
усал сүзләр якмадың.
Чыбык кызса, түзем китеп,
безне һәрчак якладың,
Гаиләңне, гөлләр итеп,
яман күздән сакладың.
Шул чакны кайтарыр идем,
ел — дәвергә очкан ук.

*2007*

# Мөсәббә*

* * *

Иңнәргә төшкән бөдрәләр
егет күзен көйдерәләр,
Тулы ирен, туры борын —
баш югалтып сөйдерәләр,
Затлы нәсел, горур буй-сын —
затлы сүзләр өйдерәләр,
«Йөзеп» барган йөрешләрем
туктап сәлам бирдерәләр,
Тоткарланмыйм дигән чакта
кулдан тотып өлгерәләр.
Кызарталар йөзләремне,
ялкыннарга төрдерәләр:
«Аһ»лар итеп мактый-мактый,
йолдызларга менгерәләр.

Өтеп алган карашымнан
бик күпләрнең китте аңы,
Үлеп гашыйк егетләрнең
истән чыкты инде саны,
Тик язмышка яздырырлык
парымны көтәсе тагы,
Каршы барыйм мәллә дисәм,
юлларымда — тәртип тавы.
Урап үтмәк булам аны —
тотып тора әдәп сагы:
Кызарталар йөзләремне,
ялкыннарга төрдерәләр.
Ә үзләре, мактый-мактый,
йолдызларга менгерәләр.

*2006*

# Ялгышлардан торган язмышлар

## Сагыш үрләде йөрәккә

*(Эссе)*

Гомер узган саен бала чак, үсмер чаклар — балалар бакчасына һәм мәктәптә укып йөргән еллар ныграк сагындыра. Педучилищеда укыган, укыткан, университетта гыйлем эстәгән еллар да ул кадәр үк үзәкне өзми.

Сугышка кадәрле елларда Чистай шәһәренең комсомол комитетында эшләп йөргән әтиемне, шул авылда туып үскән буларак, Яуширмә авылы советы рәисе итеп җибәрәләр. Чистайдан күченеп килгәндә, олы абыем гына булган. Калган сигез бала Яуширмәгә килгәч туган. Ә мин — өченче. Әле дә хәтердә: мин балалар бакчасына йөргән елларда безнең үз йортыбыз юк иде. Эшкә җибәрүен җибәргәннәр, торыр урын тәгаенләп бирмәгәннәр. Шуңа күрә без әле әбиләрдә, әле әтинең апасында, аннары кайда буш йорт бар, шунда яшәдек. Беренче сыйныфка инде мин үз өебездән киттем: шомырт, миләш, алма агачлары үсеп утырган бик матур бакчалы бер иске йортны сатып алдык без. Берничә елдан яңасын җиткердек.

Әти авыл советы рәисе булып озак эшләмәгән. Сугыштан соң әни янына мәктәпкә укытучы булып күчкән. Әни башлангычта укытса, әти югары сыйныфларда физика, сызым, музыка, кайчакларда рәсем белән физкультура да укытты (укытучылар җитешми иде). Безнең берничәбез башлангыч белемне әнидә алды, ә югары сыйныфларда барыбыз да әти аша үттек.

...Узган гомерләрдән бер әйләнсәм,
Хәйран калып торам кайчакта.
Тугыз гына бала үсмәгән бит
Безгә генә дигән кочакта.

Дүрт ел саен кырык ике сабый,
Белем генә түгел, наз алып,
Әниемнән әтиемә күчкән,
Төрле сыйныфларга таралып...

Ул елларда безнең өй гөрләп тора иде. Ишек-капка гел ачык булды. Уен-көлке, елаш-бүлешләр (күп балалы гаиләдә мондый хәлләр бик табигый) белән беррәттән, өебездә һәрвакыт музыка яңгырап торды. Әти музыка уен коралларының барысында да диярлек уйный белгәнгә, баян, кыңгыраулы гармун, скрипка, курай, аккордеон, мандолина, балалайка моңнары безнең күңелләргә бала чактан ук сеңде. Шуңа күрә дә безнең һәркайсыбыз нинди дә булса уен коралында, ә кайберләребез берничәсендә уйный белә иде. Кайсыберебез әни кебек үк моңлы тавышка ия. Әнинең әнисе, әни үзе гомер буе шигырьләр язганга, безгә шигърият дөньясы да яхшы таныш иде. Кыскасы, без җыр-музыка, шигырьләр белән тәрбияләнеп үстек. Тормышны алардан башка күз алдына да китерә алмыйбыз.

...Ут алдылар. Кинәт салмак кына,
Моң таралды ачык тәрәздән,
Кыңгыраулы гармун башлаганны
Дәвам итте баян бераздан.

Баян тынып калгач, үзәкләрне
Скрипка кылы өздерде,
Арыса да, әни җыр башлады,
Гүя моңнар аңа көч бирде.

Без кушылдык әни җырларына,
Әти көе безне биетте.
Алар безгә салган барлык сыйфат
Киләчәктә безне үз итте...

Җае туры килгән саен, мин шул чактагы тойгы-хисләремне, без үскәндәге күренешләрне хәтеремдә яңарту һәм хыялымда гына булса да бала чакка кайту өмете белән авылыма юл алам. Ни гаҗәп: бу кайтулар миңа яңа газаплар, сагыну-сагышлар гына өстәп җибәрә. Авыл минем белән бергә олыгая сыман (бәлки, ул чыннан да шулайдыр), үсеп утырган үләннәренә кадәр икенче, кырдагы чәчкәләр дә ят, без белгәннәрнең, без күргәннәрнең күбесе юкка чыккан. Гөрләп торган өебез генә

түгел, шактый зур урамыбыз да буш; анда-санда ачылып киткән капкалардан кереп-чыгып йөрүче карт-карчыклар күренмәсә, бу урамда кеше яшәми дип уйларлык.

...Яшьлегемдә аткан гөлчәчкәләр
Кырларымны инде бизәми.
Капка төпләрендә әбекәйләр,
Кайттыңмы, дип кулын изәми.

Мине белгәннәрнең бик күбесе
Бер-бер артлы китеп барганнар.
Өй тутырып үскән балаларның
Тавышлары тынып калганнар...

Ә инде әби-бабайлар да китеп барса, урам бөтенләй юкка чыгачак, дигән авыр тойгы уяна күңелдә. Ә бит кайчан гына авылыбызда, алты йөздән артык хуҗалык булып, ике меңнән артык кеше яшәгән. Өч урында өч мәчетнең биек манаралары калкып торган. Кайда алар? Кем гаепле моңа?

Киткәннәр урынын тутырырлык балалар тумый хәзер авылда. Үсеп җиткән берсе шәһәргә китеп бара. Килеп урнашкан гаиләләр дә тутыра алмаячак бу бушлыкны. Әле ханнар заманында ук матурлыгы белән тирә-якка даны таралган бу тирәлек (Болгарда ислам динен кабул иткәндә, Алмыш хан Багдадтан килгән кунакларны, үзенең яраннарын тикмәгә генә Яуширмә җиренә алып килмәгәндер. Тикмәгә генә Ханнар буасы тирәсендә тирмәләр корып ял итеп ятмагандыр) гаҗәеп зур тизлек белән яман якка үзгәрә: күлләрдә, данлыклы Яушир елгасында су саега, буалар буылмый, чистартылмый. Балыклары мыжлап торган күлләргә дә игътибар юк. Беркемгә берни кирәкми, дөньяны бер көнлеккә корылган яшәү тәртибе, бар нәрсәгә битарафлык басты. Нәрсә бу? Ник болай? Нигә кеше киләчәкне уйламый?

Инде дистә еллар буш торган өебезгә кайту күңелдә гаять авыр кичерешләр уята. Безне җырлатып-биетеп үстергән, бишектән үк җыр-музыкага мәхәббәт тәрбияләгән, авырган чакларда, ни булды, балам, хәлеңне ничек җиңеләйтим, багалмам, дип, төннәр буе безне күтәреп йөргән, и-и-и, исән-сау кайтып җиттеңме, кызым (улым), дип, күз яшьләре аша елмаеп безне каршы алган әти инде күптән дөньяда юк.

...Балаларын нык яратты әти —
Алларыннан төшми үстек без.
Тырышлыгын, зыялыгын алып,
Дөнья киңлегенә күчтек без.

Әйбәт кеше иде безнең әти —
Берәгәйле горур бер мишәр.
Ни кызганыч, инде ничә еллар
Кабер өсләрендә җил исә...

Әлфия Афзалова, Рәшит Ваһапов, Илһам Шакиров, Мирей Матье, Шарль Азнавур, Ив Монтан, Алла Пугачева, Анна Герман һәм башка бик күп мәшһүр җырчыларның җырларын тыңлый-тыңлый бергәләп идән, кер юган, өй җыештырган, ашарга пешергән сеңелләрем дә юк анда. Капка-кураларны, бакча коймаларын төзекләндереп, карап, һаман саен ни дә булса төзеп, ясап торган; берьюлы дүрт-биш баянда өздереп уйнап, бөтен авылны шаккатырган абый-энеләрем дә юк анда — бар да таралышкан, төрлесе төрле шәһәрдә.

...Үзәкләргә үтеп юксындыра
Чыр-чу килеп үскән заманнар.
Кызганыч ки: алар кайтмас булып,
Гасыр аръягында калганнар.

Үтте-китте бар да бер мизгелдәй,
Риза булмый моңа — аң дулый.
Бала чакка эзләр юклыгыннан
Йөрәк-бәгырь өзелеп, җан елый...

Әти мәрхүм булгач, әни дә, ялгызы яши алмыйча, сеңлемә торырга китте. Шулай итеп, бала чакта бербөтен булып яшәгән балалар кайсы кая таралышып бетте. Олыгайган саен, аралар ерагайган саен бала чактагы туганлык хисләре кими бара кебек тоела миңа. Туып үскән йортта бергә туплап торучы кеше булмадымы, балалар шунда кайтып һәрдаим аралашып тормадымы, акрынлап бетә башлый икән ул якынлык. Һәммәсенең үз тормышы, үз мәшәкате. Анда-санда гына, туган көннәрдә, юбилейларда гына җыелышу барыбер бала чакка кире кайтармый. Сөйләнә торган сүзләр дә өстән-

өстән генә әйтелә. Ни булды безгә? Кайда ул бер-беребез өчен утка керергә дә әзер чаклар?

Шуларны тоеп, җаным әрни, күңелем сыкрый. Шул елларны, мөнәсәбәтләрне кире кайтарыр өчен әллә ниләр эшләр идем — хәлемнән килми.

Безне үстереп, укырга дип төрле якларга очырган өй искерә, чери. Без үскәндә көчкә үрелеп карый ала торган тәрәзәләр өй белән бергә җиргә сеңеп бара. Әти, ир балалар булмагач, капка кыйшайган, җиләк-җимеш бакчасында да тәртип юк.

...Авыл читендәге безнең йортның
Капка-куралары кыйшайган.
«Ташладыгыз безне» дигән кебек,
Ишек-тәрәзәләр турсайган.

Әле кайчан гына, чыр-чу килеп,
Тугыз бала үскән бу өйдә
Агачлары гына тирбәләләр
Әти салып киткән бер көйгә...

Азгын чияләр кызыл, ак, кара карлыган куакларын басып киткәннәр. Крыжовник картайган, шулай да энәләрен тырпайткан, якын китерми, янәсе. Кура да җимеш бирми. Алмагачлар корып бара. Шомырт белән миләш кенә бирешмәскә тырыша. Исән калган бердәнбер алмагач кына, без үскән елларны хәтерләтеп, күп итеп алма биргән. Кайтыгыз, ашагыз, сабый, үсмер чакларыгызны искә алыгыз, дия кебек ул. Әти карап-тәрбияләп торганда чиләк-чиләк бал биргән кортлар да күптән үлеп бетте. Башка кешене, хәтта әтигә һәрдаим ярдәмләшеп йөргән әнине кабул итә алмадылар алар. Шуларны күреп бәгырь телгәләнә. Ник болай соң бу дөнья? Бар нәрсәнең кадере китә.

Сыйныфташлар белән җыелып, бергә укыган елларны искә төшереп, туган мәктәбебездә, классыбызда утыру шатлыгыннан да мәхрүм без.

...Безгә белем биргән агач мәктәп,
Җимерелеп, җирдән сөрелгән.
Бала чакның моңсу ядкәрләре
Еллар тасмасына төрелгән...

Таштан салынган яңа мәктәп безнеке түгел инде. Шуңа күрәдер, бәлки, мәктәпне тәмамлаганга шактый еллар узса да, бергә җыелып сөйләшеп утыра алганыбыз юк.

...Кайда соң сез, минем сабакташлар,
Бергә уйнап үскән күршеләр?
Гомер офыклары якыная —
Насыйп булыр микән күрешүләр?..

Сыйныфташларымның, укытучыларымның кайберләре инде мәрхүм. Күрешеп булмады. Алар белән мин, әлбәттә, беркайчан да күрешә алмаячакмын инде. Исәннәр белән утырасы иде бер гөрләшеп!

Менә шул уйлар күңелгә һаман тынгылык бирми. Соңга калмыйк, соңга калмыйк!

Йөрәкләрне әрнетсә дә сагындыра, бик сагындыра туган авыл. Күңелем белән гел шунда ашкынам, бала чагыма кайтасы килә. Тик моның инде мөмкин түгеллеген, шул чактагы матурлыкның, самими хисләрнең кире кайтмаячагын аңлау йөрәкне парә-парә китерә.

...Бер кайтасы иде озак итеп
Кырларыңны иңләп йөрергә,
Урам тутырып аваз сала-сала,
Көтү кайтуларын күрергә.

Тик нишлим соң, ерактан ук танып,
Каршы алыр кешең булмагач,
Тәгәрәшеп үскән өй кырында
Гөлчәчкәләр үсеп тормагач,
Кайтып булмый икән, булмый икән,
Күпме сагынсаң да өзелеп.
Тилмерәсең икән еллар буе
Китәр өчен сине бер күреп...

Тик шулай да бер кайтасы иде. Анда кайткач кире якка алып киткән үзгәрешләрне, авыл халкының авыр тормышта яшәвен, мәдәният учакларының сүнә баруын, күбесенең тормышта «ярамаган тагын» дип, кул гына селтәп, начарлыкны, ялганны алга уздырып җибәрүен һәм башка шундый тискәре

сыйфатларны күреп борчыласымны алдан ук белсәм дә, җыенып бер кайтасы иде!.. Ни дисәң дә:

Сагындыра, үлеп сагындыра
Туган якның чәчкә-гөлләре.
Шул сагыну салган тирән сагыш
Йөрәгемә кадәр үрләде.

*1995—2005*

# Ана табан асты — оҗмах, диләр...

*(Парча)*

Еллар үтеп, шактый яшькә җитеп,
Ана булгач кына мин үзем,
Аңлый алдым әниемнең хәлен:
Күпме сабырлык һәм зур түзем
Кирәк булган аңа бу дөньяда
Давылларга каршы барырга,
Балалары горур үтсен өчен,
Ышанычлы юллар салырга...

Әйе, үзебез, ана яки ата булмыйча торып, аларның балалары өчен ут йотып, ул-бу була күрмәсен дип һәр адымын күзәтеп, авырып китсәләр — төннәр йокламыйча хәсрәтләнеп торуының сәбәбен аңлап җиткермибез шул. Баласы үсеп буй җиткәч тә, олыгаеп беткәч тә ананың борчылулары, хәсрәтләнүләре кимеми, арта гына бара. Тикмәгә генә: «Кечкенә бала — вак бәла, үскән саен өстәлә», — димәсләр иде. Ул гына да түгел, кияүгә чыгып (өйләнеп), читкә киткән очракта да бетми ул: оныклар мәшәкате дә килеп кушыла әле.

Әни! Син, бәлки, хәтерләмисеңдер дә: әле синең карыныңда чакта ук ягымлы сүзләреңне «ишетеп», йомшак кулларыңның җылысын «тоеп», шатлыгымнан тыпырчына, боргалана идем. Шул чакта ук миңа яратып «кызым» дип эндәшеп (ике абыем бар иде инде), назлап торуың өчен (үсә төшкәч, балалар күбәйгәч, андый назларга урын калмады калуын), рәхмәтле булып, миһербанлы бу җан иясен тизрәк күрергә, үзенең дә битләреннән нәни кулларым белән сыйпарга теләвем иде бу. Туктаусыз тибенүемнән, тыпырчынуымнан, әти белән (авыр туфрагы җиңел булсын!) икегез, бу бала биюче булыр, ахры, дип көлешкән идегез. (Алга китеп шуны әйтим, сүзегез рас килде: бүгенге көндә дә бию, бигрәк тә төрле халык биюләре — минем иң яраткан шөгыльләремнең берсе.)

Вакыты җитеп, якты дөньяга килгәч, мин синең җылыңны, назыңны ныграк тоя башладым. Әле дә «исемдә»: тугач та, яныңа имезергә салгач, үземнең ач икәнемне дә онытып, әни шул була микән инде, дип кызыксынып, озак итеп сиңа карап торганнан соң, синең тәнеңнең хуш исеннән, күкрәк җылыңны тоеп, рәхәтлектән йоклап киттем. Син мине уята алмыйча аптырап беттең. Борынымны да кыскалап карыйсың, битемне дә сыпыргалап куясың, маңгаемнан үбеп тә аласың, ә мин уянмыйм да уянмыйм. Мине яраткан әни бигрәк җылы инде, дип йоклыйм да йоклыйм. Син боларны онытып та бетергәнсеңдер инде, йә булмаса, буталып та беткәнсеңдер. Чөнки абыйларыма, эне-сеңелләремә дә җылыңны шулай өләшкәнсеңдер. Тугыз бит без. Ә менә мин «онытмадым» — һаман «истә».

Без шулай бер-бер артлы туа тордык, сиңа мәшәкатьләрне, борчуларны сала тордык. Син бит әле тугыз бала анасы гына түгел, укытучы да идең. Без белгәннән бирле синең сыйныфта һәрвакыт кырыклап йә аннан да артыграк бала була торган иде. Ходайның рәхмәте, ата-аналарның барысы да диярлек балаларын сиңа бирергә тырыша иде: яше җитмәгәнен дә, яше узганын да. Әниемнең ташып торган энергиясенә әле хәзер дә сокланып бетә алмыйм. Озын тәнәфестә авыл уртасындагы мәктәптән авылның бер читенә урнашкан өебезгә бала имезергә йөгереп кайтулары (бала туган саен кабатланган бит ул), баланы имезеп йоклаткач, ашамыйча да кире мәктәпкә чыгып чабулары җиңел булмагандыр. Мин ул мизгелләрне хәтеремдә кабат яңарттым:

...Тукта! Кем булыр бу? Атлый-чаба
Безнең өйгә таба кем килә?
Әни ич бу, озын тәнәфестә
Бала имезергә йөгерә.

Хәле китеп, азрак тын алыйм, дип,
Капка келәсенә тотынды.

Бераз басып торды тыныч кына —
Авыр сулышыннан котылды.

Ә аннары, кинәт каударланып,
Ачып керде авыр капканы.
Тизрәк-тизрәк, инде китү кирәк —
Сәгатьләп торырга кайтмады.
Тамак туйгач, изрәп йоклап киткән
Баласына ябып япманы,
Чыгып чапты, тамагына үзе
Әллә капты, әллә капмады.

Очты гына күпер, сулар аша,
Соңга калмыйм, диеп, дәрескә.
Сиксән дүрт күз берни сизми калды —
Шулай өлгер иде һәр эштә...

Әйе, өлгерлегең, җитезлегең, сабырлыгың булмаса, шундый зур йөкне тартып бара алыр идеңмени? Дөрес, әтинең ярдәме дә зур булды. Әмма йөкнең авыры күбрәк синең җилкәңдә иде. 90 яшеннән узып вафат булган әбием (әтиемнең әнисе) дә гомеренең азагында бездә яшәде, синең кулларыңда дөнья куйды. Кырыс табигатьле, мин әйттем, дип, әмер генә биреп торучы остабикә, бөтен авылга кендек әбисе булып торган «помещица»ны карау (авыр туфрагы җиңел булсын!) сиңа җиңел булмагандыр. Әле эшеңне дә тиешенчә алып барырга кирәк. Укучыларың нык яратты сине, эзеңә генә басып, күзеңә генә карап йөрделәр. Әйткән һәр сүзең аларга закон иде. Бу турыда карт әбиләргә әйләнгән укучыларың үзләре хәзер дә сөйли:

...Әй-й, апа җан, апа канатым!
И яраттык та соң без сине.
Бер әүлия урынына күрдек —
Синдәйләрнең булмыйдыр тиңе.

Син бит әле берни белми калдың,
Һәр көн кичен бергә җыелып,
Тәрәз буегызда күпме йөрдек,
Шаулашудан көчкә тыелып.

Пәрдә читләреннән күзли идек,
Ничек йөри, диеп, өендә.
Уйлый идек: ашый, эчә микән,
Йоклый микән башка кешеләр күк,
Нинди хәлдә, нинди киемдә?..

Ул гына да түгел, Саба якларыннан Чистайга килеп «адашып» калган чибәр, уңган кыз әти-әнисен, туган ягын, тынлы оркестрда, валторнада уйнап йөргән үсмер чакларын сагынуга түзә алмыйча, бөтен хисләрен, сагышларын, чит авылдан килеп, әтисенә кияүгә чыккан әнисе Әшрәфҗамал кебек, шигырь юлларына сала башлый. Без, бу шигырьләреңне укып, хәйран калган идек. Чөнки син аларны безгә үсеп җиткәч кенә укыттың. Каләмең әле дә дәфтәреңә ни дә булса теркәп куя. Югыйсә бит сиңа быел 85 яшь тулды.

...Кибәргә элгән җиреннән
Очты китте күлмәгем.
Читтә мәңге калырмын дип
Һич кенә дә белмәдем.

Туган җиремә кайтырга
Җыендым әллә ничә.
Тормышның әче җилләре
Туктатты җәлләмичә.

Гомер буе яна-яна
Калдым кара күмергә.
Туганнарымны сагынып
Яшәдем мин гомергә...

* * *

...Ярсып-ярсып уйнармын дип
Алдым кулыма гармун.
Гармун теленә күчсен дип

Күңелдәге барлык моң.

Гармун миңа буйсынмады —
Көем килеп чыкмады.
Сагыш тулы башкаемны
Төрле уйлар тукмады... —

дип яздың син, сагышларыңны басарга теләп. Сагынуларга түзә алмыйча аккан күз яшьләреңнең дәфтәр битләренә шигырь булып яткан юлларның кечкенә генә бер кисәге болар.

Әни! Бу сагышларыңны күпмедер дәрәҗәдә басар өчен, дөньяга без килгәнбез. Әтиемне өзелеп яратуың — «адашып калуыңның» иң зур сәбәпчесе. Әти дә гомер буе сине яратып яшәде (урыны оҗмахта булсын!). Яратмаслык идеңмени соң?

Безнең әни уңган гына түгел,
Чибәрләрнең булган чибәре.
Әти аны белеп сайлап алган,
Йөз гүзәлне читкә тибәреп.

Болыт кебек куе кара чәче
Дулкынланып төшкән таралып,
Зәңгәр күзләренең төпкелендә
Сөю назы торган яңарып... —

дип юкка гына язмаганмындыр инде.

Балаларыңа күчергән назың, күңелең җылысы, миһербанлыгың, әни, юкка чыкмады. Һәр балаң күңелендә урын алып, аларга дөньяда үз урыннарын табарга, зур тырышлык белән яшәргә, авырлыкларны, каршылыкларны җиңәргә, дәрәҗәләргә ирешергә ярдәм итте. Барлык балаң да, икешәр, өчәр, дүртәр дипломга ия булып, дәрәҗәле урыннарда эшләү белән беррәттән, өч балаң филология, философия, юридик фәннәр кандидатлары дәрәҗәсенә иреште. «Аттан ала да туа, кола да туа» дигән әйтем бар. Ходайга шөкер, әти белән син биргән тәрбия тугыз баланың берсенә дә азып-тузып йөрергә «рөхсәт» итмәде. Һәрчак тезгендә тотты. Синең үзеңә дә балаларыңның абруйлы булуын күрү — олы бәхеттер. Оныкларың да сез сызган юлдан тайпылмыйча барсалар, безгә дә, сиңа да әйтеп бетергесез шатлык китерерләр иде.

Әни! Янәшәбездә үзең булмасаң да, без һәрдаим синең барлыкны, синең күзәтүне тоеп яшибез. Һәр балаңа сузылган күз нурларың, җан җылың аша идарә итәсең син безнең белән.

Хәтереңдәдер, олы улың Ирекне беренче мәртәбә читкә чыгарып җибәргәч, йөрәгең белән еладың. Ә аннары, вакыты җиткәч, калган сигез балаң да бер-бер артлы төрле якка очып таралды. Безгә нибары 15—16 яшь кенә иде. Үсмер чак. Буының сыек булса, теләсә нинди ымсындыруга ияреп, теләсә кайсы юлга кереп китәр чак. Синең догаларың, изге теләкләрең, беренче чиратта, бишектән үк салган тәрбия саклады безне. Йөрәгеңне тугызга ярып, һәр балаңа үз өлешен биреп җибәргәнсеңдер син. Барлык гамәлләребезне тикшереп, яхшысын яманнан аерып күрсәтер һәм ялгыш юлдан саклап калыр өчен. Алардан саркыган кан бәгыреңә төшкәндер. Ничек түздең, әни?

Бәлки әле, үз балаларыңның, авыл халкының рәхмәте һәм хөрмәте сине бүгенге көнгә кадәр төрле авырлыклардан, хәсрәт-борчулардан саклап торадыр. Сиксәнгә якынлашкан көннәрдә биш метр тирәнлектәге базга аркаң белән егылып төшкәч, исән калмассың дип, нык курыккан идек. Ходаның рәхмәте, сыдырылу, күгәрүләрдән гайре бернинди сыну, тирән яралар булмады. Изгелекләрең өчен шушы рәхмәтләр, фәрештәләр булып канат җәеп, сине үлемнән саклап калгандыр. Ходайның рәхмәте киң: яхшы күңелле кешене ярдәменнән ташламый.

Моңлы, челтер тавышында, җырларында тирбәлеп үскән һәр балаң милли рухыбызны, телебезне, иманыбызны югалтмасын иде!

...Ул җырлары хәзер безнең моңда —
Без дәвамы аның җырының.
Ана табан асты — оҗмах, диләр,
Без чәчкәсе оҗмах кырының:
Әниемнең аяк эзе калган,
Җырлый-җырлый күз яшьләре тамган,
Әтиебез мәңге йокыга талган,
Шәфкать салган оҗмах кырының.
*2003*

## Хикәяләр

## Югалган алтыннар

— Алтыннарны кайсыгыз урлады?!

Ишекне бәреп түр якка килеп кергән Мөхетдиннең йөзенә менә-менә корбанына ташланырга торган ерткыч җанвар кыяфәте кергән: күзләрен кан баскан, тешләре ыржайган, үзе бөтен тәне белән калтырый иде. Эчкә үткәч, бу сорауны тагын бер кат кабатлады:

— Кайсыгыз алтыннарымны урлады?

Түр яктагылар, аның мондый чагын моңарчы күрмәгәнгә, ажгырып өсләренә килүче аждаһадан курыккандай котлары очып, бер мәлгә катып калды.

Мөхетдиннең бу сорауны өченче мәртәбә кабатлавы бүлмәдәгеләрне тораташ хәленнән чыгаргандай булды.

— Әйтегез яхшы чакта, алтыннарымны кем алды?

Беренче булып Мөхетдиннең, әле күптән түгел генә хатыны үлгәч, шәһәрдән алып кайткан, сәүдәгәр кызы булса да сатучы булып эшләп шомарып беткән һәм бер дә әдәп саклап тормый торган яшь хатыны телгә килде. Хәйләкәр, шома булуы өстенә баласыз хатыннарга хас шактый зәһәр дә иде бу хатын.

— Син нәрсә дип котырасың әле? Туктап тор бераз. Башта сөйләшеп аңлашырга кирәк. Каракны тоткач котырырсың, — диде. — Табылыр, табылмаса, алган кешесеннән таптырырбыз.

— Табыласы юк! — дип кычкырды Мөхетдин. — Эзләмәгән җирем калмады. Мин куйган урыны буш. Ул ике бөртек кенә түгел, бер янчык! Беләсезме анда күпме алтын?!

— Әти, син бездән шикләнәсең мәллә? Шулай булса, ялгышасың, безнең моңа бернинди катнашыбыз юк. Без әле синең ул кадәр алтының бар икәнен дә белми идек, — дип әйтергә җөрьәт итте олы улы Сәлахетдин.

— Тиктомалдан кая китәргә мөмкин! Өйгә каракларның кергәне юк. Сездән башка безнең өйдә кем йөри?

— Соң, әти, безгә кергән-чыккан кеше бихисап. Алар арасында кем булмас, — дип, сүзгә кушылды кече улы Җамалетдин.

— Кергән-чыккан кеше табарлык җирдә түгел иде ул. Сез дә табарлык түгел иде, шулай булса да, югалган бит әле, — дип котырынды Мөхетдин.

Сәлахетдиннең хатыны яшь килен Бибиҗамал, килен кешегә бу эштә кысылу килешмәс, дип, өстәл янындагы урындыкта үз эше белән мәшгуль булып утыра бирде. Ни актан, ни карадан бер сүз әйтмәде.

Аның бу халәтен өйдәгеләрдән үзенчә юратырга уйлаган, болай да аны өнәп бетермәгән, җае туры килгән саен рәнҗетергә тырышкан карчык киленгә ташланды.

— Әһә, син урладыңмы? Ник дәшмичә утырасың, килмешәк? Бу йортта чит кеше — син. Синнән башка кем алсын аны?

Килен, бу гаепне ишеткәч, урынынннан сикереп торып:

— Ни сөйлисең, әни? Нәрсәгә дип алыйм мин аны. Мин нишлим ул алтыннар белән? Кирәк булса, үз әтиемнән барып сорыйм. Кирәк тә түгел ул миңа, — дип елап җибәрде.

Сәлахетдин үзенең матур, яшь хатынын, кечкенә кызының әнисен яклап чәчрәп чыкты.

— Бибиҗамалга сүз әйтәсе булмагыз. Ул андый хатын түгел. Аның гаебе юк. Моңа иманым камил, — диде.

Мөхетдиннең кече улы Җамалетдин да, аның сүзен җөпләп:

— Бибиҗамалдан да тәүфыйклы, сабыр хатынны эзләп табасы бар әле, — дип куйды.

Бибиҗамал, үги каенанасының нахак бәла ягуына рәнҗеп, кимсенеп, икенче йортка чыгып китте. Аның артыннан Сәлахетдин дә иярде.

Мөхетдин, җанына урын таба алмыйча, ачуыннан шартларга җитешеп, ишекле-түрле йөрүен дәвам итте. Шул мизгелдә карак тотылса, мөгаен, өзгәләп ташлар иде.

— Картым, тынычлан. Үзеңне бетерәсең. Иртәгә чуаш авылы Булакка багучыга барып кайтырмын. Ул кем урлаганын да, кая куйганын да әйтер. Бу килмешәк киленнән башка кем алсын, — диде хатын, ялагайланып.

Мөхетдиннең яраткан килененә сүз әйттерәсе, аңа мондый бәла ягасы килмәсә дә, хатынының бу сүзләреннән уйга калды. Өйлә намазы җитү сәбәпле, сүзне озынга җибәрмичә, юынып алды да мәчеткә чыгып китте.

Үги ана — яшь хатынның сүзе һәрвакыттагыча тәэсирле булды. Болай булгач, киленне озаттырам, икенчегә — үзем теләгәнгә өйләндерәм, дип шатланып һәм тынычланып куйды. Шулай дип уйлап бетерде дә, «Гөлҗамал»ны көйли-көйли, аш бүлмәсенә чыгып китте.

Мөхетдин ни өчендер үзенә килгәнче сату итеп шомарып хәйләкәр төлкегә әйләнеп беткән, ялганчы, бер алдына, бер артына төшеп, һәрвакыт үз сүзен иттергән бу хатыннан шикләнмәде.

Иртәгесен карчык җыенды да чуаш авылына багучыга чыгып китте. Моңарчы да шактый йөргән иде бу юллардан: үз эшен дә җайлады, кешеләргә дә авырлык китерде.

Багучы авыл читендәге кечкенә генә иске өйдә, утыз яшьтән артса да, кияүгә чыга алмый калган кызы белән яши иде. Бер караганда, аның кияүгә чыгып китмәве әнисенә кулай иде, чөнки ул аның бөтен эшендә дә ярдәмче.

Моңа кадәр багучы үзенә шактый еш йөргән бу хатынга гел ярдәм итте. Бу юлы аның тарантастан төшеп бусагасын атлап керүенә әйтәсе сүзләрен әзерләп куйды.

— Ялганың, кеше рәнҗеше сине бер тотар дип уйламыйсыңмы? Алтыннарны син үзең алгансың бит. Киленнең бер гаебе дә юк. Ни йөзең белән шушы саф баланы пычратмакчы буласың? — диде.

— Нәрсә сөйлисең син, карчык? Моңарчы эшләгән эшләреңнең барысы да изге дип беләсеңме әллә? Син бит минем үтенеч белән генә дә ниләр генә эшләмәдең? Синең үзеңне алар тотмасмы?

— Мин аны син әйтмәсәң дә беләм. Яшем яшәлгән, ашым ашалган. Үз гөнаһым өчен үзем җавап бирермен. Син чиста күңелле киленне рәнҗетмә. Бу эшеңнең ахыры бик начар бетәчәк. Җиле миңа да кагылыр төсле. Тәңрем ярлыкасын иде! Бар кит, миңа синең бернәрсәң дә кирәк түгел, хәтта үзеңне дә күрәсем килми. Өемдә озак утырта алмыйм, бу юлы син өемә кайгы китердең, — дип ишеген барып ачып куйды.

Хатынның чыгып китми хәле юк иде. Алып килгән күчтәнәч-бүләкләрен кире куенына тыкты да, карчыкка зәһәр караш ташлап, өйдән чыгып китте. Тарантасына менеп утырганда да, озын юлдан кайтканда да башында бер генә уй иде аның: «Барыбер үземнекен итәм, барыбер киленне кудыртам, барыбер үзем хуҗа булып, авылның иң бай хатыннарының берсе булып калам».

Юлдан тузан туздырып элдерткән үз атын танып алган Мөхетдин хатынының кайтып җитүен түземсезлек белән көтеп алды. Аны өйдәгеләрнең барысы да күңелне әрнетеп торган хәвеф белән көтәләр иде.

Атны ишегалдына кертеп тарантастан төшүгә, үзен каршы алганнарга хатын ярып салды:

— Алтыннарны килен урлаган. Багучы моны раслады. Оятсыз җан, яшереп маташа бит әле. Җирбит, каракны өйдән куарга кирәк, кызын да, үзен дә.

Багучы сүзеннән соң Мөхетдин дә, Сәлахетдин дә һәм башкалар да аптыраштa калды. Барысы да киленнең бу эшкә бармасын белә. Әдәпле, бай гаиләдә үскән кыз. Бу йортта да үзен яхшы яктан гына күрсәтте.

— Юк, мөмкин хәл түгел бу. Мин аны сезгә караганда да яхшырак беләм. Ул моны эшли алмый, андый түгел ул, — дип ярсып, хатынын яклады Сәлахетдин.

Бер читтәрәк басып торган килен бөтенләй коелып төште. Битен яулыгы белән каплап, ихтыярсыз елап җибәрде.

— Мин алмадым, мин алмадым. Нигә ышанмыйсыз? — диде, үкси-үкси.

Сәлахетдин аның янына йөгереп килде дә:

— Бибиҗамал, җаныкаем, ышанам мин сиңа, елама, зинһар. Башка кеше кулы монда. Күңелем, җаным белән сизеп торам. Каракны барыбер табарбыз. Елама гына, — дип, хатынын кочагына алып, күз яшьләрен сөртте.

Сәлахиенең ярсып-ярсып үзен яклавын күргәч, Бибиҗамалның күңеленә бераз җылы иңде: сөекле ире барыбер рәнҗеттермәс, Алла боерса, дип уйлап куйды ул.

— Улым, — диде Мөхетдин карт, — алтынны кайтарып бирсә дә, бирмәсә дә, хатыныңны аерырга туры килер. Өйдә карак яшәтеп булмас.

— Әти, күрмисеңмени, син аны белмисеңмени? Ул түгел бит. Аермыйм, аера торган хатыным юк. Безнең балабыз бар. Оныгың Миңҗамалны ничек атасыннан йә анасыннан аерасың, әти?

— Бибиҗамалны оныгым Миңҗамал өчен генә кире алу шарты белән аертырга риза. Бу эшләр ачыкланып беткәнче бездән китеп торсын, — диде әтисе.

Кире аласына ниндидер бер өмет булганга гына Сәлахетдин сөекле хатынына өч мәртәбә «талак» дип кычкырды. Шәригать законы буенча дүрт айга Хәмит байга хатынлыкка биреп торырга һәм, вакыты чыккач, кире аерып алырга килештеләр.

— Мин мәңге аныкы булмаячакмын, — дип өзгәләнеп елады Бибиҗамал.

Сәлахетдин моны бик авыр кичерде. Ашаудан калды. Хатынын сагынудан, аның чит ир куенында ятуын күз алдына китерүдән сулды, тилмерде. Ниһаять, Бибиҗамалны кайтару көне җитте. Ә Хәмит бай аны аермый да аермый. Чөнки ул Бибиҗамалны шул вакыт эчендә яратып өлгерә, өстәвенә Бибиҗамал аннан балага да уза.

Инде Мөхетдин дә, улының шулкадәр тилмерүен күреп, алтын кайгысын да онытып, хәсрәткә төште: киленне ничек

кайтарырга? Улына ничек ярдәм итәргә? Шул борчулар белән тагын берничә ай үтеп китте. Бибиҗамал шул арада Хәмит байдан малай да табып куйды. Аңа Шәрәфетдин (Шәртәй) дип исем куштылар. Хәмит байның башы күктә иде.

Бу хәлләргә инде Сәлахетдин түзми: Булак авылына барып, ялганны раслатканы өчен багучы карчыкны атып үтерә. Шуннан кайтканда, Ян (Җан. — *Ф.Т.*) Бирде елгасы буенда качкын Әхмәт компаниясенә эләгеп, алар белән танышып кала. Әхмәт аңа эшен җиренә җиткерергә булышачагын әйтә. Авылга кайтып, хәлләрне белешкәч, Әхмәт белән элемтәгә кереп, Чирүле Шонталысының ат печүчесе белән сөйләшеп, Хәмит байны урманга алып баралар да печәләр. Бу хәлләрдән соң авыл байлары, бу нинди башбаштаклык, дип, Мөхетдин картны да күндереп, карар чыгарып, Сәлахетдинне Себергә җибәрәләр. Хатыны Бибиҗамал, Хәмит байдан китеп, җиде яшьлек кызы Миңҗамал белән үз әтиләренә күчә.

Мөхетдин карт зур кайгыда кала. Каһәр суккан шул алтыннар аркасында күпме хәсрәт, күпме яра.

Сәлахетдинне Себергә озаткач, чын дөреслек ачыла. Мөхетдиннең карчыгы көтмәгәндә чирләп китә. Озак ятмый, үлә. Сандыгыннан кирәк-яраклар, үлемтекләрен алганда, алтыннар белән теге янчык килеп чыга. Аны Мөхетдингә кертеп бирәләр. Моны күргәч, карт телсез кала. Бер гаепсезләрне гаепле итеп, тормышларын бозып, оныгын ятим калдыручы шушы карчык һәм аның сүзеннән чыкмаган үзе булган икән. Ходайдан ярлыкау сорый-сорый елый Мөхетдин. Башкалар сүзен тыңламавына, шул азгын, карак хатынның кем икәнен белмичә, үз балаларын рәнҗетүенә үкенеп бетә алмый.

Ярар. Җәйге көннәрнең берсендә, Себердән котылып, Күкчәтау шәһәренә килеп урнашкан һәм руда заводына эшкә кергән Сәлахетдин яныннан аның дусты Хәнәфинең хатыны авылга кайтып төшә. Бибиҗамал белән Миңҗамалны күреп, Сәлахетдиннең аларны һаман да көтүен, сагынып яшәвен һәм үз янына чакыруын әйтә. Инде унҗиде яшенә җиткән Миңҗамал шатлыгыннан Мөхетдин бабасы янына йөгереп бара. Бабасына булган хәлләрне сөйли һәм үзләренең әтисе янына җыенуларын әйтә. Моны ишеткәч, бабасының кулыннан әйберләре төшеп китә. Оныгын кочып елый. Изге юл тели, юлларына акча бирә. «Бер гаепсез бу балалар морадына ирешсен иде», — ди эченнән генә. Шулай итеп, әниле-кызлы Күкчәтауга әтиләре Сәлахетдин янына чыгып китәләр.

Шактый озак барганнан һәм тәмам арып-талганнан соң, Күкчәтауга барып җитәләр һәм Сәлахетдинне табып килеп керәләр.

Күрешү шатлыгыннан өчесе дә кочаклашкан килеш үксеп-үксеп елыйлар. Шуннан Бибиҗамал, сөекле иренең кочагыннан чыгып, күзләренә яшьле күзләрен тутырып карый да:

— Менә, Сәлахетдин, җанкисәгем, күпме тилмерешкәннән соң без бергә. Син теләгәнчә кызыңны алып килеп җиткердем, инде сау-сәламәт яшәргә язсын! — ди.

Күпне күргән, өзгәләнеп, телгәләнеп беткән йөрәге шатлыкны күтәрә алмый. Баскан җирендә егылып үлә Бибиҗамал.

Күпмедер вакыт үткәч, Сәлахетдин бер кыргызмы, казахмы карчыгына өйләнә. Дару үләннәре белән дәвалый торган карчык була ул. Мөгаен, Сәлахетдинне, кайгы-хәсрәтләрдән, зәхмәтләрдән арындырып, аякка бастыручы булгандыр ул карчык. Сәлахетдин авылга кайтып йөри. Түгәрәк йөзле, урта буйлы һәм бик җитез Сәлахетдин картаеп беткәч тә яраткан гармуныннан аерылмый. Аның шул җитезлеге, ачык күңелле булуы, өздереп гармунда уйный белүе, бәлки, үлемнәрдән саклап калгандыр да.

Үсеп җиткәч, кызы Миңҗамал кияүгә чыга. Ике малае туа. 1911 елларда авылга кайтабыз дип хат язсалар да, кайта алмыйлар. Шуннан соң элемтә өзелә.

Сәлахетдиннең бертуган энесе Җамалетдин, өйләнгәч, беренче туган кызларына яраткан абыйсы һәм яраткан сеңлесе хөрмәтенә Миңҗамал дип исем куша.

Хәмит байның гомере фаҗигале төстә өзелә. Яшенле, яңгырлы көннәрнең берсендә улы Шәртәйне кочагында тоткан килеш аны яшен сугып үтерә. Шәртәй исән кала. Шул яшен вакытында Мөхетдин картның да ике атын яшен суга. Ләкин карт моңа әллә ни кайгырмый — бу өч үлемне бергә бәйләүче Ходайның бер могҗизасы булгандыр, хәерле каза булсын, ди.

*P.S.* Мөхетдин карт — минем әтием Тарханов Габдрахманның әтисенең (минем бабайның) бабасы. Бабам Минһаҗның әтисе Җамалетдин — Сәлахетдиннең бертуган энесе. Бу тарихны әтиемнең олы абыйсы Нурулла 1967 елда, авырып киткәч, әтиемә әйтеп яздырган. Вакыйга булган авыл — Яуширмә, вакыты — XIX гасыр.

*2006*

## Яшь бабай

Әтиемнең олы абыйларыннан берсен, Нурулланы, без — нәселнең бала-чагасы — Яшь бабай дип йөрттек, чөнки ул инде олы яшьтә иде. «Бабай» дип кенә әйтер идең, ике яктан да (әти ягыннан да, әни ягыннан да) карт бабайлар бар, ә ул алардан күпкә яшь.

Менә шул үзе яшь, үзе бабай Нурулла абзыйны без барыбыз да бик ярата идек. Үзе дә безне яратты. Мине күбрәк тә ярата иде кебек, һәрхәлдә миңа шулай тоела иде. Җәй җиттеме, әти мине мотоциклына утырта да, Актауны, аның инешен җилдереп кенә үтеп, Чистай дигән калага Яшь бабайларга илтеп куя торган иде. Безне «ах» та «ух» килеп каршы алалар. Юлдан соң әти, тәмләп кенә чәй эчкәч, мине атна-ун көнгә утырмага калдырып, кайтып та китә. Ә мин Яшь бабайның кызлары — миннән бераз олырак Клара апа һәм Сирень апа белән калам. Яшь бабайның икенче хатыны Җиңги әбинең мөнәсәбәте дә миңа яхшы иде. Ул миңа карата усал булса, кыерсытса, мин аларда атналап тора да алмаган булыр идем. Тик менә аның үги кызларына — туганнан туган апаларыма — бик коры булуы, кайчакларда нык кыерсытуы минем кечкенә йөрәгемне яралый иде. Аның шундый булуын Яшь бабайга әйтергә теләсәм дә, Клара апа белән Сирень апа, яман да куркып, әтиләренә әйттермиләр иде.

Аларның бу тормышы үзе бер китап язарлык булган икән. Мин аны үскәч кенә белдем. Бәлки, киләчәктә язылыр да.

Чистайда, Биләр урамының 10 нчы йортында, һәр ел саен уздыра торган бер-ике атнага сузылган каникул көннәрем күңелгә мәңге онытылмас булып уелып калды. Яшь бабайның әле зур, әле кечкенә скрипкасында үзәкләргә үтеп моңлы озын көйләрне уйнавы; өй алдындагы һәм артындагы шактый зур җиләк-җимеш-яшелчә бакчасында сулар сибешеп, андагы матурлыктан хозурланып йөрүем; көн саен апаларым белән Чистай урамнарын, базар, ял паркларын урап кайтуым — барысы да ел буе сөйләрлек матур бер хатирә калдыра иде. Баксаң, ел буе гына түгел, гомергә искә алырлык хатирә булып калган икән.

Менә шул Яшь бабам, әле утызына да җитмичә, коллективлашу чорында крестьяннарны колхозга керергә үгетләп йөргән. Үз әти-әнисе колхозга кермәгәнгә, кайберәүләр аның бу үгетләвенә каршы: «Ә-ә, Тархановмы? Бар, әүвәл үзеңнекеләрне керт, аннан соң безне агитларсың», — дип тиргәп, кире борып чыгаргач, бүтән бәйләнмәсеннәр өчен фамилиясен алыштырып, әтисенең рәнҗешен алган һәм шуның аркасында үзе генә түгел, балалары да, балаларының балалары да күп авырлыклар күргән. Кызыл Яр волостеның Чистай кантонында финанс министры вазифасын башкарган; сугыш елларында эвакогоспитальдә финанс бүлеген (финчасть) җитәкләгән; гомере буе финансист-экономист булып эшләгән; һәвәскәр музыкант (мин аның скрипкада уйнавын мәшһүр скрипкачы Заһид Хәбибуллин уйнавына тиңли идем); егет чагында ук Яуширмәдә үзе язган пьесалар буенча спектакльләр куеп, авыл яшьләрен (шул исәптән мәшһүр сүз остасы Фәйзи Йосыповны да) беренче мәртәбә сәхнәгә мендергән; хикәяләр, повестьлар язган (бәлки, бастыргандыр да — эзләп табасы бар); шул әсәрләрен кайчандыр үзе белән бергә Балтачта эшләгән, соңыннан классик язучы булып киткән Гомәр ага Бәширов укып чыгып, үзенең фикерен әйткән һәм «Совет әдәбияты» журналына бастырырга тәкъдим иткән (Г.Бәшировның аңа язган бу хаты миндә саклана); шуның өстенә, үзе сугышка киткәч, сөекле хатыны үлеп, аны күмәргә дә кайта алмыйча, ятим калган биш баласын сугыштан соң гына кайсын кайдан җыеп алып, икенче хатыны Хәдичә ярдәмендә бер гаиләгә туплаган; өйгә килеп керсә, әзмәвердәй зур гәүдәсе белән бөтен өйне, олы йөрәкле, гаҗәеп нечкә күңелле Нурулла абзыйның, ягъни Яшь бабайның, кулъязма хәлендәге кайбер мәгълүматларын, язмаларын җыеп, аларны кыска хикәяләргә әйләндерергә булдым.

### *Колдун*

Чистай шәһәреннән ерак түгел Крутая Гора дигән авыл бар. Шулай бервакыт бу авылга эш белән килгәч, кунып калырга туры килде. Кич белән, ашханәгә кереп, тамак ялгап алмакчы булдык. Чистайдан ике-өч кеше, Алексеевскидан берәү һәм тагын үзен рус милләтеннән дип таныштырган пенсионер Ян Карлович Подоль дигән кеше бар иде. Рус дип таныштырса да, аның нинди милләттән булуы йөзенә язылган иде. Шуңа күрә төпченеп, милләтен ачыклап тормадык, хәтта нинди кеше икәнен яшергәнен дә аптырамадык.

Сүз артыннан сүз ияреп, кызык хәлләр турында да сүз чыкты. Шунда Ян Карлович сөйләп китте:

— Мин сезгә, егетләр, суеверие дигән нәрсә турында сөйләмәкче булам. Сезнең татарларда да булмас нәрсәләргә ышанучылар күп икән. Безнең рус халкында да андыйлар шактый. Украиннар

турында әйтмим дә инде.

Минем егет чак. Украинадагы бер заводта эшләп йөрим. Ә торуыбыз — заводтан ерак түгел бер авылда. Җәяү барабыз, җәяү кайтабыз. Беркөнне шулай эштән кайтып килгәндә, иптәш егет, куркуыннан коты алынып:

— Кара әле, кара! Болар нишли, ә? — дип кычкырып җибәрмәсенме.

Карыйм: берәүләрнең йортыннан ирләр, хатын-кызлар өелешеп, куркышып килеп чыктылар да нишләргә белмичә басып торалар. Без алар янына йөгереп килдек.

— Ни булды? — дип сорыйбыз.

Араларыннан берсе:

— Кичә кич менә бу йортта бер карчык вафат булган иде. Инде хәл белергә керсәк, вакыт-вакыт башын чайкап ала, — диде.

Мин дус малайга:

— Әйдә керик әле, күрик, ни-нәрсә икән, — дидем дә икәүләшеп өйгә кереп киттек.

Безнең арттан ияреп күршеләре дә керде. Чынлап та, вафат булган карчык әледән-әле башын чайкап куя. Без дә аптырашта калдык.

Андагы гадәт буенча мәетне, башыннан ук саванга төреп, тәре белән икона куелган почмакка башы белән каратып яткыралар. Җентекләбрәк карый башлагач, күзем шул почмакка төште. Аның астына оясы белән каз утыртканнар икән.

Карчыкның башын ураган саванның бер очы утыра торган казның оясына салынып төшкән, ә каз аны вакыт-вакыт тешләп йолыккалый. Ул йолкыган саен, үлекнең башы селкенә.

Ә мин, кешегә сиздермичә генә, саван канатын оядан алып, тиешле урынына кыстырып куйдым да, халык алдына чыгып, барысына да ишетелерлек итеп, мәеткә:

— Тик кенә ят! — дип, бармак янадым. — Хәзер башы селкенмәс, — дидем, һәм иптәшем белән чыгып та киттек.

Чынлап та, карчыкның башы бүтән селкенмәгән. Әмма икенче көнне үк бөтен авылга мондый хәбәр таралган: «Ян Карлович колдун икән, ә үлгән карчык аның кушканын үтәүче ведьма булган икән».

Инде кичен эштән кайтып, ашап-эчкәннән соң кызлар янына чыксам, кызлар миннән кача, минем белән биюче дә юк. Урамда очратсалар да минем күземә күренмәскә йә, урамның икенче ягына чыгып, сиздермичә генә үтеп китәргә тырышалар.

Ярар. Монысы болай булды. Алга таба аннан да «шәбрәге» сагалап торган булып чыкты.

Заводка йөри торган юлыбыз зират аша үтә иде. Көннәрдән бер көнне миңа төнге сменага барырга туры килде. Кич белән көчле яңгыр явып узды. Эшкә киттем. Көн саен йөри торган сукмактан барам. Сукмакның нәкъ уртасына кабер казып куйганнар икән. Мин моны күрмәдем — караңгы. Шуып егылып төшеп киттем бит шул кабергә. Яңгыр яуганга, бөтен җир юеш, тайгак, һич кенә дә чыгып булмый, каһәр. Үрмәләп-тырмашып бераз менгән кебек булам да яңадан шуып төшеп китәм. Җәфаланып беттем. Бераздан ишетәм: ике ир кеше сөйләшә-сөйләшә сукмак буйлап килә.

Мин шатлыгымнан:

— Егетләр, миңа кабердән чыгарга булышыгыз әле, — дип кычкырып җибәрдем.

Болар, минем тавышны ишетү белән, кинәт туктап калдылар, аннары борылдылар да егыла-тора, абына-сөртенә чабып киттеләр. Мин, ни еларга, ни көләргә белмичә, артларыннан кычкырып калдым.

Шулай да бераздан фонарь тоткан зират каравылчысы белән өч ир кеше килеп мине кабердән чыгардылар.

Инде минем турында яңа хәбәр таралды: «Ян Карлович, каберләргә кереп, төннәр буе үлекләр белән аралашып йөри икән».

Бу хәлләрдән соң үземә дә әллә ничек була башлады. Шулай да түзәм инде, кая барасың.

Алай да беркөнне яшьләр җыелган җиргә барырга булдым. Урыс әйтмешли: «Была не была!». Киттем матур итеп киенеп. Мин барып җиткәндә, биюләр башланган иде инде. Килгән шәпкә күзем төшкән бер кызны биюгә чакырдым. Кыз чыкмады. Минем ачуым килде.

— Болай булсаң, табаның белән артка таба йөри торган итәм мин сине, — дигән идем, бу кыз шундук юк булды.

Шуның белән мин дә кайтып киттем.

Иртәгесен кулына бер кувшин самогон, бер-ике кило шпик тоткан кызның әтисе килеп керде. Аягыма егылып:

— Ян Карлович, син, зинһар, кызымны сихерли күрмә инде. Кыз бала бит ул, кияүгә чыгасы бар. Ничек табаны белән артка йөрсен инде. Берүк алай ясый күрмә, зинһар, гафу ит! Менә сиңа күчтәнәчләр, — дип, өстәлгә үзе белән алып килгән әйберләрен китереп куйды.

Мин бу абзыйны тынычландырып чыгарып җибәрдем, кызына тимәскә вәгъдә бирдем. Үземнең җен ачуларым чыкты, сиздермим генә.

Тәки колдун-сихерче итеп бетерделәр мине. Бу авылда яшәрлегемне калдырмадылар. Эшемне ташлап, башка якка китеп барырга мәҗбүр булдым. Менә сезнең җирләр тартып китерде үземне, — дип, сүзен бетерде ул.

Ян Карлович сөйләгәндә, тәгәри-тәгәри көлдек, эчебез катып бетте. Күңелләребезне күтәргән өчен, кызыклы хикәяте өчен аңа рәхмәтебезне белдереп, урыннарыбызга таралыштык.

### ***Шиһап мулла мәдрәсәсе***

Чистайда заманында Шиһап мулла мәдрәсәсе бар иде. Анда шәһәрнең үзеннән дә, тирә-юнь авыллардан да килеп укучы шәкертләр байтак булды. Кайчандыр шул мәдрәсәдә шәкерт булып йөргән кешеләр бергә очрашса, андагы кызык хәлләрне искә төшереп, рәхәтләнеп көләләр иде. Минем белән бергә эшли торган танышым Госман да шул мәдрәсәдә укыган булып чыкты. Буш вакыт булган саен нәрсә дә булса сөйләми калмый иде ул. Бу юлы да шулай булды. Бераз ял итеп алыйк дип утырышкан гына идек, Госман, авызын ерып:

— Нәрсә, сөйлимме? Тыңлыйсызмы? — диде.

— Тыңлыйбыз, тыңлыйбыз, сөйлә әйдә, — диештек.

— Минем Чистайныкы икәнне беләсез инде сез. Күршебездә урыслар яши иде. Минем яшьтәге уллары да бар. Дуслар инде без. Мин — аларда, ул — бездә. Ашау-эчү дә уртак без ике дусның. Тегенең күгәрченнәре бар. Кайчакларда сәгатьләр буе күгәрчен очырта. Мин дә аңа кушылам. Арып беткәч, аларга кереп ашыйбыз. Аларның ашы миңа бик тәмле булып тоела иде, безнең әнинеке кебек түгел, икенче төрле тәмле иде. Дуңгыз ите белән пешергәнгәдер инде. Минем шулай урысларда ашап йөргәнне Шиһап мулла белән Борһан мәзингә җиткергәннәр бит. Мине мәдрәсәгә чакыртып алдылар да сорау алырга керештеләр.

Сүзне Шиһап мулла башлады:

— Син, Госман энем, күрше урыслар белән аралашасың икән. Хәтта аларда ашларын да ашыйсың, ди. Дөресме бу?

— Булгалый, — дим.

Үзем аның йөзен күзәтәм. Мин уңай җавап биргәч, йөзләре җыерылып килде мулланың.

— Тәүбә, әстәгъфирулла! Тәүбә, әстәгъфирулла! Дуңгыз итен дә ашыйсыңмы?

— Ашаштыргалыйм, хәзрәт. Биргәч, ашамыйча булмый бит инде. Яхшы түгел. Җирәнә дип уйлаулары бар.

— Энем, дуңгыз ите — мөселманнарга хәрәм. Син алга таба да дәвам итсәң, мөселман булудан туктап, кяфер булачаксың бит.

— Мулла абзый, мин аңлап җиткермим: ни өчен дуңгыз ите безгә хәрәм?

— Бердән, бөтен нәҗесне ашаганы өчен, икенчедән, пычрактан чыкмый, шакшы бит ул.

— Мулла абзый, менә безнең тирәдәге кайбер урыслар «английский» дигән нәселле дуңгызлар асрыйлар. Аларга гел икмәк белән бәрәңге генә ашаталар, чиста җирдә генә тоталар, андыйлар да хараммы? Ә менә тавык теләсә кайда йөри, теләсә нәрсә ашый, дуңгыздан да болайрак. Ул нигә хәрәм түгел?

— Ахмак, ни сөйлисең син? Тавык белән дуңгызны чагыштырып буламыни? — дип кычкырды Шиһап мулла, җене чыгып.

— Хәзрәт, ачуланмасаң, тагын бер соравым бар иде: шуңа һич башым җитми.

— Сора, сора, шәкерт, — диде ул, бераз тынычланып. — Белмәгән гаеп түгел, белергә теләмәгән гаеп. Шәкерт чагыңда күбрәк белеп калырга тырыш. Бәлки, яманны яхшыдан аерырга өйрәнерсең.

— Менә корбан чалу мәсьәләсе дә аңлашылып бетми миңа, хәзрәт. Аллаһы Тәгалә тояклары ярык булган хайванны гына чалырга кушкан. Мулла абзый, менә безнең күрше урысларның дуңгызын күрсәң, исең китәр: үзе ярык тояклы, үзе гаҗәеп зур — валлаһи газыйм, ых та итмичә, сразы биш-алты татарны сират күпере аша алып чыгып куячак.

Шиһап мулланың кабат ачуы чыкты. Кызарынды, бүртенде, түземе төкәнде.

— Ләгънәт малай, сөйләмә юкны. Аллам сакласын, Аллам сакласын! Көфер сүз сөйлисең. Мелла Борһан, бу ахмакны, кяфергә әйләнгәнче, яхшы итеп, юлдан язмаслык итеп өйрәтергә кирәк. Сиңа тапшырам, бөтен ахмаклыгын чыгар, — диде дә, миңа зәһәр караш ташлап, җил-җил килеп чыгып китте, ә Борһан мәзиннең тал чыбыгыннан котылып булмады: шәп эләкте үземә, икенчеләй көфер сүз сөйләрлек итмәде мәзин.

Шәкерт халкы барыбер шаян инде ул. Юк кына нәрсәдән дә кызык табып, юк кына нәрсәне дә

көлкегә әйләндерә ала. Шиһап мулла мәдрәсәсенең кайда булганын беләсез инде сез — хәзер аның урынында трикотаж фабрикасы. Аның өске катында намаз укыр өчен бик зур залы бар иде, ә аскы катта — тәһарәтләнү бүлмәләре. Безнең тәһарәт алганны карап торучы камчылы назыйр бар иде. Ул беренче каттан икенче катка намаз укырга йөгереп менүчеләрнең башын гына тотып карый: чәче коры булса, камчысы белән берне генә сыдыра, беренче катка яңадан төшеп җиткәнеңне сизми дә каласың.

Авыл малайлары тәртиплерәк әле. Шәһәр малайлары арасында гаҗәп усаллары, әллә ниләр уйлап тапканнары булды. Намаз укыганда да төрлечә кыланалар иде.

Беркөнне шулай рөкүгъка иелгәндә, саф булып тезелгән әллә ничә дистә шәкертнең уңыннан яны белән этеп җибәрәләр, шәкертләр бөтен саф белән берсе өстенә берсе килеп егылып бетәләр. Бу хәл һәрдаим кабатланганга, аптырагач, безне намаз укырга мәчеткә алып керә башладылар. Шаян шәкертләр анда да кимен куймады.

Бервакыт мәчеттә намаз укыганда арттагы сафта торган бер малай рөкүгъка иелгәндә нәкъ мулла турысындагы бер шәкертнең артына башы белән шундый итеп китереп бәрде, тегесе аягында торып кала алмады — алдагы шәкерткә, анысы үз алдагысына башы белән килеп бәрелде. Шулай итеп, бер-берсен ега-ега, чират муллага җитте. Мулла бик яшь булмаса да, сөрлегеп кенә китте, идәнгә барып төшмәде.

Шуннан соң инде безне мәчеткә кертмәс булдылар. Шуклыклар аркасында кыен да эләгә иде инде: Борһан мәзин дә, озын борынлы укытучы Мөхәммәт тә, тагын әле Талкыштан Мотыйгулла Ярмушев дигән укытучы да кыйный иде безне. Аңа карап шәкертләр барыбер тик тормады — яңадан-яңа шуклыкларны уйлап чыгарып кына тордылар. Бүгенгә җитәр, калганын икенче вакыт сөйләрмен, — дип, сүзен очлады Госман. — Таралышыйк, югыйсә монда да карап тормаслар, эләктереп куймагайлары.

*2006*

# Упкын

— Сеңлем, миһербанлы кешегә охшыйсың, ипи алырлык кына булса да акча бирмәссең микән?! — дигән тавышка борылып карасам, имәнеп киттем: кояшта каралган йөзен буразналар ярган, эчкә баткан күзләрендә өмет
чаткылары сүнгән, искереп, кечерәеп беткән пальто, башына мескен бүрек кигән, уң аягы кәкре булганга, шул ягына бераз янтайган бер адәм калтыранган кулына акча салганны көтеп тора иде.

Миңа аның тавышы ничектер таныш кебек тоелды, шуңа күрә үзен җентекләбрәк карый башлагач, ул сискәнеп китте: мин аны танып алганчы, ул үзе мине таныды. Таныды да бөтен гәүдәсе белән куырылып килде, хәер сорап сузган кулы хәлсезләнеп салынып төште. Йөзенә кәфен аклыгы иңде. Бераз тотлыга төшеп:

— З-з-зинһар, төбәп карама, с-с-сеңлем. Карама шулай үзәгемә үтеп. Оят миңа. Оят синең алда. Әмма акча сорарга мәҗбүрмен. Инде өч көнләп ашаганым юк. Ачтан үләсең килмәсә, оятың кача икән. Кача икән! — диде ул, күтәрелеп карамыйча гына. — Менә шундый хәлләргә төштем инде, сеңлем. Үзеңне кулда тота алмасаң, төшәсең икән шул. Таныш-белеш түгел, үземне үзем дә танымыйм мин хәзер.

Әйе, танырлыгы калмаган иде аның. Кайчандыр озын буйлы, чандыр гәүдәле, зәңгәр күзле, дулкынланып торган аксыл чәчле, шәһәрнең иң зур хастаханәләренең берсендә атаклы хирург булып эшләгән, үз милләтен, милли мәдәниятне, сәнгатьне бала чактан ук белеп, мөкиббән китеп яраткан, заманында танылган зыялы зат шул хәлгә төшәр дип кем уйлаган? Шундый кешене хәерче кыяфәтендә күрү кызганыч та, куркыныч та иде.

Минем күзләрне яшь пәрдәсе каплады. Әйтергә сүз тапмадым. Бу хәлгә ышанасым килмәде. Заманында кемнәргә генә ярдәм итмәде бит ул. Ничек болай килеп чыккан соң әле?

— Роберт абый, чынлап та синме соң бу? — дидем, ниһаять, телгә килеп.

— Мин, сеңлем, мин. Әйдә читкәрәк китик әле. Кеше күзеннән, дим. Миңа ни, мин күнеккән инде. Синең өчен борчылам: синең кебек ханымга минемише кеше белән сөйләшеп тору килешмәс, бизәмәс ул сине.

Шунда гына мин тирә-юньгә күз салдым. Чынлап та кешеләр, безнең тирәдән үткәндә, зур игътибар күрсәтәләр иде. Хәтта кайберәүләре, туктап, безнең сүзләргә колак салып тора башлады.

— Әйдә, алайса, Роберт абый, әнә тегендә ашханә бар, шунда керик әле. Минем дә ашыйсым килә, бергәләп ашап та чыгарбыз, берочтан хәлләреңне дә сөйләрсең. Сине күрмәгәнгә биш кенә түгел, йөз

былтыр бит инде, — дип
шаяртмакчы булдым.

Күңеле күтәрелде абзыемның. Кызу-кызу атлап, ашханәгә таба китте. Бераз баргач, нәрсәдер исенә төшкәндәй, кинәт туктап калды.

— Ни бит әле... сеңлем... Син минем белән анда керергә хурланмыйсыңмы соң? Сиңа минем белән янәшә бару да читендер инде. Булмаса, мин урамның теге ягына чыгыйм. Ул яктан барыйм, — диде, уңайсызланып.

— Нишләп хурланыйм, Роберт абый. Син бит чит, белмәгән кеше түгел. Бер дә борчылма.

— Шулай дисеңме. Син әллә ниләр уйлама, сеңлем. Мин үземне күрсәтәм әле, аякка басам әле, менә әйтте диярсең. Минем танышларым күп, элемтәләр җитәрлек. Менә күрерсең, — диде, минем сүзләрдән канатланып.

Ашханәгә килеп керү белән, юынырга, үз-үзен тәртипкә китерергә дип, юыну бүлмәсенә кереп китте. Мин чиратка бастым. Безнең бәхеткә, ашханәдә кеше аз иде. Димәк, иркенләп ашарга да, җәелеп сөйләшергә дә мөмкин булачак.

Бераздан юынып, чистарынып һәм, кояштай балкып, Роберт абый килеп керде. Мин аны буш өстәл янына утырттым.

— Чират җиткәч чакырырмын, булышырсың, — дидем.

Башта мең уй бөтерелә. Менә сиңа язмыш! Менә сиңа затлы тормыш! «Эһ» дигәнче челпәрәмә килгән дә беткән. Дәрәҗәгә ирештем, үлгәнче шулай булыр дип һич ышанып йөрерлек түгел икән. Менә бит дөнья нишләтә: бер алдын, бер артын күрсәтә, дип, юкка гына әйтми икән халык.

Роберт абый пальтосын салып, букчасы белән бергә тәрәзә төбенә илтеп куйды. Костюмының бик күптәнге (әмма чиста) булуына игътибар иттем: җилкәләре тар, җиңе кыска, чалбар балагы ямьшәеп беткән ботинкасына да җитми. Чалбар балагы кыска булганга, аягыннан ике төрле оекбаш балтыры күренә. Бераздан, чиратымның җитүен күреп, ул минем янга килеп басты.

— Роберт абый, менә култабын, теләгән нәрсәңне ал, курыкма, миндә акча җитәрлек. Читенсенмә. Рәхәтләнеп аша, — дидем, аның тартынып торуын күргәч. — Ал, ал!

Бичара, калтыранган куллары белән әле тегесенә сузылды, әле монысын алмакчы булды, нәрсә сайларга белмәде. Ниһаять, култабынын тутырып, касса янына барып басты. Кассир хатын бер аның кыяфәтенә, бер ул җыйган ризыкларга карады да, ниндидер бер «матур» сүз әйтергә теләп, авызын гына ачкан иде, Роберт абый янына мин килеп җиттем.

— Борчылмагыз, барысы өчен дә мин түлим, — дидем.

Шуннан соң гына кассир хатын берәм-берәм исәпләргә кереште.

— Бигрәк аз алгансың үзеңә. Акчаң калмагандыр инде, мин беразын илтеп куйыйм, булмаса, — дип борчыла башлады ул.

— Юк-юк, Роберт абый, миңа болар да бик җиткән, — дидем, аны тынычландырып.

Өч көн ашаганым юк дисә дә, ач икәне йөзенә чыкса да, ризыкка бүредәй ташланмады. Кыюсыз гына ипигә үрелде һәм бала чактан килгән тәрбиялелеге белән, ашның тәмен белеп, ләззәтен тоеп ашый башлады. Мин дә аның көенә генә утырдым. Бүлдермим дип, сораулар бирмәскә тырыштым.

— Син миннән аңлату көтәсеңдер, шулкадәр югарылыкка ирешкән бу бәндә ничекләр итеп упкынга тәгәрәгән дип уйлыйсыңдыр инде, әйеме? — диде ул, өстәлгә коелган ипи валчыкларын чүпли-чүпли. — Тормышны рәткә кертү, җайга салу гына авыр икән ул, җимереп ташлау берни тормый икән. Минем афәтнең башы: әтиемнең, туганнарым һәм танышларымның сүзен тыңламыйча, ялгыш өйләнүемдә. — Аның уфтануы, үкенүе күкрәк түреннән чыккан авыр ыңгырашу булып таралды. — Минем аңа өйләнергә җыенуымны белгәч, әйттеләр, син милли хисләрдә, милли көйләрдә тәрбияләнгән бала. Ул синең каныңа сеңгән. Әллә кайда үскән Рәсәй марҗасы синең милли хисләреңне барыбер аңламаячак. Кирәксенмәячәк. Сиңа бик авыр булачак. Төптән уйла. Ялгышасың, ялгышасың, бала, дип күпме кисәттеләр. Юк бит, тыңламыйсың икән яшь чакта. Рәзе безнең тормыш начар була ала, ярата ич ул мине. Яраткач, ничек аңламасын да, минем тәкъдимнәргә ничек каршы килсен ди. И җүләрлек! Туганнар хаклы булып чыкты, әлбәттә, аңламады ул мине, аңларга да теләмәде.

Үзең беләсең: минем әти татар халык көйләрен төрле-төрле скрипкаларда үзәк өзгеч итеп уйный иде. Аннан оста уйнаучы Заһид Хәбибуллинны гына беләм мин. «Тәфтиләү»ләр, «Әллүки»ләр моңында тирбәлдек бит без. Башка милләт балалары белән аралашып, уйнап, җырларын җырлап үссәк тә, үз көең, үз моңың йөрәккә дә якын була икән шул: дәртләндерә, шатландыра, күкләргә дә чөя, үзәкләрне телеп-телеп сагышка да сала. Минем бөтен туганнарым да милли көйләребезгә гашыйк, җырчы кешеләр. Шуңа күрә кайда гына, кайчан гына очрашсак та, гел җыр-музыка, бию иде бездә. Ни

кызганыч: үзем бер генә уен коралында да уйнарга өйрәнә алмадым.

Фатыйхасыз, рөхсәтсез өйләнүемнең «нәтиҗәсен» мин өйләнешеп, бер-ике ел үткәч тә күрә башладым. Җиңги апаң үзен генә ярата торган хатын булып чыкты. Дуслашып, яратышып йөргәндә, күзгә берни күренми икән. Башка милләттән булуы да, башка дин вәкиле булуы да.

Без, ирләр, сезләрне үзебез азындырабыз бугай, ярәшкән егет белән кыз булып йөргәндә бигрәк тә. Теләсә нинди көйсезлекне дә көйләргә, гозерегезне үтәргә генә торабыз. Алай гына да түгел, йөгерә-чаба үтибез. Моңа ияләнгән хатын-кыз кияүгә чыккач та шуны куа. Тормыш алып бару — сөешеп йөрү генә түгел, аның мең мәшәкате бар. Мин җиңги апаңда хатыным буларак күрергә теләгән сыйфатларны таба алмадым. Югыйсә тормышыбызны бөтенләй башкача күз алдына китергән идем.

Үзем дә гаепле. Нык тора алмадым. Артык узындырдым. Шуңа да мине санга сукмый башлагандыр. Хәтта исемемне «онытып», фамилиям белән генә эндәшүгә күчте: «Кайттыңмы, Җәләев. Чәеңне эч тә, Җәләев, әнә керләрне чайкап ал, Җәләев». Ходаем, мин кемгә әйләндем? Өй җыештырам, кер юам, бала карыйм, аякларына кадәр юып сөртә-сөртә, аны иркәлим, кайчакларда ашарга да үзем пешерәм. Мин бит ир генә түгел, хирург та. Үзем дәвалый торган, мин операция ясаган авыруларым көтеп ята ич мине. Шуның өстенә көн саен операция ясыйм, дәвалану вакыты бетеп, хастаханәдән чыкканнарының өйләренә барып хәлен беләм, җөйләренең төзәлүен тикшерәм. Өйгә эт булып кайтып егылам. Менә шул минутларда үзебезнең милли көйләребезне тыңлап, ана телендә тапшырулар карап, бераз ял итеп аласы килә. Көч-дәрман җыясы. Кая ул?! Күргән һәр җирдән җыеп кайткан татарча язмаларны, җыр тәлинкәләрен, мин тыңламасын дип, берәм-берәм дә, барысын берьюлы да тәрәзәдән томыра торды; радио, телевизорларны, татарча тапшыру башлану белән, йөгереп килеп сүндерә иде. Баштарак түздем, каты бәрелмәскә тырыштым. Тора-бара катырак әйткәли башладым, әмма сүз гауга, талаш-кычкырыш, күз яшьләре белән тәмамлана иде. Тәмам гарык булдым тавыштан. Инде икенче юлга бастым: эшем беткәч, туры өйгә кайтмыйм, күңелемә хуш килгән җырчы егетләрне алам да ресторанга китәм. Алардан үзем яраткан җырларны җырлатам. Мин сыйлыйм — алар җырлый, алар җырлый — мин сыйлыйм. Үзем дә салып куям. Сала торгач, күңел йомшап, тыела алмыйча елыйм, әтиләр, туганнар, барыбыз бергә җыелышып утырган чаклар искә төшә. Шулай да кәеф әйбәт, җаным тыныч. Инде кайтам да, диссертацияне дәвам итәм, дип, шактый илһамланып өйгә кайтсам, тагын тавыш, хет яңадан чыгып кач.

Югыйсә бит хатын акчаны санап яшәмәде. Ике җирдә эшләп, күп алдым мин аны. Ул вакытта ук ике дистәгә якын авторлык таныклыгым бар иде. Һәр ел саен, ике баланы җитәкләп, Кырымга ял итәргә йөрдек. Ул да эшләде, әлбәттә, тик аның акчасы вак-төяккә дә җитми иде. Кимсетеп әйтүем түгел: белгән кешегә аңларлык. Әйткәнемчә, тормышны өй эшләрендә булышып җиңеләйтергә тырышсам да, күңелен күтәрергә төрле җирләргә йөртсәм дә, ни гаҗәптер, үземә карата аңлау, ярдәм, теләктәшлек күрмәдем, булырлык та түгел иде. Чөнки аның тәрбиясе икенче иде. Эх-х, күзем соң ачылды, бигрәк соң ачылды шул!.. Бала туганчы кирәк иде.

Шулай да күпме түзәргә була?! Аралар акрынлап суына башлады. Дөресрәге, минем хисләр сүнде — аның явызлыгын, мин-минлеген күргәч, эреп юкка чыктылар. Гаҗәеп оста итеп балаларны да миңа каршы котырта башлады. Минем аерылып китмәвемнең сәбәбе дә шул балалар гына иде: ятим итәсем килмәгән иде аларны. Үзем ярым ятим үскәч, ятимлекнең ни икәнен беләм идем мин. Үз балаңа түгел, дошманның баласына да теләмәс идем мин ятимлекне. Шулай итеп, үлеп яраткан улым белән кызым миннән читләшә барды. Эшемдә көчле шәхес булсам да, гаиләмдә йомшаклык күрсәттем. Бу йомшаклыгым миңа, руслар әйтмешли, «боком вышел» — тормышымны чәлпәрәмә китерде. Мин эчә башладым, эш аерылышуга җитте.

Шундый авыр көннәрнең берсендә Ходай Тәгалә, бу хатын белән барыбер яшәп бетерә алмасымны белептер инде, мине сылу гына бер татар кызы белән очраштырды. Көтмәгәндә, уйламаганда очраштык без аның белән. Шулкадәр сабыр, акыллы, уңган кыз иде ул. Мин аның игътибарыннан күкнең җиденче катында идем. Дистә еллап хатын-кыз назы күргәнем юк иде. Үзем дә аңа тартылдым. Тормышыма ямь керде. Эшләрем җырлап кына бара башлады. Шул көннәрдә чит милләт кызына өйләнүемнең нинди зур ялгышлык булуын тагын бер кат аңладым. Сүз дә юк, бар да шундый дип әйтергә җыенмыйм, һич юк. Алар арасында да тиешле тәрбия алганы очрыйдыр. Алар белән дә бәхетле яшәгән татарлар бардыр. Дөрес, үз чибәрләребез дә мең төрле. Анысы икенче мәсьәлә. Әмма бер үк милләттән булган парлар арасында милли нигездәге каршылыклар, ызгыш-талашлар беркайчан да булмаячак та, тумаячак та. Ә иң авыры, йөрәккә барып кадалганның иң әрнүлесе — милләтеңне кимсетеп, хурлап әйтелгән сүз икән, яраткан кешеңнең, синең белән бергә торып, балалар үстерсә дә, сине тиңсенмичә, ничек кенә аннан өстен булма, ким күреп яшәве икән...

Хатыным, әлеге кыз белән очрашып йөрүемне белеп алгач, үзенең тагын бер ягын ачты: партком

юлында йөреп, мине партиядән чыгартты, эшемә килеп гауга куптарды. Яраткан кешемне эштән кудыртты. Партиядән чыгарылу һәм канатсыз калу минем өчен соңгы чик булды: мин, башымны югалтып, бөтенләй эчүгә сабыштым.

Эшемнең рәте китте, ахыр килеп, аннан да алдылар. Билгеле инде — без аерылыштык. Мин урамда калдым. Ике бүлмәле фатирымны бөтен җиһазлары белән хатыныма, балаларыма калдырдым. Тормышымны башка хатын белән бәйли алмадым. Төрле урыннарда эшләп карадым. Булмады. Эчә торгач, холкым да начарайды. Исерек килеш троллейбус астына килеп кергәнмен — аякларым изелде. Берсе әйбәт кенә төзәлсә дә, икенчесенең сөяге менә шулай кәкре ялганды, шуңа күрә кыскарак та. Аксап йөрүемнең дә сәбәбе шул. Рәтләп эшләмәгәч, акча да юк. Үземне кулга алырлыктан узган бугай инде. Дәваланып та карадым — файдасы тимәде. Менә кем хәзер мин?! Ә бит, кая гына барсам да, ишекләрнең үзләре ачыла торган чаклары бар иде. Татарстанда гына түгел, Союзда беләләр иде мине. Минем ачышлар буенча эшләнгән кайбер нәрсәләр кешеләргә генә түгел, илебез икътисадына да шактый файда китерде.

Докторлык диссертациям әзер иде. Менә дигән эш урыным бар иде. Һәммәсе дә тарихка кереп югалды. Үз көчем белән тапкан бар байлыгым юкка чыкты. Элегрәк өнемдә югалткан бар нәрсә төшемә кереп газаплый иде. Аларның хәзер инде күбесе төшемә дә керми башлады. Тора-бара балаларым белән дә аралар өзелде: аларның үз тормышы, минем үз тормышым. Алар өчен дә йөрәгем әрнеми хәзер.

Менә шул, сеңлем. Сине борчыганым өчен, зинһар, рәнҗемә, — диде ул, урыныннан торып, киенә-киенә. — Озак утырдык. Китик инде. Синең дә эшкә барасың бардыр. Вакытыңны кызганмый мине тыңлап утырганың өчен дә, тамагымны туйдыруың өчен дә мең рәхмәт.

Без киендек тә урамга чыктык. Ашханәнең ят исләр, төрле кешеләр белән тыгызланган һавасыннан соң, кышкы саф һава кислород кебек тәэсир итте безгә.

— Алай да син мине бөтенләй өметсез икән бу дип уйлама инде, сеңлем. Жәлләп тә карама шулай. Ходай кушса, үземне кулга алып, кешечә яши башлармын әле. Алай дигән белән мин бит әле гел беткән кеше түгел. Күрсәтәм әле мин үземне, — дип бетерде ул сүзен кызганыч бер елмаю белән һәм титаклый-титаклый китеп барды.

*P.S.* Кызганыч, күтәрелә алмады ул элекке югарылыгына. Хәтта уннан бер өлешенә дә буе җитмәде. Бетте. Югалды. Упкын суырды. Медицина өлкәсендә элек аны белмәгән кеше юк иде, ә хәзер бергә дус булып йөргәннәрнең дә, бары аның ярдәмендә генә үз биеклегенә күтәрелгәннәрнең дә хәтереннән чыгып бара ул. Дөрес булса, соңгы көннәрдә аны республиканың кайсыдыр Картлар йортында күргәннәр. Картайган, тешләре төшкән, ап-ак чәчле бер бабайга әйләнгән, ди.

*1999*

## Үкенү

Сәйфулланың хатыны Разияне җирләп кайтуына елга якын вакыт узып китте.

Менә инде ничәнче ай эштән кайта да карчыгы белән гомер кичергән өендә, утын да алдырмыйча, япа-ялгызы уйларына чумып утыра Сәйфулла. Онытылыр өчен төнгә кадәр эшләп, арып-талып, гәүдәсен, аякларын көчкә сөйрәп кайткан көннәре дә еш хәзер. Юк шул, тиз генә онытылып китеп булмый икән. Киресенчә, уйлый башлау белән, бар тормышы, барлык гамәлләре, бөтен нечкәлекләрен актарып, күз алдына килә дә баса.

Разиясе ташлап теге дөньяга киткәч, нурсыз, шыксыз калган өенә кайтып керүе була, бөтен уен хатыны, балалары белән уздырган гомере биләп ала. Әй, яши белмәде. Бер генә дә яши белмәде шул. Үзен бетерде, хатынын бетерде, балаларын үзеннән биздерде, аларда элекке елларда үзенә карата булган ихтирам, аның белән горурлану хисләрен юкка чыгарды, салып таптады. Инде хәзер күпме генә яшь түксә дә, ярлыкау сораса да — файдасыз: ни хатыны, ни балалары аны күрми дә, ишетми дә. Өйләренә шулай да йә өрәк, йә күбәләк булып кайткалап йөридер йөрүен Разия. Үзе үлгәч, Сәйфулланың ниләр эшләвен, ничек яшәвен күзәтеп торадыр, бәлки. Тик ул аны барыбер гафу итмәячәк, гомере буе кыйналган тәне һәм җаны өчен нәфрәтләнәчәк кенә. Кем белә, бәлки, кызганып та куяр.

«Йа Алла! Аннан башка шулай саташып, тилмереп йөрисемне ник алдан кисәтмәдең, нигә үз башыма кылган бу явызлыкларымны беркайчан да эшләмәслек камил акыл салмадың, нигә зиһенемә яшел елан агуыннан зәгыйфьләнергә ирек бирдең, нигә башымны югалтып көнләшүемә юл куйдың?» — дип дәгъвалады Сәйфулла. Бу дәгъваның үзенә генә, бары үзенә генә әйтелгән булуын да аңлый югыйсә, чөнки бары үзе әмәлләгән тормыш тәгәрмәченең гаиләсен һәм, ахыр килеп, үзен үк изеп китәсен белмәслек кеше түгел иде. Тыела гына алмады.

Бүген дә төнен йокламый чыккан Сәйфулланың уйлардан башы күпте. Таң аткач та әйләнгәләп,

боргаланып шактый ятканнан соң, уйларыннан качу өчен сикереп торды да, әле бер, әле икенче бүлмәгә кереп, арлы-бирле йөренә башлады. Нишләргә? Җанына кайдан тынычлык табарга? Әллә инде барысын да искә төшереп торучы уйлардан саташып, йә булмаса, үлеп кенә арынып буламы? Эчеп онытылыр иде — эчә алмый хәзер. Разиясенең үлеп ятуын күргән мизгелдән аракыдан күңеле кайтты, бизде, эчә алмас булды.

Йөренә торгач, кухняга килеп керде. Тәмәкесен кабызды. Әллә ни күп булмаса да, кара-каршы утырып, хатыны белән чәй эчкән чакларын күз алдына китерергә тырышты.

Разыя (хатынына шулай дәшә торган иде), Разыя, дим, чәең кайда? Нәрсә җебеп каттың? Тиз бул, ашыгам! Юк, юк, алай түгел, Разия карчыгым, чәең әзерме? Әйдәле, бергәләп чәйләп алыйк булмаса, дип әйтәсе килде аның. Эх, исән булса, шулай дип әйтер иде хәзер. Аннан башка яшәүнең яме китүен, гаҗәп авыр икәнен татып белгәч, хәзер кадерләп кенә яшәр иде дә бит. Үткәнне кире кайтарып булмый шул!

Нигә мондый булып чыкты соң бу тормыш? Яратты бит ул аны, үлеп яратты. Аңа карата төксе, усал булса да, үзен-үзе белештерми җәберләсә дә, гомере буе яратып яшәде. Бары аны гына яратып торды. Өч баласының анасы булганы өчен икеләтә, өчләтә яратты. Ник болай булып бетте соң? Көнләшүе юләрләрчә булдымы, араны боздылармы, әллә инде, гаиләдә мин патша дип расларга тырышып, таякны артык бөгеп ташладымы — нәтиҗәдә бар да шартлап сынды.

Хатынына сокланып карарга да курка иде Сәйфулла. Күз тидерә күрмим дип. Үзе шәһәр кызы, үзе чибәр, үзе уңган: пешергән ашлары — телең йотарлык, балаларына, үзенә, иренә теккән киемнәре — иң соңгы мода белән, үзе укыткан мәктәбендә дәрәҗәсе гаҗәеп зур. Мондый хатынны яратмау гөнаһ булыр иде. Шуңа күрә көн саен чит ирләр сиңа карадымы? Берәрсе белән очраша торгансыңдыр әле, дип, әшәке теле белән бер сәбәпсез рәнҗетә иде ул аны. Соңга таба телдән йодрыкларга күчте. Хатынының гына түгел, балаларының да күз яшьләренә әйләнә иде аның бу вәхшилеге. Хатынны никадәр рәнҗетсәң, шулкадәр ул сине яратачак, буйсынып торачак дигән хайвани уй идарә итә иде аның белән. Торган саен ныграк усалланды Сәйфулла. Шуңа да карамастан хатынының аны тәмле ризыклар пешереп көтеп торуын, өстәл янына килеп утыргач та әле тегесен, әле монысын куеп сыйлавын ниндидер гаебен юарга тырышу дип кабул итә иде. Үзенең тиле уйларына үзе ышанып, китергән ашларын идәнгә сыпырып төшереп, сугып әйләндергән чаклары да шактый булды. Соңгы вакытларда карчыгым дип яратып эндәшүен, кочып үбүен хәтерләми ул. Хатынны үзеңнән билгеле бер ераклыкта тотарга кирәк, шулай булса гына аның сиңа тартылу көче ныгый, көчәя бара дигән фикерне алга сөрде. Менә әле дә, шушы чәй өстәле янына кара-каршы утырып, матур итеп чүкердәшеп, бергә чәй эчкәннәрен хәтерләми ул. Булды микән андый чаклар? Бәлки, тормышлары башында булгандыр. Ә ул вакыт бик еракта калды — искә дә төшерерлек түгел. Ә менә хәзер утырыр иде, бик утырыр иде. Күзләренә генә карап, теленнән төшкән һәр сүзен эләктереп алып, сорауларын җавапсыз калдырмыйча, матур яшәү рәхәтлегенә мәмнүн булып утырыр иде. Юк шул, юк!!! Югалтты, мәңгегә югалтты.

Ә бит өйләнгәч тә бер ун-унбиш еллап кеше сүзенә карап, кеше сүзе белән яшәмәде Сәйфулла. Ул чакта да арага керергә теләүчеләр күп булды. Эчми иде, үз башы бар иде. Офицер буларак төрле җирләрдә яшәргә туры килде аларга, чит илдә дә торып кайттылар. Фин сугышы башланды. Аннан кайтып озак тормады, Ватан сугышына китте. Хатынын этиләренә кайтарып куйды. Ерак тылда яшәгән хатыныннан килгән сагыну, ярату хатлары аны үлемнән коткарып калды, яраларын тизрәк төзәтеп, туган җиренә кайтарды. Өзелеп сагынган Разиясенең шатлыктан елый-елый шешенеп бетүләре, кала кызы булуына карамастан, авыр сугыш җәфасын авыл хатыннары белән беррәттән тартып, җиңүне якынайтуга үз өлешен кертүе — бар да исенә төште Сәйфулланың. Онытканы да юк. Онытмаячак та. Искә генә төшерергә кирәк.

Сугыштан кайтып, берничә ел яшәгәч бозыла башлады Сәйфулла. Авыр яраларыннан соң хәрби хезмәткә яраксыз булып калгач, тыныч тормыш хезмәтенә күчеп, командировкаларга йөри башлагач, һәрдаим кеше сыйлаулар (эше шундый иде) кире якка үзгәртте аны. Сыланырга гына торган хатыннарның да моңа «ярдәме» зур булды. Үзе шундыйга әйләнгәч, хатынына карата да фикере нык үзгәрде. Мин өйдә юк чакта бу да тик кенә тормыйдыр әле дигән уй миен бораулый башлады. Өч баласы да киртә түгел иде. Хатын-кыз теләсәме — су түгәргә чыкканда да ... дип, үзен-үзе котыртты. Үз фаразына үзе ышана башлады. Шуннан китте көнләшү...

Эшеннән, командировкасыннан эчеп кайткан саен хатынын җәберли торган булды. Исерек баштан кыйнап ташлый йә балалары белән бергә урамга куып чыгара башлады: кайда йөрдең, шунда кит, янәсе. Соңга таба, аның кайтып килүен алдан ук күреп алып, хатыны белән балалары йә күршегә, йә мунчага кереп кача торган булдылар. Койма буйларында качып төн чыккан чаклары да аз булмады.

Тора-бара аек көннәре сирәгәйде Сәйфулланың. Дуслары белән дә эчте, үзе генә дә эчте. Дошманнары да сыйлады: кем күптәнге үчен алды, кемгәдер аның урыны кирәк булды. Эчте-эчте дә хатынын кайтып кыйнады, балаларын эт итеп сукте. Аның акайган күзләренә карап, дорфа тавышыннан дер-дер калтырап, хатынының, балаларының үкси-үкси елавы аңа ләззәт бирә башлады. Үзенең кемлеген күрсәтер өчен, өс-башын да салмыйча, җыйган чиста урынга менеп ятып, төкеренер, саз ерып кайткан итегенә ябышкан пычракны юри урын-җиргә сылар иде. Сикереп торып, янә гаиләсен җәберләргә тотыныр иде. Соңгы вакытта гомерен шулай уздыра торган булды Сәйфулла. Кешеләр дә белделәр, күршеләр дә күрделәр: ныгытып торып тәртипкә чакыручы булмады, хатыны да аның өстеннән шикаять белән йөрмәде. Балалар укып чыгып зур кеше булдылар. Әтиләрен алар да үзгәртә алмады. Үз тормышларын үзләре алып барырлык булгач, бу тавышлы, җәнҗаллы өйдән тизрәк китү ягын карадылар. Китүен киттеләр, тик әниләрен алып китә алмадылар. Ул калды. Шул ук кимсетелүләргә, рәнҗетелүләргә, кыеннарга түзәргә калды. Йөрәкләре әрнесә дә, балалар берни дә эшли алмады. Тиз арада гына кайтып-китеп, хәл белешеп кенә тордылар.

Икәүдән-икәү калгач, әдәпкә килеп, бер-берләренең кадерен белеп кенә яшәргә иде дә бит. Чир китә, гадәт кала, диләр. Дөрес тә. Инде гадәткә әйләнеп беткән «чиреннән» арына алмады Сәйфулла. Шул гадәте аркасында дус-ишләре, туганнары белән дә бозылышып бетте. Сәйфулла белән беркем аралашмас булды.

Көннәрдән бер көнне Разия урыныннан тора алмады. Бөтен дөньясы ут яна, кайсы җире авыртканын да сизмәс булды. Торып, ашарга да пешерә алмады. Көне буе ач ятты. Кибеп ярылган иреннәрен чылатырга су бирүче дә юк — балалары читтә. Кичен өйдән дулап чыгып киткән ире әле һаман кайтмаган. Кайткан хәлдә дә ничек буласын бер Хода гына белә. Бәлки, кайтмаса хәерлерәктер дә.

Кайтты Сәйфулла. Ишекне тибеп ачуыннан дерт итеп киткән Разия аның нинди хәлдә кайтуын бик тиз аңлап алды. Ирен каршы алыр өчен сикереп тормакчы булды — хәлсез аяк-куллары, гәүдәсе аңа буйсынмады. «Әһә, мине санга сукмыйча тормый ятасыңмы, юри усалланып ятасыңмы, кәнтәй, хәзер мин сине торгызам», — дип, хатынын урын өстеннән сөйрәп төшереп эченә тибә-тибә кыйнады Сәйфулла. Үзенең кемлеген күрсәтте. Исерек иде. Күңеле булганчы издә дә, хатынының өстенә төкереп, янә чыгып китте.

Таң алдыннан гына әйләнеп кайтты. Ишекне гадәтенчә тибеп ачты да түргә узды. «Разыя-а-а!» дип акырып җибәрде. Җавап бирүче булмады. «Ах син, тегенди-мондый!» дип сүгенә-сүгенә йокы бүлмәсенә керде. Коточкыч усал тавыш белән «Разыя-а!» дип кабат кычкыру өчен авызын ача гына башлаган иде, идәнгә күзе төшеп катып калды. Бердән айнып китте. Кичә кыйнап калдырган җирендә хатыны үлеп ята иде. Йөзләре, тәннәре шешенгән, тимгел-тимгел. Ирен кырыеннан кан саркып чыккан. Сәйфулланың авызыннан каһәрләнгән «Разыя-а!» урынына үзәк өзгеч «Разыя!» илереп чыкты.

Элек шактый зур урыннарда эшләгәнгә күрә, элемтәләре нык булганлыктан, хатынын ярдырырга бирмәде Сәйфулла. Әбиләр чакыртып, тиешенчә укытып, ислам дине кушканча, бөтен йоласына туры китереп күмдерде. Мәрхүмә бу дөньядан йөрәк чиреннән китеп барды дип уйлады бар да. Балалары да кайтып өлгерде. Тик аны исән килеш кенә күрә алмый калдылар. Әниләренең газаплы үлем белән үлгәнен белсәләр дә, тавышланып, әтиләре белән мөнәсәбәтләрен ачыклап тормадылар. Әниләрен күмеп кайтуга, җыендылар да китеп бардылар.

Инде менә елга якын ни хәбәрләре юк, ни үзләре күренми. Телефоннан да шылтыратмыйлар. Әниләренең гомер буе тилмереп яшәвен күреп үскән балаларның күңелендә әтиләренә карата нәфрәт кенә җыелып калды.

Менә көннәр буе эшләп кайта да ничә ел гомер иткән өендә, утын да алдырмыйча, япа-ялгызы уйларына чумып утыра Сәйфулла. Ни туганнары килми, ни күршеләре керми, ни балалары кайтмый — барысының да күңелендә боз, кайчан да булса эрерме, билгесез. Инде эчми дә. Эше бетү белән вакытында өенә дә кайта. Тик ашарына пешереп, өен җылытып каршы алучы изге җан гына юк. Үкенә, бик үкенә Сәйфулла. Кешечә яши белмәгәненә, дөньядагы иң гүзәл хатыннарның берсе булган Разиясенең кадерен белмәгәненә, сакламаганына, җәберләвенә, балаларын тыныч гаиләдә үстермәвенә үкенә ул хәзер. Тормышының мәгънәсезгә узганынамы, ниһаять, карчыгын өзелеп-өзелеп сагынуданмы, әллә барысыннан дамы, инде үзе үксеп-үксеп елый Сәйфулла.

Инде берничә көнләп капкаларыннан кеше кергән-чыкканы күренмәгәч, хафага төшкән күршеләре, ни булды икән, дип кереп карарга булдылар. Ишек эчтән бикләнмәгән иде. «Сәйфулла, Сәйфулла!» дип эндәшеп тә карадылар, беркайдан да тавыш килмәде. Түргә узганнар иде — имәнеп киттеләр: бүлмә уртасында идәндә, күзләрен түшәмгә текәп, авызлары чалшайган Сәйфулла ята иде.

*1991*

## Соңгы хәбәр

Әлфинур, очына-очына, бәйрәм өстәле әзерләп йөри иде. Кунакларның инде шактые килгән. Ирләр бер почмакта гәп корып утыра, ә хатын-кызларның берничәсе Әлфинурга табын әзерләшеп йөри. Кинәт ишек кыңгыравы күңелләргә гаҗәеп ятышлы көен уйнап җибәрде. Әлфинур, ашыга-ашыга, ишекне барып ачты. Ишек төбендә авызлары колакка җиткән авылдаш ахирәтләре басып тора иде. Көтмәгәндә-уйламаганда килеп чыккан бу очрашуны зур шатлык итеп кабул иткән Әлфинур, күгәрчендәй гөрләп, ахирәтләрен чишендерде дә кунак бүлмәсенә алып кереп китте: яңа килгәннәрне башкалар белән таныштырды. Кунакларның барысы да диярлек бер як кешесе булып, берсен-берсе элек күрмәгән булса да, ишетеп белә иде. Ул арада чакырылган башка кунаклар да килеп җитте. Шау-гөр килеп киемнәрен салдылар да кунак бүлмәсенә кереп утырдылар. Китте сөйләш, китте көлеш. Авылдан килгән ахирәтләрнең берсе — өлкәнрәге, җаен туры китереп, Әлфинур артыннан кухняга ияреп керде. Сүзен нидән башларга белми, ык-мык килеп тора башлады.

— Йә инде, сузма, әйт тизрәк, ни булды? — диде Әлфинур, ахирәтенә сүз башларга ярдәм итәр өчен.

— Кыз, син бер хәбәр ишеттеңме әле?

Әлфинур сагаеп калды.

— Нинди хәбәр, кыз? Яхшы булса да, яман булса да турысын әйт. Күтәрергә тырышырмын.

— Ни бит, кыз, берничә көн элек Данияр үлде бит. Мин дә шунда идем.

Әлфинурның күз аллары караңгыланып китте, йөрәге чәнчеп авырта башлады. Ахирәте, Әлфинурның бу хәбәрне авыр кабул иткәнен күреп торса да, берьюлы әйтеп бетерим дип ярып салды:

— Үлгәндә дә исемеңне кат-кат әйтте. Һаман сине исенә төшерде. Бу дөньядан бары синең исемеңне әйтеп китеп барды, мәрхүм, — диде дә тыела алмыйча елап җибәрде.

Әлфинур баскан урынында катып калды. Башы бер мизгелгә уйлаудан туктады, сүз әйтергә теле әйләнмәде. Кинәт, аңына килеп, ахирәтен кочып алды да, башын җилкәсенә салып, йөрәк сыкравына буйсынды.

«Онытмаган икән, яратуы көчле булган икән, гомере буе мине уйлап яшәгән икән...» Башына килгән беренче уй шул иде. Йа Хода! Ник ул бу турыда хәзер генә белде! Нигә иртәрәк түгел? Соң булса да аңлашырлар, бер-берсен гафу итәрләр иде. Әнә бит, үпкәләмим, соңгы сәламемне җиткерегез, дигән. Әлфинурның илереп-илереп кычкырасы, үкереп-үкереп елыйсы килде. Өй тулы кунакларның булуы гына сабырлык бирде, әмма күзләреннән ихтыярсыз ташып аккан күз яшьләрен ул тыя да, туктата да алмады. Үкенү дә, әрнү дә, гаҗизлек тә, гафу итү дә бар иде аларда. Яшьлегенең, инде күптән үткән яшьлегенең, үсмер вакытларының, кыз чагының бер чите кителеп төште. Данияр киткән, инде мәңге кайтмаска дип киткән. Үзе белән миңа булган мәхәббәтен, ихтирамын алып киткән. Яратмады, тиң күрмәде дип уйлап китеп барган бит. Алай түгел, түгел иде, Данияр! Яраттым мин сине, бик тә яраттым. Бары бер җөмлә, бер генә җөмлә араны бозды. Горурлыгым көчле иде, тикшереп-нитеп тормадым, аңлашып сөйләшәсем дә килмәде — араны үздем дә куйдым шул. Их, хәзерге акылым булса, шулай эшләр идеммени? Сине яратмаска мөмкин түгел иде, Данияр, дип сыкрады Әлфинур.

Әлфинурның әле дә хәтерендә: Даниярның, медицина институтының беренче курсын тәмамлап, авылга каникулга кайткан чагы иде.

Матур җәй ае. Әлфинурның ындыр табагыннан кайтып килеше. Җиденче сыйныфны тәмамлагач, каникулда акча эшләп алырга дигән ният белән урып-җыюда катнашып йөргән көне. Урамның икенче ягыннан Әлфинур танымаган матур, ыспай гына бер егет үтеп бара. Бу егет минеке булсын иде дип уйларга да өлгермәде Әлфинур, егет, урамны кисеп, аның каршына килеп басмасынмы! Шаккатты Әлфинур. Сүзенең тәэсир көченә шаккатты.

— Син икәнсең, Әлфинур, саумы? Узган ел гына сабый идең бит әле, быел мин кайтышка матур кызга әйләнгәнсең, — диде ул, елмаеп. — Данияр абыең булам мин, аръякныкы. Сезнең Хадимә апалар каршында безнең йорт. Беләсеңме безне?

— Беләм, ник белмәскә. Югары очтагыларны гына белеп бетермим мин. Син бит Нәби абзый малае.

— Әйе шул. Хадимә апаларга чыкканың бар бит инде синең. Берничә мәртәбә сине алар капкасыннан чыкканда күреп калдым да йөрәгемә салдым.

Моңарчы Әлфинурның егетләр белән болай кара-каршы басып сөйләшеп торганы юк иде. Кызарынды, тирләп чыкты. Шатлыгыннан күзенә яшьләр килде. Авызы кипте. Әй бу кыюсызлык! Бу халәттән чыгар өчен тизрәк китәргә кирәк. Телләре бәйләнеп көлкегә калмагае!

— Озак сөйләшеп тора алмыйм, үпкәләмә. Тизрәк әбәтне ашап килергә кирәк, юкса соңга калам. Сау булып тор! — диде дә Әлфинур каушавыннан чалыш-чолыш атлап китеп тә барды.

— Сау бул, Әлфинур! Бүген клубта «Таш чәчәк» дигән һинд фильмы, фильмнан соң биюләр, танцы булачак, чык, яме! — дип кычкырып калды Данияр.

Әй тинтәк, бу кадәр дә җебегән булырсың икән. Егет белән дә сөйләшә алма инде, дип, юл буе үзен сүгә-сүгә кайтты Әлфинур. Әмма күңеленә корт төшкән иде инде. Авылның иң чибәр егетләренең берсе аңа сүз кушты бит. Клубка чакырды. Әле үсмерлектән чыкмаган, бөреләнеп кенә килә торган шушы җебегән кыз шундый егетнең күңеленә хуш килсен инде. Сыйныфташ кызлары белсә, көнләшеп үләчәкләр.

Анысы да монысы, тик клубка ничек чыгарга? Фильм килгән саен клубта укытучылар кизү тора. Кышын хәтта алтынчы-җиденче сыйныф укучыларын куып кайтара торганнар иде. Хәер, инде җәй, җиденче сыйныф тәмамланган. Хәзер инде без җиткән егет-кызлар кебек. Бәлки, кумаслар дигән өмет чаткысы кабынды Әлфинурда.

Әлфинурның эштән кайтуын капка төпләрендә күрше кызы, ахирәте Тәнзилә көтеп утыра иде. Әлфинур аның янына килде.

— Кыз, кичен клубта индийский фильм була, барабызмы? — диде шыпырт кына, үзенекеләр ишетмәсен өчен. — Барабыз дисәң, мин әзерләнеп торам. Син мине кереп алырсың, яме. Ату безнекеләр синсез чыгармыйлар.

— Кумаслар микән соң? Адәм мәсхәрәсенә калмабызмы егетләр алдында? — диде Әлфинур.

— Ник кусыннар хәзер. Беренчедән, уку вакыты түгел — каникул. Икенчедән, без җидене бетердек бит инде. Өченчекөн беркемне дә кумаганнар. Әбер-чеберенә кадәр кино караган әле, — дип тынычландырды Тәнзилә.

— Ярый алайса, син әзерләнеп тор. Бергә барырбыз. Кереп алырмын. Минем әти нәрсә дияр бит әле. Чыкмыйсың димәсә ярар иде. Мин киттем. Соңга калам алайса, — диде дә Әлфинур, йөгерә-йөгерә үз капкаларыннан кереп китте.

Төшке аштан соң Әлфинурга эшләве әллә ни авыр булмады. Эссе дә ул кадәр тәэсир итмәде. Суны гына күп эчмәскә кирәк. Эчмәсәң, тузан да әллә ни сармый, битләр дә бозылмый.

Кичен Әлфинур белән Тәнзилә клуб каршысына килеп басканда, кеше шактый җыелган иде. Ишек төбендә билет алып, берәм-берәм керә торалар. Данияр Әлфинурны күрүгә, билетлар барып алды да алар янына килеп басты.

— Килдегезме, Әлфинур. Мин инде килмисең дип борчыла да башлаган идем. Рәхмәт килүеңә, шатландырдың. Әйдәгез керәбез, — дип, кызларны ишеккә таба алып китте.

Бу хәлгә Тәнзилә гаҗәпләнсә дә, бер сүз әйтмәде, сорашмады, сүзсез генә Әлфинур белән Даниярга иярде.

Фильм мәхәббәт турында иде. Әлфинур да, Тәнзилә дә, бигрәк тә янәшәләрендә егет утырганга, фильмны бик оялып, уңайсызланып кына карадылар. Җитмәсә, елата торган фильм. Күзләреннән генә түгел, борыннарыннан да акканга, кулларына яшереп тоткан кулъяулыклары лычма булды. Һай авыр да соң һинд фильмнарын карау: елатып, шешендереп бетерә. Җырларына кадәр үзәкне өзә. Шуңа күрә елап утыручылар бер алар гына түгел иде.

Фильм беткәч, шешенеп беткән күзләрен, кызарып чыккан борыннарын кешегә (бигрәк тә Даниярга) күрсәтмәс өчен, бер-берсенә астан карап елмая-елмая, күтәрелеп карамыйча гына, кызлар клубтан чыктылар. Данияр аларга иярде. Биюгә кергәнче, төн караңгылыгында тынычланып, бераз сулу алып, күз-кашларны тәртипкә китерергә кирәк иде. Данияр фильм турында, уйнаган артистлар турында үз фикерен җиткерде, кызларның да уйларын белде. Ун-унбиш минутлап һава сулаганнан соң, бергәләп янә клубка керделәр. Урындыклар җыелган, гармунчы бию көен уйный башлаган иде. Электән үк түгәрәк тоткан ике-өч пар очып-очып бии башлады. Данияр да Әлфинурны чакырды. Күңеле ашкынып торса да, Әлфинур чыкмады, уңайсызланды, оялды. Данияр аңа үпкәләмәде: ярар, икенчесен биербез, дип, Әлфинур янәшәсенә килеп утырды. Калган биюләрне гел бергә биеделәр.

Шул көннән ике арада мәхәббәт җепләре сузылды. Кыш айларында ешрак хатлар язышып, сирәк кенә күрешсәләр, җәй җиттеме, гел бергә булдылар. Кышкы каникулларда да, җәйге каникул вакытларында да авыл яшьләре укытучылар белән тирә-як авылларга концертлар куярга йөрделәр. Аларны үз районнарында гына түгел, якын-тирә район авылларында да белеп бетерделәр, шатланып көтеп ала торганнар иде. Шул чакларда Даниярның гаҗәеп матур итеп җырлавын концертта катнашучылар гына түгел, тамашачылар да хәйран калып тыңлый иде. Кат-кат чакырып җырлаталар, алкышларга күмәләр иде. Чибәрлеге дә бар. Әлфинур аны урысның Родион Нахапетов дигән артистына охшата иде. Кыз үзе дә төшеп калганнардан түгел: моңлы тавышы, тавышына туры китереп

сайлап кына җырлаган җырлары күпләрне елатты, аягын идәнгә дә тидермичә очып-очып биюләре бер генә кешене дә битараф калдырмый иде.

Шулай итеп, биш ел вакыт үтеп тә китте. Әлфинур инде, педагогия училищесын тәмамлап, укытучы булып эшли башлады, ә Данияргa әле тагын бер ел укыйсы бар. Хирурглар никтер җиде ел укырга тиешләр. Биш-алты елда гына бирелгән программаны үзләштереп җиткерә алмыйлар, күрәсең.

Шулай булса да, Даниярның теленә өйләнешү дигән сүз керде. Җае туры килгән саен кабатлады ул аны. Әле кайткач та шул турыда сүз кузгатты.

Әлфинурның ашыгасы килмәде, университетка кереп, хет берничә курсны бетерәсе иде дип уйлады ул. Теләген Данияргa да әйтте. Моңа да риза булды Данияр.

— Көтәм, кайчан дисәң, шунда өйләнешербез. Укыйсың килгәч укырсың. Мин дә тиздән эшли башлыйм, үзем ярдәм итәрмен. Шулай да иртәрәк булса яхшырак булыр иде. Укып бетергәч, мине чит илгә җибәрүләре бар. Әгәр өйләнсәм... Моны күңелеңә салып куй әле, ярыймы?! Уйлый торырсың. Ә хәзергә сине Казанга кунакка чакырам. Абыйларның сине күрәсе килә. Теге юлы бик ошатып калганнар иде. Киләсеңме? — дип сорады Данияр.

Әлфинур риза булды. Даниярның башы күккә тиде, кызның ризалык бирүенә бик сөенде. Кулларына күтәреп алды да күзләреннән, ирennәреннән үпте. Шатлыгыннан ни эшләргә белмәде.

— Әлфинурым, рәхмәт сиңа. Беләсеңме мин сине ничек яратам: сине уйлый-уйлый хыялыйга әйләнеп бетәм инде. Сиңа багышлап җыр алып кайттым. Тыңла әле. Ул синең өчен генә, — дип, матур тавышы белән җырны җырлап та күрсәтте.

Әкрен генә кояш батты,
Күк йөзе эңгерләнде,
Зәңгәр күктә ай калыкты,
Киңлекләр зәңгәрләнде.

Яшел үләннәргә кунды
Энҗе чык бөртекләре,
Төнбоекларның ачылды
Сөттәй ак керфекләре.

Шушындый матур кичләрдә
Кайда йөрдең, гүзәлем?
Дидем: «Синең өчен генә
Өзелә бит үзәгем».

Әйтмәсәм дә аңларсыңмы
Өзелеп сөйгәнемне? —
Төнбоек чәчәге кебек
Ач миңа йөрәгеңне.

Әлфинур хисләнеп тыңлады. Сөйгәненең матур, ихлас җырлавыннан күңеле тулды. Яратуының игечиге юк иде. Даниярның муенына сарыласы, шушы матур сүзләрне әйткән, аның өчен генә җырлаган иреннәреннән үбәсе, иркәләнәсе килде. Ах бу оялчанлык, уңайсызлану! Киртәне куя да тора, куя да тора. Бәлки, дөрес тә эшлидер, шулай кирәктер дә.

— Җанкисәгем, син Казанга киләсе көнне минем имтихан була. Мин беренче булып керергә тырышачакмын, борчылма. Әгәр инде алай-болай булып өлгермәсәм, син аптырама, үпкәләмә дә, зинһар, туры безнең тулай торакка кил. Мин егетләргә әйтеп китәрмен, каршы алырлар. Мин имтиханны биреп кайту белән абыйларга китәрбез. Алар безне көтә. Сөйләштекме?! — диде Данияр.

Килешенгән көндә Әлфинур бергә эшли торган укытучы кыз Людмила белән Казанга китте. Людмила — Казан кызы. Кайда нәрсә урнашканын әйбәт белә. Шуңа күрә Әлфинур бер дә борчылмады. Әйбәт кенә барып җиттеләр. Данияр каршы алырга килә алмаган булып чыкты. Сөйләшенгәнчә, тулай торакка киттеләр. Бүлмәдәш егетләр, чынлап та барыннан да хәбәрдар булып, кызларны аһ итеп каршы алдылар, имтиханга Данияр кайткач барасылар икән.

— Узыгыз, Әлфинур, утырыгыз. Хәзер кайтып җитә ул. Хәбәр килде — имтиханга кереп утырган инде. Данияр сезгә чәй эчерергә кушты. Чәебез әзер, чишенегез, өстәл янына узыгыз, — дип йөгерешә-йөгерешә чәй әзерли башлады егетләр.

Әлфинур да, Людмила да чәйдән баш тартты. Данияр кайткач эчәрбез, диделәр.

Шактый көтеп утыргач, Әлфинур, уңайсызланып:

— Кайчан кайтам диде соң? Озак булса, без китәбез, — диде.

— Юк, юк, — диделәр егетләр, дәррәү, — сез китеп барсагыз, безне бетерә бит ул, зинһар, көтеп торыгыз инде.

Шул арада бүлмәгә бер егет килеп керде. Аны гына көткән кебек, егетләрнең берсе:

— Айдар, син Даниярны күрмәдеңме, кайда икән ул, имтиханнан чыкты микән? — дип сорады.

— Кайда булсын инде, һаман шул теге кызлар янындадыр, — дип ычкындырды әлеге егет.

Егетләр әллә нишләп китте. Әлфинурга кайнар су сиптеләрмени: кабартмадай кызарып чыкты, күзләренә яшь килде.

Моны күреп, егетләрнең берсе:

— Нишләп кызлар янында булсын ул. Имтиханда бит. Соңрак кергән иде, әллә имтиханын бирә алмый ята микән? — дип әйтергә ашыкты.

Әлфинурга бу сүзләр җитә калды. Болай да егетләр бүлмәсендә аны көтеп утырганына хурлануы чиктән ашкан иде, әлеге сүзләрдән соң сикереп торды да:

— Без башка көтә алмыйбыз. Килгән иде, диярсез. Озак көтте, диярсез. Сәламемне тапшырырсыз. Хушыгыз! — диде һәм иптәш кызына хәлне аңлатып (Людмила рус кызы булганга, үзара сөйләшкән сүзләрне аңламый утыра иде) бүлмәдән чыгып киттеләр.

Людмила:

— Зачем, давай уж дождемся, — дия-дия, аңа иярде.

«Хәзер кайта ул, китмәгез инде» дип арттан әйтүләрнең дә тәэсире булмады.

Әлфинур ничек кенә тырышса да, күзләренә өелеп килгән яшьне кире җибәрә алмады — алар бите буйлап гөрләп агып төштеләр. Шулай да, баскычлардан төшеп урамга чыкканчы, үзен кулга алып өлгерде. Инде кая барырга?

Людмила, Әлфинурны тынычландырырга тырышып:

— Не переживай, ничего особенного не произошло. Все-таки надо было подождать, ведь расстроится. Может здесь подождем, — диде.

— Юк, юк, — дип каршы төште Әлфинур. — Көтмим дә, уйламыйм да хәтта.

— Ну хорошо, — диде Людмила, — тогда поехали к нам. Мама знает, что я с тобой еду, не поедешь же обратно.

Әлфинур риза булды. Кире кайтуының мәгънәсе юк иде. Өч көн бәйрәмдә нишләп ятарга кирәк!

Соңыннан билгеле булганча, Әлфинурлар китүгә, Данияр кайткан. Ерак китмәгәннәрдер әле, дип, артларыннан йөгереп чыккан. Анда сугылган, монда сугылган — аларны тапмаган. Егетләрне, безне алып кала алмаганга, нык ачуланган. Белер-белмәс теләсә нәрсә сөйләп йөргәненә Айдарга ныграк эләккән. Кая киттеләр, адресын калдырмадымыни, дип, бәгырьләренә төшкән. Нык борчылган, әлбәттә.

Әлфинур хезмәттәшенең әнисендә ике көн кунак булганнан соң, Людмила белән яңадан мәктәпкә әйләнеп кайтканда, ныклы карарга килә: бетте, мин моны гафу итмәячәкмен, хатларына җавап язмаячакмын, үзе белән очрашмаячакмын! Һәм шулай эшли дә.

Даниярдан моннан соң да ел буе килгән хатлары җавапсыз кала. Үзе белән очрашудан кача. Сөйләшергә дип махсус кайтып, капка төпләрендә сәгатьләр буе утырып, үзен көткәнен күреп торса да, янына чыкмый.

Аптырагач, күршесе Хадимә апага кереп елый Данияр. Аны яучы итеп барырга күндерә.

— Бәлки, ул миңа Нәби малае итеп кенә карыйдыр. Мин дә бит төшеп калганнардан түгел, тиздән хирург булачакмын. Мин аның бәхетле булуы өчен бөтен нәрсәне эшләргә, бөтен гомеремне аңа гына багышларга әзер. Бер-беребезне яратабыз лабаса. Аннан башка минем тормышым тормыш булмаячак. Үзе дә мине ташлап бәхетле булыр дип уйламыйм, мәхәббәттән алай гына ваз кичәргә ярамый. Күндер син аны, Хадимә апа, зинһар, гафу итсен. Әнисе белән дә сөйләш. Укытучым бит ул минем. Бәлки, ул ризалатыр. Бу эшне башкарып чыга алсаң, мәңге онытмас идем яхшылыгыңны, — ди.

Хадимә абыстайның да, әнисенең дә сүзе үтми Әлфинурга. Ул Хадимә абыстайны да «юк» дип кайтарып җибәрә.

Иртәгесен Данияр китеп бара. Күпмедер вакыттан соң өйләнә. Үзе әйткәнчә, тормышы тормыш булмый. «Матур гына» эчә башлый. Хатыны кыерсытуларга, эчүенә түзә алмыйча, балаларын алып, берничә мәртәбә китеп тә карый, ләкин, балалар хакына дип, кире кайта.

Үлем аны берничә тапкыр сагалап тора. Ә менә монысы алып киткән. Авыр туфрагы җиңел булсын, урыны оҗмахта булсын!

— Ашыккан Данияр, ашыккан. Илле бише тулды гына бит әле. Аңлашмыйча, минем белән бәхилләшмичә киткән. Казанга килми тормагандыр инде, нигә эзләп табып сөйләшмәде икән? Күңелендәгесен минем үземә әйтмәде икән? — дип өзгәләнде Әлфинур.

Болай җебеп утырып булмас. Кунаклар киткәч, рәхәтләнеп тагын бер елар әле. Борчуларны, күз яшьләрен беркемгә дә күрсәтергә ярамый, дип, йөзенә елмаю чыгарып, өстәл тирәли тезелешеп утырган, хуҗабикәне көтмичә генә үз эшләре белән мәшгуль кунакларның һәммәсен дә кыстый-

кыстый сыйларга кереште Әлфинур.

Ә күңелендә агылып килгән хисләрдән, яшьлеген сагынудан, Даниярның иртә китүенә хәсрәтләнүдән өр-яңа җыр туды. Соңгы сәлам турындагы җыр иде ул.

Авыр хәбәр килеп җитте тетрәндереп,
Ни дисәң дә, фани дөнья гаҗәеп тар:
Исемеңне кат-кат әйтеп дөнья куйды,
Исемеңдә синең, әйтче, нинди көч бар?..

*2002*

## Мәхәббәт фаҗигасе

Кайбер елны Фираяга туган көнен Арча педучилищесына очрашуга килгән курсташлары белән уздырырга туры килә.

Бу юлы да шулай булды: төрле елларда училищены тәмамлаган укытучылар, галимнәр, язучылар белән аралашып сөйләшкәннән соң, үзләренә белем биргән укытучылары белән күрешкәннән соң, Фираялар группасы, җыелышып, тулай торакның бер бүлмәсенә китте. Көн яңгырлы булганга, үзләре белән шашлык ясарга дип алып килгән әзер итләрен газда гына пешереп алып, төрледән төрле яшелчә, җиләк-җимеш кискәләп, матур итеп табын әзерләделәр.

Күпме вакыт күрешми торганнан соң очрашу шатлыгы, бөтен мәшәкатьләрне, кайгы-хәсрәтләрне, узган елларны әллә кайда калдырып, бик еракка китәсе килмәгәннәрен бер читкәрәк этәреп, яшьлек елларына, училищеда укып йөргән, сабыйлык та чыгып бетмәгән елларга алып китте. Күпме хатирә, күпме истәлек, күпме сагыш, сагыну!.. Барысы бергә буталды, күзләрне яшь сарды... Гомер нинди кыска! Инде егетләрнең берничәсе дөнья куеп та өлгергән. Алар инде ничә килсәң дә булмаячак. Гомернең яртысы үтелгән, калганын акыл белән, матур итеп, үкенмәслек итеп узып булса иде.

Бу уйлар, инде очрашу һәм туган көн кичәсе тәгәлләнеп, курсташларының төрлесе төрле бүлмәләргә таралышып йокларга яткач та китмәде Фирая күңеленнән. Күңеле тулуын, әллә кайдан, йөрәк түреннән өерелеп чыгарга торган үксүен тыярга тырышып, күз яшьләре ташкынга әверелмәсен дип, күзләрен йомды, тешләрен кысты. Йокыга китсә, бу халәттән котылыр кук тоелды. Тик кая ул йокыга китү! Җитмәсә, күрше бүлмәдә, үзәкләрне өзеп, баян елый. Чыгарылыш курс егет-кызларының соңгы кыңгыравы аларның күңелендә дә давыл куптарган.

Моннан утыз еллап элек Фираяларны төрле якка ташлаган аерылышу инде алар бусагасына кереп баскан. Аларның җырларын, моңнарын тыңлап ята торгач, түзмәде Фирая, өстәл өстендә калган ризыкларны алып, күрше бүлмәгә — үзенең яшьлегенә кереп китте.

Аның керүенә баштарак гаҗәпләнеп, аннан тартынып торсалар да, кем икәнен, нинди ният белән кергәнен белгәч, гел үз итеп, араларына алдылар. Фираяның күңеле алар белән дә тынычланмады, йөрәге ныграк әрнеп, ныграк бәргәләнә башлады. Араларында аның яшьлеген, эчкерсез мәхәббәтен искә төшереп, чибәр парлар утыра. Аларның бер-берләренә назлы карашыннан, җаен туры китереп бер-беренә кагылып, сыенып алуларыннан, урыннарын янәшә туры китереп утыруларыннан болар арасындагы чиста саф мәхәббәтнең кайнарлыгы, самимилеге тәҗрибәле күзгә нык ташлана иде.

И гомерләр! Әле кайчан гына ул үзе дә шулар кебек иде бит. Әле дә хәтерендә: беренче курста укый башлагач та аның, Наилнең, моңсу, сагышлы күз карашларын гел үзендә тоеп уңайсызлана иде ул. Башта аңа бөтенләй игътибар итмәде. Үзен һәрдаим күзләгәнен белсә дә, күрмәмешкә салышты. Өстәвенә аны башка бер кыз яратып йөри иде. Шул кыз белән сөйләшкән, шаярышкан булып, Фираяны үзенә игътибар иттермәкче, үзенә каратмакчы, көнләштермәкче дә булып карады. Битараф кешегә мондый хәйләләр тәэсир итәмени, кыз моңа игътибар да бирмәде. Ул гына да түгел, Фираяның яратып йөри торган егете бар иде, бәлки, шуңадыр да аның газабына, аның тилмерүенә артык исе китмәгәндер. Кем кемгә карамый да, кем кемне сөйми. Барысына да гашыйк булып буламыни?!

Өченче курска килгәндә, Наилнең хисләре ярларыннан ташып чыккан дәрьяга әйләнгән иде инде. Фираяны яратуын яшереп тора алмый башлады. Аның мөкиббән китеп сөюе йөзендә, хәрәкәтендә, бөтен кыланышында чагыла иде. Әмма көннәрнең берендә, Фираяның үзенә һаман да битараф булуын, игътибарсызлыгын күреп, боегып калды. Аңа нишләптер бу каникулдан ул үзгәреп, аны сагынып килер төсле тоелган иде. Аның кайнар мәхәббәте бу тәкәббер кызыйны бераз гына булса да җылытмады микәнни, үзенә карата шәфкатьлерәк итә алмады микәнни?! Үз партасын Фирая янәшәсендә сайлап алып, дәресләр буе, куллары өстенә башын куеп, кыздан күзен алмый карап тора

башлады. Дәресен укымады, күңеле төште, йөрәге әрнеде, янды, көйде. Бу халәтеннән чыгу юлын таба алмады. Хәтта Фираяга яратышып йөргән егетеннән килгән хатларны, әрҗәдән алып, яшереп калдыра торган булды. Бирмәде, үзендә җыеп барды. Ертып та атмады, ачып та укымады (шактый вакытлар үткәч кенә ул аларны Фираяга кайтарып бирде, әмма эш узган, егет белән кыз арасы өзелгән иде инде).

Дәресләрен укымагач, хәзерләмәгәч, башы икеле белән берледән чыкмады. Моңарчы яхшы гына укып йөргән егетнең кинәт кенә шулай үзгәрүе укытучыларның да кәефен кырды, билгеле, аптыраушта калдырды. Шулай йөри торгач, Наил бөтенләй төшенкелеккә бирелде.

Көннәрдән бер көнне аның белән бер фатирда торучы курсташы Искәндәр курс җитәкчесенә тыны бетеп йөгереп килеп керде. Йөзе агарынган, иреннәре дерелди, куллары калтырый. Берара сүзен әйтә алмый торды. Аннары, яшьләренә буыла-буыла:

— Наил асылынган, әле дә ярый өлгердем. Мин кайтып җитмәсәм, үләсе икән. Шул Фирая аркасында бөтен газабы да, укымавы да. Әйткәнне дә тыңламый. Нишләргә инде? Фираяны үлеп ярата, тегесе аңа карамый да. Бер-бер хәл кыласы иде, — диде.

Укытучылар, бу хәлгә бик пошынып, «бер-бер хәлне кылып» та куйдылар. Иртәгесен Фираяны педсоветка чакырттылар.

— Фирая, син Наилнең асылынганын ишеттеңме? — дип, йомшак кына сүз башлады куратор.

— Нәрсә? Кайчан? Ни өчен? Йа Ходаем, үлгәнме? — диде, борчылуы йөзенә чыккан Фирая.

— Үлүен үлмәгән, Искәндәр кайтып җитеп баудан алган. Әлегә хастаханәдә.

— Син, Фирая, безне игътибар белән тыңла әле, — дип, сүзгә кушылды училище директоры Мөнәвир Гәрәевич. — Наилнең сине ятраканын беләсеңдер бит?

Әйе дигәндәй, башын кагып куйды Фирая, йөзе кызарып китте.

— Менә шул, — дип дәвам итте директор, — синең битарафлыгың аны шул хәлгә төшергән. Неужели ул егет җәл түгел сиңа? Уку бетәргә ел ярым вакыт калды. Шундый авырлык белән укырга кергән бала. Әтисе килеп бик үтенгән, укытып чыгарыгыз, зинһар, дип ялварган иде. Егет тә сәләтле. Әгәр син ярдәмгә килмәсәң, ул бетәчәк, юкка чыгачак. Без сиңа аны ярат дип боера алмыйбыз, әлбәттә. Аны порукага ал, дип кенә үтенә алабыз. Укытып чыгарыйк инде бергәләп, ярдәм ит инде, зинһар. Сиңа сүзебез шул иде.

Укытучылар гына түгел, директорның да бөтен өметен үзенә баглавын күргәч, Фирая юк дип әйтә алмады, ризалыгын бирде. Аның «ярар» дигән сүзен ишеткәч, бар да җиңел сулап куйды.

Берничә көннән Фирая Наилнең сәламәтләнеп дәрескә килүен ишек төбендә көтеп алды да, коры гына:

— Бүгенге көннән дәресләрне бергә әзерлибез, син миңа, мин сиңа булышып укырбыз, — диде.

Наилдәге шатлыкның йөзендәгесен генә түгел, йөрәгендәгесен дә күрде Фирая. Йа Раббым, ул аны күккә чөйде мәллә? Аның «дәресләрне бергә әзерлибез» дигән сүзләре Наил өчен «мин сине өзелеп яратам» дию белән бер иде, ахры.

Көне буе очып кына йөрде Наил, шаярды, дәресләрдә җавап бирергә тырышты. Дәрес вакытында әллә ничә мәртәбә нур чәчеп торган күзләре белән Фираяга карап алырга да өлгерде. Аңардагы бу үзгәрешне шундук сизделәр, билгеле. Сизми мөмкин түгел иде, кычкырып торган үзгәреш иде бу. Эшнең нидә икәненә төшенгән курсташлары Фираяга хөрмәт белән карый иде.

Шул ук көнне дәрестән соң математика белән рус теленнән әзерләнергә калдылар. Бер бүлмәдә икесе генә. Наил каушады, кызарды, ни әйтергә белмәде.

Фирая, аңа бу халәтеннән чыгарга ярдәм итәр өчен:

— Йә, икеле капчыгы, нидән башлыйбыз? Әйдә, булмаса, өй эшләрен эшләп алыйк. Аннан күз күрер, — диде, елмаеп. Узган хәлне телгә алмады.

Аның төрттереп әйткән сүзләренә Наил үпкәләмәде, киресенчә, аның һәр сүзен көтеп алып елмая гына иде. Фирая ни дисә, барысына да риза ич ул.

Берничә айдан Фирая үзенең гаҗәеп зур, илаһи көчкә ия булуын аңлады: егет акрынлап үз табигатенә кайтты, икеләләр генә түгел, өчлеләр дә бер-бер артлы төзәлә торды. Кыз көннән-көн аңа игътибарлырак була башлады.

Беркөнне Наил, гадәтенчә, Фирая янына килеп басты да нидер аңлатмакчы, әйтмәкче булып сул кулын күтәрде һәм кинәт аска төшереп артына яшерде. Үзе кып-кызыл булды. Фирая аптырап калды: ни булган моңа, кулын ник яшерә?

— Яле, ни яшерәсең икән миннән? — дигән булып кулын үз кулларына алды һәм шаккатты: Наил сул кулына пычак белән «Фирая» дип уеп язган да, эзе ныграк калсын дип, шул җәрәхәткә язу карасы салган, шуңа күрә кулы кабарып шешеп чыккан иде. — Син нәрсә инде, Наил! Ычкына башладың мәллә? Инфекция кереп, кулсыз калуың бар бит. Нигә шулай эшләдең инде, ә? — дип, чын-чынлап

ачуланды Фирая, үзе эчтән җәлләп тә куйды.

— Ычкынырсың да синең белән. Исемеңнең йөрәгемдә генә түгел, тәнемдә дә уелып калуын теләдем. Мәңгегә! Белсәң иде син минем җанымда ниләр барын! Аңласаң иде! Болай тилмертмәс идең.

Шушы кадәр ярату да була икән дөньяда! Бу егетнең инде ничә елларга сузылган олы мәхәббәтенә, беренче мәхәббәтенә, сабыйларча самими яратуына сокланды, күңелендә аңа карата күпмедер дәрәҗәдә наз уянды Фираяның.

Шул кичтән соң алар аерылмас дусларга әйләнделәр. Фираяның бүгенге игътибарлылыгы, күңеленең Наилгә карата көннән-көн тартыла баруы ике арада озакка сузылачак җылы мөнәсәбәткә беренче адым иде. Моннан соң инде алар ниндидер көч ярдәмендә бер-беренә тартылып, шатлыгын да, кайгысын да уртаклаша торган булып киттеләр. Нәкъ шул көннәрдә Наил Фираяның егетеннән элек килгән хатлар төргәген дә кайтарып бирде, тезләнеп гафу үтенде.

— Бу ахмаклыкны сине үлеп яратуым эшләтте, зинһар, гафу ит, — диде.

Фираяның бу хәлгә бик ачуы килсә дә, эшне зурга җибәрмәде: шулай кирәк булгандыр, Хак Тәгаләнең әмере шулай булгандыр, инде өзелгән араны барыбер ялгап булмас дип уйлады. Йөрәге бик әрнесә дә үчләшмәде. Үзенә дә, аңа да яңа яра салмады.

Тик, ара өзелгән инде дип, Фирая ялгышкан булып чыкты. Язып-язып та хәбәр ала алмагач, Мәскәүдән ул үзе кайтып төште.

Яңа ел киче иде. Педучилищеның спорт залында бал-маскарад бара. Һәркем диярлек ниндидер әдәби әсәрдән бер персонаж булып киенгән, Наил белән Фирая — Онегин белән Татьяна. Менә залга керергә аларга да чират җитте. Кулга-кул тотынышып, тантаналы рәвештә, музыка астында барысын да шаккатырып килеп керделәр алар. Бу мизгелдә икесе дә гаҗәп гүзәл иде. Нәкъ шул чакта Фираяның күзләре эскәмиядә үзләренә карап елмаеп утырган бер егеткә төште. Шундук башы әйләнеп, йөрәге кысып куйды: Хәсән ич бу, аның Хәсәне.

Ул да булмады, Хәсән, урыныннан торып, аларга таба килә башлады. Тануын кара син аның: өстә — персонаж киеме, күзләрдә — ялтыравыклы күзлек. Үзеңнеке үзәктә шул.

Фирая уйларыннан айнып өлгергәнче, Хәсән аның каршына килеп тә басты. Уң кулын сузып:

— Разрешите вас пригласить на вальс, мадемуазель, — диде дә, Фираяны кочаклап алып, чыршы янына бөтереп алып та китте. — Сез бик гүзәлсез, туташ. Мин бик бәхетле, — диде.

Башта берни аңламаган Наил, бу парның күптәнге танышлар кебек сөйләшә-сөйләшә биюен күргәч, барысын да аңлап алып, залдан чыгып йөгерде. Фирая ике ут арасында калды.

Икенче биюгә чыкканнар гына иде, Фирая җыр укытучысы Зиннәт Хәсәновичның ашыга-ашыга үзенә таба килгәнен күрде һәм, биюен акрынайтып, аны көтеп алды.

— Фирая, — диде ул, артык дулкынлануын күрсәтмәскә тырышып, —нишләттең син ул малайны?

— Нәрсә булган тагын, Зиннәт Хасаныч?

— Нәрсә булганын үзе дә әйтми, мин дә ни уйларга белмим. Музыка бүлмәсенә кергән дә үксеп елап утыра. Бар инде, тынычландырып кил. Авыр сүз әйттеңме әллә? Син ник аның белән биемисең соң?

— Менә бит Мәскәү хәтле Мәскәүдән егетем кайткан, мин нишләргә тиеш соң инде хәзер? — диде Фирая, гаҗиз булып.

Кызның укытучы белән сөйләшүеннән шулай да кайбер нәрсәне аңлап алды Хәсән.

— Бар инде, Фирая, алай булгач, тынычландырып кил, мин монда утырып торырмын, — диде, күңелсез генә.

Фираяның кинәт кенә Хәсәннең кайтып төшүенә, Наилнең шундый җебегән булуына, шул сәбәпле көтеп алган бәйрәмнең яме китүенә ачуы кабара башлаган иде, әмма, Наил утырган бүлмәгә килеп кергәч, аның шулкадәр дә үксеп, үзен-үзе тыя алмыйча елап утыруын күргәч, әллә нишләп китте.

— Нишлисең инде тагын? — диде ул, аның янына килеп утыргач. — Син бит аның минем егетем икәнен беләсең, синең аркада хат та алышмый башлаган идек бит инде. Сәбәбен белергә үзе кайткан хәзер. Синең үпкәләрлегең дә, елап утырырлыгың да юк бит. Тынычлан да, әйдә бәйрәмгә керәбез.

— Син хәзер аның белән китәсеңме? Мине ташлыйсыңмы? Мин бит сине күрмичә, синең янәшәңдә йөрмичә яши алмыйм хәзер.

— Син нәрсә?! Ничек мине күрмисең ди? Без бит бер группада укыйбыз. Дәресләрне барыбер бергә әзерләячәкбез. Монда җебеп утырма, әйдә киттек. Мин Хәсән белән сөйләшергә, аңлашырга тиеш. Син бит бала-чага түгел, ул бит минем йөргән егетем ләбаса.

— Сөйләш, аңлаш, тик аның белән генә китмә. Мин сине бик авырлык белән таптым, инде югалтасым килми. Мин бит сине үлеп яратам, син хет беләсеңме шуны? Син булмасаң, миңа берни

кирәк түгел, кирәк түгел укуы да, яшәве дә. Бары син генә минем тормышым.

Фирая Наилнең каршысына килеп басты. Тынычландырыйм дип чәчләреннән сыйпады, җиң очыннан кулъяулыгын алып битләрен сөртте. Наил түзмәде, кызны үзенә тартып китерде дә биленнән кысып кочты, башын күкрәгенә куйды. Шулай бераз торганнан соң, тынычланып:

— Әйдә, бергә керик залга. Зинһар, ачуланма, яратуым хакына гафу ит, — диде.

Наил белән Фирая залга килеп кергәндә, уеннар башланган иде. Алар керү белән, Хәсән аның янына килеп басты. Наил эскәмиягә барып утырды.

— Йә, тынычландымы? Күреп торам, ул егетегез сиңа нык гашыйк. Син минем хатларыма шуңа җавап язмадыңмы?

— Түгел, Хәсән, аның өчен түгел. Синең хатларыңны ул алып барган, араны махсус бозу өчен. Мин син язмый дип уйладым. Әйе, ул миңа күптән гашыйк. Ул бик газаплана, Хәсән. Мәхәббәтенең шундый булганына газаплана.

— Ә син? Син аңа гашыйк булмый кала алырсыңмы соң? Күрәм: ул миннән күпкә яшь, чибәр, озын буйлы. Күз төшмәслек егет түгел, өстәвенә көн саен яныңда. Әнә бит, мин язмый дип, хат язудан да туктагансың? Синнән хат булмагач, мин нәрсә уйларга да белмәдем. Көн саен почтага йөгерәм. Инде бүген килгәндер, дим, булмагач, ярар, иртәгә килеп җитәр, дип өметләнеп, хыяллана-хыяллана чабам. Баксаң, сәбәбе бер елак малайда икән.

Хәсән соңгы сүзләре белән кызның күңелен күтәрергә уйлады, ә Фираяның күз алдыннан Наилнең интегүләре китмәде. Ни өчендер аны күбрәк якын итте ул бу минутта, җәлләде. Хәсән, Фираяның тагын да күңелсезләнүен күреп:

— Әйдә китик әле моннан, бердәнберем. Хәзер хуҗабикәң янына кайтабыз да, җыенып, Казанга, минем апаларга кунакка китәбез. Яңа елны шунда каршыларбыз, мин шуның өчен кайттым, — диде.

— Гафу ит, бүген синең белән беркая да бармыйм, Хәсән, — диде Фирая, катгый карарга килеп. — Мин хәзер чыгып китсәм, аның белән ни дә булса булачак. Зинһар, миңа рәнҗемә. Син акыллы, зирәк кеше. Мин башкача булдыра алмыйм.

Хәсән, күзләрен тутырып, Фираяга бик озак карап торды. Маңгаена тир бәреп чыкты.

— Мин сине сагынып, сине күрергә, Яңа елны бергә каршыларга дип ничә йөз чакрымнардан очып кайттым. Мин дә бит сине өзелеп яратам. Менә күрерсең: бу егет белән сезнең берни дә барып чыкмаячак. Мәхәббәтне елап кына, шау-шу күтәреп кенә яулап алып булмый. Андый юл — кызгандыру юлы белән тудырган ярату озакка бармый, нык булмый. Син шуны белергә тиешсең, балакай. Минем ярату — инде сыналган, акылга утырган җитди кеше яратуы. Кызганыч, син моны аера алмыйсың. Бәлки, вакытлар узгач, аңларсың да, тик соң булыр. Шуны да белеп тор: мин сине тиз генә оныта алмаячакмын, әлбәттә, бәлки, гомергә йөрәк ярасы булып калырсың, анысын вакыт күрсәтер. Тик мин сиңа ачулана да, рәнҗи дә алмыйм: яшьсең әле. Күп нәрсәне белмисең. Ярар, нәфис гөлем, сагынычым минем, сине артык борчыйсым, үземнең дә газапланасым килми, хуш! — дип тезде-тезде дә борылып та карамыйча чыгып китте.

Фирая янә ике ут арасында калды. Нишләргә? Бу бичара караңгы төн уртасында белмәгән җирдә кая бара хәзер? Ярый ла Казанга кадәр поезд булса. Ә булмаса?

Фирая, Наилне бөтенләй онытып, аның артыннан чыгып чапты. Аннан карады, моннан карады — Хәсән күренмәде. Киемнәрне биреп торучы хатын, аның, тиз генә киенеп, урамга чыгып китүен әйтте. Ул, өстенә дә кимичә, буран уйнап торган урамга ташланды. Хәсәннән җилләр искән иде. Күңеле тәмам төште Фираяның. Гөр килеп торган залга керсә дә керде, кермәсә дә керде. Аны анда шатлыгы йөзенә чыккан Наил көтеп тора иде. Килеп керүгә, Фираяны кулларыннан алып, биюгә чакырды.

— Борчылма, Фирая. Минем яратуым шулкадәр көчле ки: икебезгә дә җитәрлек. Шикләнмим: син дә мине яратачаксың, мин моның өчен барысын да эшләячәкмен. Үзең күрерсең, мин начар егет түгел. Тик ташлама гына мине, — диде.

Фирая Наилне тыңласа да, күңелендә Хәсән иде. Йа Ходаем, рәнҗетте бит ул аны. Аңлашырга, ни өчен хат язмавын белергә, өзелеп яратуын белдерергә дип кайткан иде бит ул. Бәлки, ул да үзен кая куярга, ни эшләргә белмидер. Кыз эчтән генә булса да аннан гафу үтенде. Үзенең юләрлек эшләвенә эче пошты. Бәйрәм кайгысы китте. Үкереп елыйсы килде.

— Наил, — диде ул, акрын гына. — Мин өйгә кайтам. Хуҗа апа, озак торма, дигән иде. Теләсәң, озатып куя аласың.

— Ашыкма инде, Фирая. Кеше таралганда кайтырбыз әле. Күңелләр дә ачылып китәр. Фирая, кал инде, кал инде!

— Юк, юк, биисем дә, җырлыйсым да килми хәзер. Елыйсым гына килә минем. Үгетләмә дә, калмыйм да. Киттем, хуш!

— Тукта инде, озатып куям мин сине. Тышта караңгы, буранлап та тора. Ялгыз йөрмәссең бит инде, мин булганда.

Алар киенеп урамга чыкканда, буран тагын да котыра төшкән, күзгә төртсәң берни күренми торган караңгы иде. Фираяның күңелендә ниндидер бер өмет чаткысы кабынды: бу коточкыч буранда, бәлки, Хәсән китмәгәндер, училищедан ерак тормаганын, адресын белә, бәлки, анда кайтып көтеп утырадыр. Әй шулай булса!

Ул адымнарын тизләтте. Ун минут дигәндә кайтып та җиттеләр. Фирая Наил белән тиз генә саубуллашты да өйгә кереп китте. Аны ачуы йөзенә чыккан хуҗа хатын — Саҗидә апасы каршы алды.

— Син, җүләр булмасаң, шундый егетне җебегән бер маңка малайга алыштырыр идеңме. Кешесе нинди бит аның: үзе акыллы, үзе чибәр, үзе зыялы. Минем кызыма караса, шундук бишкуллап биреп җибәрер идем, һич икеләнмичә, һәм ул гомер буе бәхетле яшәр иде. Минем моңа иманым камил. Юк шул, минем кызыма карамый шул ул, син дип башын югалткан. Ну, кызый, кемне югалтканыңны аңларсың әле, соң булыр. Синең нинди «хөрмәт» күрсәтүеңә карамастан, кереп, сиңа дип алып кайткан бүләкләрен калдырып китте. Чәй дә эчмәде хәтта, стансага төшеп китте. Мескен, каян кая хәтле кайтып бит әле. Үз кызым булсаң, тотып ишәр идем инде мин сине, кеше баласы шул. Әнә кара, күпме әйбер алып кайткан үзеңә. Безгә дә бит әле. Кадерен белмәгән нәрсә.

Хуҗа апа, ярсуына чыдый алмыйча, икенче бүлмәгә кереп китте. Аның сүзләре Фираяның болай да түгеләм-түгеләм дип торган күңелен ашып таштырды һәм ул караватына барып капланды, туйганчы елады. Апасы юатмады, өстәп тә бер сүз әйтмәде: тынычлансын, уйлансын дигәндер инде. Тик, берәр сәгатьләп вакыт үткәч кенә:

— Нәрсә, күңелең булдымы? Тор. Сиңа бераз акыл өйрәтмичә, кешене кешедән аера белергә кирәклеген аңлатмыйча булмас, ахры. Тор, тор, хәзер безелдәп ятма, алдан уйларга кирәк иде, — диде.

Фирая Саҗидә апасына кайтарып бер сүз әйтмәде. Торып, елаудан шешенеп беткән күзләрен юып килде. Шунда гына Хәсән калдырган әйберләргә күзе төште. Кыш уртасында ничек өшетмичә алып кайткандыр бу роза чәчәкләрен. Кыйммәтле француз хушбуеның тәмле исе бөтен өйгә таралды. Ә болары нәрсә тагын? Менә сиңа мә: каләмсез яза торган, чит илдән килгән шариклы ручкалар икән ләбаса (андый ручкалар дөньяга чыгып кына килә иде әле). Шундый ук ручкаларны Саҗидә апага да, кызы Рәдиләгә дә бүләк иткән булып чыкты.

Фирая бу Яңа елны фатир хуҗасы Саҗидә апасы белән каршылады. Йөрәгендә Хәсән алдында үзен гаепле итеп сизү, ничә ел яратышып йөргән кешесе белән бозылышуга сәбәпче булган Наилгә ачу катыш кызгану уелып калды.

Көннәр уза торды. Наил Фираяга булган игътибарын тагын да арттырды. Гел аның янында булырга, кәефен бозмаска тырышты. Укуын тагын да яхшыртты. Моны күреп Фираяның күңеле үсте, әлбәттә. Тырышлыгы бушка китмәде, димәк, педсоветның ышанычын да аклады: Наил училищены әйбәт тәгәлләп килә.

Хәсәннән бик озак хат килмәде. Фирая үзе дә язмады. Акланасы, акланып кимсенәсе килмәде аның. Бәлки, алар мәхәббәтенең сүрелүе яхшырактыр да. Үзеннән ун яшькә олы кешегә кияүгә чыгып бәхетле буламы, юкмы дип тә уйлап куя иде. Наил белән бәхетле булырмын дип тә уйламый иде ул. Чөнки Наил күпме генә тырышмасын, Фираяның егеткә карата мәхәббәт хисе кабынып китә алмады. Сүз дә юк, ул аны бик якын итә, йөрәгендә аерым бер урын да яулап ала алды. Тик Хәсән һаман уйда иде. Аның турындагы уйларны ничек кенә куып азапланса да, барып чыкмады: алар һаман саен әйләнеп кайта торган булдылар.

Көннәрнең берендә, Яңа ел вакыйгаларыннан соң ай-ай ярым вакыт узгач, Наил Фираяның кулына бер хат китереп тоттырды. Дулкынлануы, борчылуы йөзенә чыккан, куллары калтырый.

— Сиңа хат килгән. Үзең күргәнче, мин биреп шатландырыйм әле, дип алдым, ачуланмыйсыңдыр бит, — диде дә, күңелсезләнеп, борылып китеп барды.

Хат Хәсәннән иде. Фирая шатланырга да, борчылырга да белмәде. Нәрсәләр язылган икән бу хатта? Ул йөгерә-чаба бер бүлмәгә кереп утырды, тиз генә конвертны ачып, укырга кереште.

*«Исәнме минем кечкенә кыз!»* — дип башланган иде хат. Фираяның эченә җылы кереп китте. Күзләре яшьләнде. Юк, рәнҗемәгән аңа Хәсәне, рәнҗемәгән. Ачу да тотмый. *«Синең яшьлегең, кайнарлыгың, наивлыгың аркасында килеп чыккан теге хәлләргә үч итеп, сиңа хат язмый торуым өчен гафу ит. Минем тарафтан ул балалык, әлбәттә. Инде менә, хатамны төзәтеп, бөтен уй-фикерләремне язарга булдым. Кабул итсәң...»*

Ничек кабул итмәсен ди инде. Кабул итә, билгеле. Бик шатланып кабул итә.

Фирая, хатны укып бетергәч, җанындагы инде ничәмә-ничә көннәр авыр таш булып яткан газаплы кичерешләрнең эреп югалуын, күңеленең сафлануын, Хәсәннең шулкадәр дә олы җанлы булуын,

яратуының көчле икәнлеген тойды.

Наил хатның эчтәлеге турында сорамады. Бәлки, ул үзе сөйләр дип көткәндер. Кыз ул турыда берни әйтмәде. Әмма Фираяның күтәренке күңел белән йөрүеннән ул хатның әйбәт эчтәлекле булуын аңлады. Шул көннән башлап, Фирая белән Хәсән арасында хатлар йөрүе яңарды. Наил кулына эләкмәсен өчен, ул хатны фатиры адресына язарга кушты.

Инде дәүләт имтиханнарын бирер көннәр, училищены тәмамлап, төрле якларга таралыр вакытлар да якынлашты. Наил белән Фираяның тарихын белеп, кызыксынып күзәтеп йөргән курсташлары, укулар беткәч, алар берәр районга икесе бергә укытырга китәрләр дип уйлап йөриләр иде. Тик Наил белән Фирая гына бу темага кагылмады. Хәсәннән хат килгән көннән егетнең тынычлыгы китте, күбрәк кәефсез йөри башлады.

Шулай да имтиханнарын яхшы гына биреп чыкты. Укытучыларның да күңеле булды. Егет югалмады, әти-әнисенә шатлык өстәп, дипломлы белгеч булды. Үз районнарына эшкә билгеләнде.

Фирая, гел яхшы укып килгәнгә, имтиханнардан курыкмады. Әйбәт бирәсенә ышана иде ул. Шулай булып чыкты да. Аны Пенза өлкәсенә математика укытучысы итеп билгеләделәр.

Болай булгач, аерылу котылгысыз иде. Дөрес, бер юл бар барын — өйләнешеп, тегендәме, мондамы бергә китү. Тик әлегә алар моны хәл итәрлек түгел иде. Соңгы кичтә, саубуллашу кичендә, юк кына нәрсәдән үпкәләштеләр. Икесенең дә нервылары киеренкеләнгән, әйтеләсе сүзләр әйтелмәгән, ачыкланасы нәрсәләр һаман да ачыкланып бетмәгән булгангадыр инде. Аерылышу көне килеп җитте, ә алар һаман да икесе ике ярда. Кичен бер-беренә үпкәләшкән килеш аерылыштылар. Очрашу турында сүз куешмадылар. Фирая төнен йокламады: иртүк торды да поезд белән туган якларына кайтып китте. Язу да калдырмады. Насыйп булса, Ходай кушкан булса, эзләп табар, кайдан икәнемне белә дип уйлады Фирая. Тик хатлар да килмәде, үзе дә күренмәде, көн саен төшкә кереп кенә тилмертә торган булды. Педучилищеда укыганда кулдан гына тотып йөргән бу егет төштә кочаклап, үбеп, назлап, сөеп, Фираяның йөрәгенә төшә башлады.

Аерылышкан көннән утыз еллап вакыт узды. Наил Фираяның төшеннән китмәде. Елмая да килеп керә, елмая да килеп керә. Һаман бер киемнән: ап-ак күлмәк, кап-кара костюм-чалбар.

Көннәрдән бер көнне, педучилищеның 60 еллык юбилеен уздырып кайткан төндә, Фираяның бу төше кинәт үзгәрде.

Имеш, курсташлар, янә бергә җыелып, сөйләшә-гөрләшә урам буйлап бара. Наил дә шунда, һаман шул яшь килеш, шул ук кием, бераз тазарып, тулыланып кына киткән, имеш. Үзе борчулы. Фираяның күзләренә мөлдерәп карап торды да:

— Әйдә үзебез генә утырып сөйләшик әле, тынычрак урын табыйк та, — дип, Фираяны кочагына алып, башта кысып-кысып кочты, аннан, кочагыннан чыгармыйча гына, читтәрәк торган бер эскәмиягә алып барып утыртты. Үзе, аның каршына чүгәләп, кулларыннан тотты. — Күпме эзләдем мин сине, Фирая, күпме эзләдем. Шылтыратмакчы да булган идем. Хәзер мин сиңа шылтырата алмыйм икән бит, син үзең миңа шылтырат әле, менә минем телефоным, — дип, Фираяга ниндидер саннар яздырды. Имеш, эш телефоны. — Минем өем дә үзгәрде, өемне менә мондый тамга буенча табарсың, — дип, табут рәвешендәге ике рәсем ясап тоттырды.

Шуннан соң, бер-беренең күзләренә карашмыйча гына, бераз сөйләшеп утырдылар.

— Син, Фирая, минем янда Клара исемле хатын күрсәң, ачуланма, яме. Син юк идең бит, шуңа күрә танышкан идем аның белән. Үпкәләмә, яме, — ди, имеш.

Шуннан соң әллә ничек кенә аерылышып киттеләр дә, Фирая өенә кайтып керде, имеш. Бер караса, үз өе дә түгел икән. Наилгә шылтыратмакчы булып телефонга барса, номеры язылган кәгазьне таба алмый, имеш. Бары өенең билгесе ясалган дәфтәр бите генә ята.

— Наил, Наил, — дип елый-елый, Фирая телефон номерын эзләргә кереште. Шулай елый-елый уянып та китте.

Әле уянгач та бик озак елап ятты Фирая. Ул көнне көне буе үзенә тынычлык таба алмады. Нәрсә бу, ни әйтергә тели Наил? Ничек, кайдан белергә? Тикмәгә генә мондый төш кермәгәндер, дип борчылды Фирая.

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте киң, дип белми генә әйтмиләрдер шул. Нәкъ шул көннәрдә Фирая, көтмәгәндә-уйламаганда, Наилнең Казанда яши торган һәм инде егерме елдан артык күрешмәгән сеңлесе белән очрашты. Ул Наил турында сораштыра башлагач:

— Үлде бит ул, әле күптән түгел генә батып үлде, — диде. — Сине оныта алмады, өйләнеп тә карады, балалары да булды — аерылды. Синең фотоларың бүгенге көнгә кадәр өйнең түрендә эленеп тора. Беркемнән дә алдырмады. Хәтта әти белән әнигә, хатынына, балаларына да кагылырга кушмады. Мин куйдым, миннән башка кеше алмаячак та, диде. Үзе үлгәннән соң да шулай тора әле ул фотолар. Инде ул өйдә кеше дә яшәми. Әти дә үлде, әнине үземә алып килдем. Үләр алдыннан сине

телевизордан күргән дә, тавышы һаман шул икән, үзе генә бераз үзгәргән, тагын да матурайган, дип куйды. Шуннан соң озак тормады инде, мәрхүм. Буранлы көндә, соң булса да уң булсын дип, синең янга дип өйдән чыгып киткән дә, адашып, бәкегә барып төшкән. Гәүдәсен язын гына таптылар. Бигрәк авыр үлем белән үлде инде җанашым. Сине теленнән төшермәде, оныта алмады сине, — дип кат-кат тәкрарлады.

Фирая, бу сүзләрне ишеткәч, сыгылып төште. Күзләренә яшь тулды. Менә ни өчен борчылып кергән икән ул төшкә теге вакыт! Менә нинди хәлдә булган икән! Йа Раббым, авыр туфрагын җиңел ит. Урыны оҗмахта булсын! Җавап тотканда, тел ачкычлары бир!

Сеңлесе белән сөйләшкәннән соң, Фирая Наилнең әнисен дә барып күрде, аның рухы өчен дога кыл, дип, садака бирде. Кучтәнәчләр китерде. Елый-елый сөйләштеләр. Шул төнне Наил Фираяның төшенә яңадан керде.

Курсташлар тагын җыелышкан, имеш. Шау-гөр киләләр, җырлашалар, биешәләр.

Наил, Фирая янына килеп:

— Әйдә әле әнә теге бүлмәгә. Иркенләп сөйләшик әле соңгы тапкыр. Әйтер сүзем бар, — дип, Фираяны тынычрак бүлмәгә алып кереп китте, имеш. — Син, Фирая, миңа ачуланма инде. Мин бит очрашуга башка килә алмаячакмын. Яңа йорт өлгерттем. Ул моннан шактый ерак, аннары ул җирдән китеп тә булмый. Башка килә алмам инде. Хуш! Тик син мине онытма, сирәк кенә булса да исеңә төшер, яме, — дип тынычланып, башкалар белән саубуллашмыйча гына, матур гына чыгып китте, имеш.

Шул көннән соң Наил Фираяның төшенә бөтенләй кермәс булды.

*1999*

## Фатыйма үче

Йөрәге ярсуына чыдаша алмагач, елый-елый шешенеп беткән Фатыйма аннан-моннан гына киенде дә ахирәте янына чыгып йөгерде. Эчендәге ачуы күкрәгенә сыеша алмый чәчрәп чыгардай булганга, урамда үзен көчкә тыеп барды. «Ну укытам әле бу тәренең иманын. Укытам әле! Кеше алдында адәм рисвае итәм барыбер бу азгын хайванны», — дип, ирен сүгә-сүгә йөгерде ул.

Ахирәте бусагасын атлап керүе булды, тыеп килгән ачуы шартлап, кычкырып елап та җибәрде.

Ахирәте Айгөл, гадәтенчә:

— Ни булды тагын, һаман шуның аркасындамы? — дип сорарга да өлгермәде, Фатыйма, күз яшьләренә буыла-буыла, үзе тезеп китте:

— И-и-и, ахирәт! Теге тәре китеге тагын өстерәлә башлады бит. Тагын кемнедер тапкан... Берничә ай матур гына йөргәч, Аллага шөкер, акылына утырды бугай, шәт, иншалла, инде тынычлап яшәрбез, дисәм, кичә тагын кунарга кайтмады. Бүген иртән генә кайтып керде, күзләрен тондырып. Дежурда булдым, дигән була.

Фатыйманың тыела башлаган үксүе яңа көч алды.

Айгөлгә аны аркасыннан сөя-сөя, башыннан сыйпый-сыйпый тынычландырырга туры килде.

— Беләм мин аның нинди дежурда булганын. Сизенми, белми бу дип уйлыйдыр. Әнә Рәсимәнең ире дә атлаган саен дежурга дип чыгып китә, ә үзе Илһамия янында «дежур торып» кайта. Үзем гаепле мин, үзем. Чыкма бу гулящийга кияүгә, диделәр. Аның бит Казанда өстерәлмәгән хатыны калмады, яши алмассың, диделәр. Юк, тыңламадым. Минем белән алай булмаячак, янәсе. Үлеп яраткан күк иде бит йөргәндә. Миңа чыкмасаң кияүгә, асылынып үләм, дип, йөрәгемә төште. Үзем гаепле, үзем! Тегене ашыйсыңмы, моны ашыйсыңмы, моны киясеңме, бар ял ит, үзем эшлим, дип, янында биеп кенә торгач, шулай булмый хәле юк. Уйлап кына кара, улыбыз унҗидегә җитә, ә аның малае белән хет бер мәртәбә утырып ирләрски сөйләшкәне бармы? Киңәш биргәне бармы? Юк бит, — дип, кабат ярсып китте Фатыйма.

Бераз елап алып күңелен тынычландыргач, янә дәвам итте:

— Әзергә бәзер генә яшәгәч, ничек гүләйт итмәсен ди ул. Син мине аңламыйсың, минем эшем шул, дигән була. Соң бит инде, ахирәт, аның эше шул дип, теләсә кайда кунып йөргәненә түзеп торып булмый бит инде. Аерылып кына китәр идем, ул малайны ничек кулда тотармын. Атасыннан да хуже бит ул. Заманасы да әллә нindigә әйләнде, ичмасам. Әле, оятсыз, мине симез дип, тупас дуңгыз түшкәсе дип хурлый. Үзен белми. Үзе миннән дә симез бит югыйсә. Шулай бит, ахирәт? Түзмәдем, әйттем, әйдә икебез дә чишенәбез дә көзге каршына басабыз. Кайсыбыз тупасрак икән, кайсыбыз тоташ түшкә икән, шунда күрербез, дидем. Риза булмады, юкса күрсәтә идем инде үзенең нинди икәнен. Кием астында гына адәм рәтендә йөри бит ул, затсыз.

Нишлим, ахирәт, нәрсә эшләтим моны? Ничекләр генә итеп акылга утыртыйм икән бу әнчек кавемен? — дип, арлы-бирле йөренә башлады Фатыйма.

Ахирәтенең бу сүзләрен беренче генә ишетүе түгел иде Айгөлнең. Дөресен әйткәндә, аның ничә еллар буе шулай интегеп, ничә мәртәбә аерылырга омтылып та, аерыла алмыйча яшәвенә бераз ачуы да килә иде. Аңа нинди дә булса киңәш бирүнең дә файдасы юк: барыбер үзенчә эшли, үзенчә яши бирә. Айраты да инде, азгын тәкә, туя белмәде һаман. Егерме ел буе шушы хатынны елатып, вакытсыз картайтты. Күз яше төшәр дип тә курыкмый, күрәсең, дип уйлап бетерергә дә өлгермәде Айгөл, Фатыйма кинәт, нидер исенә төшкәндәй, елавыннан туктап, күз яшьләрен, кызарып чыккан юеш борынын сөртеп алды да елмаеп җибәрде.

— Карале, ахирәт, мин бу кәнтәйгә багышлап шигырь чыгарган идем, укып чык әле, син бу өлкәдә белгеч бит. Кирәк тапсаң, матурла, төзәт. Исемен атап, гәзиттә бастырып чыгарам мин аны. Туган-тумачалары, дус-ишләре белмиләр әле аның кем икәнен, үзем сөйләп йөрмәгәч. Фаш итәм мин аны бөтен дөньяга. Белсеннәр бар да. Ул-бу була калса, мине генә гаепле итмәсеннәр. Аны бит алар әүлия дип белә. Башка түзәр хәлем юк, — диде дә Айгөлнең кулына бер бит кәгазь китереп тоттырды.

Шигырь шактый озын язылган иде. Айгөл аны укып бетерә алмады, Фатыйма аның кулыннан кәгазь битен суырып алды да, сумкасына салып, тиз генә киенә башлады.

— Ахирәтем, чү әле, онытып торам икән, без бит бүген аның апаларына кунакка барырга тиеш. Әниләре дә, туганнары да килә. Шунда укыйм мин аны. Аларга төзәтелмәгән килеш тә бара. Менә күрерсең, йөзен кызартам, койрыгын кыскартам бүген мин аның.

Һәрвакыт шулай, елап килеп керә дә, сиңа сүз әйтергә ирек бирмичә, тыр-тыр килеп пулеметтан ата да яңадан чыгып йөгерә. Шулар арасына кереп берәр сүз әйтеп кара син, үзең генә гаепле булып каласың.

Фатыйма кызарып-пешеп өенә кайтып кергәндә, ире телевизор карап утыра иде. Күтәрелеп бер күз ташлау белән, әле генә ду килеп, үкерә-үкерә чыгып киткән хатынының тынычланып, ярсуы басылып кайтканын күрде. Айгөлгә эченнән генә рәхмәт укыды Айрат: тиз арада хатынының җенен бастырып җибәргән. Фатыйма исә, кичкә аласы үченең ләззәтен күз алдына китереп, шуңа кәефләнеп, тиз-тиз генә өй эшләрен бетерде дә мәҗлескә җыена башлады. Моңа кадәр иренең чалбарын үзе үтүкләп кидерә торган хатыны хәзер аны үзенә чыгарып тоттырды, моннан соң үзеңне үзең кара, янәсе. Тегесе тырыша-тырыша чалбар үтүкләргә кереште, әмма каршы сүз әйтмәде.

Бераздан, киенеп-ясанып, берни булмагандай җитәкләшеп, кунакка чыгып киттеләр.

Һаман этле-мәчеле, бер-беренә төрткеле сүзләр әйтеп кенә йөргәннәрен күреп туеп беткән иренең апасы, боларның матур гына култыклашып килеп керүләрен күргәч, сагаеп калды. Бер-бер хәл бар монда, Аллага тапшырдык. Мәҗлеснең генә ямен җибәрмәсәләр ярар иде, бик тыныч күренәләр болар, давыл алдыннан булмагае, дип уйлап куйды ул.

Кунаклар тиз җыелып бетте. Бер-берсе белән күптән күрешмәгән кук, ах та ух килделәр. Фатыйманың гүзәллеген мактадылар. Тавышы матур булганга, һәр мәҗлестә аны җырлатмый калмыйлар иде.

Бүген дә:

— Яңа җыр юкмы бүген? Нинди җырлар алып килдең? Әзерләнеп тор, — дип кисәтеп куйдылар.

Фатыйма, серле генә елмаеп, әле моңарчы яңгырамаган өр-яңа җыр алып килүен әйтте (теге шигырьне сөйләргә түгел, җырларга исәп итте ул).

Өстәл янына утырышып бераз ашап-эчеп алгач, җыр башлап җибәрделәр. Гадәт буенча башта һәр мәҗлестә җырлана торган җырларның берничәсен башкаргач, яңаларына күчтеләр. Чират Фатыймага җитте. Ул бер горурлык белән торып басты һәм Айгөл төзәтеп өлгермәгән баягы шигырьне, халык көенә салып, иренә туп-туры карап, җырлап та җибәрде:

Салкын җилләр исеп куйгач,
Кофтасын төймәләде.
Өйләнгәнчүк бер кеше дә
«Әйбәт» дип сөйләмәде.

Язмыш кушты микәнни соң
Юллар чалыштырырга.
Әле һаман туймадыңмы
Хатын алыштырырга?

Анда чабып, монда чабып,
Вакытың уздырасың.
«Мин сөймәгән ничә хатын
Бар икән?» — дип торасың.

Чит хатыннар күргән саен,
Күзеңне кыздырасың.
Эт тә алай өстерәлми,
Эттән дә уздырасың.

Илле яшең тула инде —
Йөрмә ишекләр шакып.
Азгынлыкның чиге бардыр —
Акыл керергә вакыт.

Җырлый-җырлый иренең җырга реакциясен күзәтте Фатыйма. Аның кызарып-бүртенеп, күтәрелеп карарга да хурланып утырганын күргәч, күңеле булды. Зәһәр елмайды. Агулы ук нәкъ ноктасына тигән иде. Хатыныннан моны көтмәгән, үз гомерендә мондый хәлнең булуын күз алдына да китермәгән, алла мәхлугы, үрнәк гаилә башлыгы булып йөргән Айрат туганнары, ата-анасы, дуслары алдында адәм рисвае булды. Җыр җырланып беткәч тә, хурлыгыннан күтәрелеп карарга да читенсенеп, урынына кадаклап куелган күк, кымшанмый утыруында булды. Аннан кинәт сикереп торды да, беркем белән дә саубуллашмыйча, киенеп чыгып китте. Бар да, үзләрен бу хәлдә гаеплегә санап, уңайсызланып утырдылар, ара-тирә Фатыймага күз ташлап алдылар. Фатыйма, күңеленең бер почмагы белән ирен җәлләсә дә, үзенең, баласының ничә еллар буена шулай кимсетелүен күз алдына китереп, үч алуына, Айратның, ниһаять, чын йөзен ачып сала алуына шатланып, тагын бер тапкыр канәгатьләнү белән елмаеп куйды. Өстәл яныннан торып, барысы белән дә баш иеп саубуллашып, бөтен кунакларны хәйран калдырып, ашыкмыйча гына җылы кофтасын барып алды да рәхмәт әйтеп чыгып та китте.

Бу көнне гомерендә беренче тапкыр өенә кайтмады, ахирәте Айгөлләргә кунарга китте Фатыйма.

*1992*

# Яшьлек хатасы

«Татарстан» поездына соңга кала яздым. Абына-сөртенә вагонга килеп кергәч кенә бераз тынычландым. Һай, өлгермим, дип куркудан ак-караны аермаган карашым күрше утыргычта мине серле генә елмаеп күзәтеп торган бер ханымга төште. Аның шулай текәлеп карап торуы мине бераз гаҗәпләндерде. Ашыга-ашыга әйберләремне урнаштырдым да үз урыныма җайлап утырдым.

— Нәрсә, танып җиткермисең мәллә? Йә-йә, кем инде мин? — диде ул, каршыма торып басып. Үзе һаман елмая.

Мин, аптырап, бу хатынның йөзеннән танышлыкны белдерүче сыйфатлар эзли башладым.

— Галимә, син түгелме соң?

— Мин шул менә. Ходай кушкач, күрешәсең икән аны. Йә, нихәл? — дип кочагын җәйде.

Мин дә, сикереп торып, аны кочып алдым. Галимәне күрүемә бик шат идем. Без әллә ни якын танышлар булмасак та, бер-беребезне белә идек, әмма күптән инде, бик күптән очрашканыбыз юк иде. Аның белән Мәскәүгә кадәр бергә барачакбыз икән. Нинди бәхет! Юл йөргән белә: юлдаш булып яхшы адәм туры килсә генә ярар иде, дип теләмәгән кеше сирәктер, мөгаен. Ул арада Салих Сәйдәшев маршына поездыбыз кузгалып та китте.

Мең шөкер, Ходам, өлгерттең бит тәки, дип шатланып куйдым.

Галимә, миннән өлкәнрәк булса да, һаман яшь, чибәр килеш сакланган. Бер дә үзгәрмәгән.

— Тфү, тфү! Күз тимәсен, Галимә. Бер дә картая белмисең. Утыздан артыкны бирмәссең, валлаһи, — дидем, чын-чынлап аның өчен шатланып.

— И-и-и, кайда инде ул яшь килеш калу! Әле яңа аякка бастым дияргә дә була. Сөйләсәң, адәм ышанмаслык хәлләр булды бит әле, дускаем. Һич көтмәгәндә. Үлемнән калдым бит мин. Әйе, әйе, бер дә арттырмыйм.

Ул бераз тын торды. Газаплы кичерешләрен башыннан кабат уздырды булса кирәк. Аннары, авыр сулап, сүзен дәвам итте:

— Инде, Аллага шөкер, барысы да җайланып килә. Күрәсең бит, менә ерак юлга чыгарга да тәвәккәлләдем. Исән-сау барып кайтам, Алла боерса. Болай булгач, исән калдым инде, — диде дә, барыбер минемчә булыр дигәндәй, кояштай балкып елмайды.

Без бер мәлгә тынып калдык. Тәрәзәгә карасак, поезд Юдинога якынлашып килә икән инде. Безнең купега башка кеше кермәде. Икәү генә барачакбыз, ахры. Бигрәк тә шәп. Борчучы кеше булмас. Иркенләп сөйләшергә дә беркем комачауламас.

— Беләсеңме, дускай, — диде Галимә, — минем белән соңгы елларда булган хәлләр турында әле

таныш-белешләрнең берсенә дә сөйләгәнем булмады. Син — беренче. Иң якын һәм шул хәлләргә нинди дә булса мөнәсәбәте булган кешеләр генә белә. Сиңа никтер барысы турында да бәйнә-бәйнә сөйләп бирәсем килә. Син үзең дә күпне күргән, авыр газаплар, хәсрәт кичергән кеше бит. Шуңа күңелем тартыладыр, ачыласы киләдер. Бер караганда, минем язмыш та күпләргә гыйбрәт булырлык. Кайчан да булса бу турыда язып чыксаң да каршы килмәм. Чынлап та гыйбрәт алырлар, бәлки. Яшь чакларда исәпләмичә эшләнгән эшләргә өлкәнәйгәч җавап бирәсе бар икән. Мин үзем турында гына әйтмим. Яшьләрнең күбесе шундый. Бер генә як гаепле була алмый. Гаеп атта да, тәртәдә дә буладыр. Тик үз вакытында моны аңлап кына җиткерә алмыйбыз. Шуңа күп очракта бар да үкенечкә кала.

Галимә сөйли-сөйли, мин тыңлый-тыңлый кечке чәй әзерләргә керештек. Аңа нинди дә булса сүз әйтергә, фикеремне җиткерергә курыктым — сөйләвеннән туктар да сүзе ярты юлда өзелеп калыр: сүз сөрешен югалтыр, аннары йә бөтенләй башлап китә алмас, җеп очын таба алмас дип шикләндем. Шуңа сүзсез генә тыңладым.

Галимә, бер-ике бавырсак кабып, чәен бер генә йотып куйды да, йә сүзләремне бәйләп китә алмам дигәндәй, хикәятен дәвам итте:

— Без Хәйдәр белән моннан утыз еллар элек Әлмәт шәһәрендә таныштык. Мин, мәктәпне тәмамлаган яшь кыз, бу шәһәргә килеп эшкә урнашкан идем. Тулай тораktан урын да бирделәр. Көннәрдән бер көнне шәһәребезгә, институт бетереп, дүрт инженер егет кайтып төште. Шуларның берсе, минем иптәш кызыма гашыйк булып, көн дә аның янына килеп йөри башлады.

— Галимә, — ди бу егет миңа беркөнне, — әйдә, мин сине үземнең дустым белән таныштырам. Әйбәт егет ул, үкенмәссең.

Эчтән генә уйлап алдым: кем икән ул егет? Нинди кеше? Мин яратырлык булырмы? Риза да димәдем, кирәкми дип тә әйтмәдем. Бөтенләй игътибар итми калу килешмәс дип, оялып кына елмаеп куйдым.

Берничә көн узды. Нефтьчеләр бәйрәме җитте. Берзаман болар, барысы бергә җыелып, безгә килеп кермәсеннәрме!

— Ни хәлләрдә яшәп ятасыз, кызлар, Әлмәт күгендәге якты йолдызлар? — дип сүз башлады берсе.

— Үзләре генә түгел, бүлмәләре дә балкый боларның. Үзебезнең кызлар бигрәк чиста, бигрәк уңганнар инде, тфү! — дип куйды икенчесе.

Мин егетләрне тиз генә күздән кичердем: боларның кайсы белән таныштырмакчы була икән мине иптәш кызымның егете? Шулай да берсенә күз карашым озаграк тукталды.

— Кызлар, җыеныгыз тизрәк, бәйрәмгә барабыз. Мондый көндә бүлмәдә яту килешмәс, әйдәгез, — дип, безне, ай-ваебызга карамыйча, бәйрәмгә — урманга алып чыгып киттеләр.

Элек бит, үзең беләсең, бәйрәмнәрдә урманга менүләр, җырлап-биеп ял итүләр, төрлечә күңел ачулар була торган иде. Бу бәйрәмне дә шулай уздырырга булганнар. Шау-гөр килеп чыгып киттек.

Саф һава. Тирә-як яшеллеккә төренгән. Әле анда, әле монда төрле тавышлар чыгарып сайраган кошлар, куышып очып йөргән төрле төстәге күбәләкләр, хуш исле аллы-гөлле чәчәкләр без утырган аланны сихри бер табигать хозурына әйләндергән. Шул сихрилектә без мәш киләбез. Гармун, баян тавышлары ишетелә. Кемдер җырлап җибәрә. Кызларның күбесе табын әзерли. Егетләрнең бер ишесе чыбык-чабык җыярга урманга кереп китте, ә кайберләре читтәрәк, авызларында чәчкә сабагын әйләндерә-әйләндерә, кызлар күзли. Мин дә теге егетне күзәтәм. Әйттем бит әле, бүлмәдә чакта күз карашым озаграк тоткарланды, дип. Шул егет инде. Шулай «күзләшә» торгач, безнең карашлар очрашты бит. Икебез дә уңайсызланып куйдык. Зифа буйлы, кап-кара кашлы, кара күзле, дулкынланып торган куе кара чәчле егет. Хәйдәр исемле икән. Бергә уйнадык, бергә җырладык. Көн кичкә авышкач, кайтыр юлга чыктык. Хәйдәрнең кулында фотоаппарат. Барыбызны да фотога төшереп йөрде. Берзаман минем янга йөгереп килде дә, фотоаппаратын җилкәмә элеп:

— Минем әле дустымны Азнакайга озатып җибәрәсем бар, моны асып йөрмим инде. Кайтканда кереп алырмын, яме, — диде дә иптәш егете белән тиз генә китеп барды.

Ә без кызлар белән театрга киттек. Фойега кергәч, көзгә каршына басып, чәчләремне төзәткәләп, өс-башымны рәтләп тора идем, ишектән Хәйдәр белән Вилсур килеп керде. Автобус булмаган икән Азнакайга. Безгә керсәләр, без өйдә юк. Кемдер әйткән, театрга киттеләр, дип.

— Беләсеңме?! — диде Галимә, очынып. — Бер күрүдә ярату дигән нәрсә бар бит ул. Син моңа ышанасыңмы? (Мин, ышанам дигәндәй, баш кагып куйдым.) Без дә Хәйдәр белән бер-беребезне бер күрүдә яраттык. Үлеп яраттык. Көн дә очраша башладык. Бер-бер сәбәп чыгып, килә алмаган чакларында өзгәләнеп, сагынып, елап бетә идем. Ул да мине нык яратты. Кадерлем, бер генәм, дип, гел назлап, минем өчен өзелеп торды. Ни әйтсәм, шуңа риза иде. Килешмәгән очракта да үз фикерен матур итеп үткәрә белә иде.

Шулай бер-беребезне яратышып-сөешеп берничә ай үткәндерме-юктырмы, беркөнне бик җитди кыяфәттә Хәйдәр килеп керде. Керә-керешли мине күтәреп алды да, күзләремә карап:

— Галимә, мин синнән башка яши алмыйм. Әйдә өйләнешәбез. Гаризаны иртәгә үк барып бирәбез, — диде, җитди итеп.

Шаярып-көлеп сөйләшсәм, ышанмас дип уйлагандыр инде.

Мин дә, җитди генә:

— Хәйдәр, җаныкаем, миңа да синнән башка беркем кирәк түгел. Тик болай, кинәт кенә кияүгә чыгып булмый бит инде. Әнинең рөхсәтен, фатихасын алып килергә кирәк. Рәнҗер бит ул безгә, аңа әйтмичә өйләнешсәк. Менә Яңа ел алдыннан кайтып рөхсәтен алып килермен. Аннары гаризабызны бирербез, яме! Әле синең кызны сорап киләсең дә бар бит, — дип, аның кочагына сыендым.

— Ничек дисәң, шулай булыр, алтыным. Тик озакка гына сузмыйк, ярармы, — дип ризалашты ул минем белән.

Яңа ел алдыннан мин әни янына кайтып киттем. Фатыйхасын алырга дип. Хәйдәр үбә-үбә озатып калды. Озак торма, ату саргаеп үләчәкмен, диде. Минем канатланып очып кире кайтуыма, Хәйдәремне читләр алган иде инде. Атна-ун көн генә тордым бит югыйсә. Әни янында гына булдым, әллә кайда да йөрмәдем. Кияүгә чыгарга рөхсәт алып киләм, икебезгә дә шатлык алып киләм, дип кенә киттем бит Әлмәттән.

Галимәнең күзләренә яшь килде. Бу хәлләр, онытылып бетмәсә дә, тынычрак кабул ителергә тиеш тә бит югыйсә. Юк шул, дистәләгән еллар үтсә дә, әле яңа гына булган кебек күңелгә якын икән. Хиссез кеше аның ише хәлләрне тиз онытадыр да, бәлки. Галимә кебек нечкә күңелле кешеләр өчен алар эзсез югалмыйдыр шул.

Ул эшләгән урында инде байтак вакыттан Хәйдәргә кызыгып йөргән, аны ничек тә үзенә каратасы килгән бер хатын бар иде. Мин юктан файдаланып, өйләнергә җыенуын да ишеткәч, «ятып калганчы, атып кал» дип, Хәйдәрне тиз арада үзенеке итү хәстәренә керешкән. Туган көнен уйлап чыгарып, мәҗлес җыйган, шунда дуслары белән аны да чакырган. Шактый исертеп, иркәләп, морадына ирешкән бу.

Мин Казаннан ризалык алып кайткан көнне берни булмагандай очраштык. Мин ул чакта чынлап та берни белмим, үзе сөйләмәде. Иртәгесен генә бу турыда ишеттем. Иптәш кызымнан. Бу хәбәр мине чак түшәккә салмады. Эчтән янсам, көйсәм дә, очрашуны дәвам иттем. Хәйдәргә аны-моны сиздермәдем. Ә аңардагы үзгәрешне күрми кала алмадым, билгеле. Ниһаять, беркөнне, ниндидер кичәдән кайтканда, ул, тезләнеп, аякларымны кочты һәм барын да сөйләп бирде.

— Кичерә алсаң, кичер мине, Галимәм. Миңа кирәк хатын түгел ул. Мәңге ярата алмаячакмын мин аны. Хаталандым. Эчмәскә иде миңа. Гаеплемен, чиксез гаеплемен. Галимә, кичер, зинһар! Мәхәббәтебез хакына. Хатамны төзәтергә мөмкинлек бир, — диде.

Бу юлы инде мин чыдап кала алмадым. Әйтәсе килгән сүзләремне тезә-тезә үксеп еладым.

— Ничек кичерим мин бу хыянәтне? Ничек ышаныйм мин сиңа! Бер атна бит, бер атна! Өйләнешергә сүз куешканнан соң ни йөзең белән эшләдең син бу эшне? Киләчәккә нинди ышаныч калдырдың син миңа? Мондый хыянәтне гафу итеп буламы? — дидем дә борылып китеп бардым.

Хәйдәр торараштай басып калды.

Бер-ике көннән, беркемгә берни әйтмичә, барысын да ташлап, Казанга кайтып киттем.

Бу минутларны Галимә кабат йөрәге аша үткәрде булса кирәк, тавышы өзек-өзек чыкты, бите буйлап, мөлдер-мөлдер яшь бөртекләре тәгәрәде. Хәзер елап җибәрәм дигән кебек, иреннәре кыйшаеп дерелди башлады. Әмма ул үзен бик тиз кулга алды. Гафу ит дигәндәй, күз яшьләре аша миңа бер елмаеп карады да, тирән сулу алып, дәвам итте:

— Дускаем, әйт әле миңа, син кичерер идеңме мондый хыянәтне? Кияүгә чыккан очракта да андый кеше белән бербөтен булып ничек яшәргә кирәк? Менә шуларны уйладым да, өзелеп яратышуыбызга нокта куеп, аны искә төшермәскә тырышып, башка тормыш белән, Хәйдәрсез генә яши башладым. Эшкә урнаштым. Әнием өчен дә бу хәл зур хәсрәт булды, минем өчен бик борчылды ул.

Күпме генә онытырга тырышсам да, оныта алмадым мин аны. Төшләремә кереп тилмертте: кочагын җәеп, кил, Галимәм, йөрәгемнең син дип өзелеп тибүен тыңла әле, мине ташлап озак йөрмә, саргаеп үләм синсез, дия-дия, төн саен җаныма төште.

Хәйдәр минем Казандагы адресымны табып, бер-бер артлы хатлар яудыра башлады. Аларның берсенә дә җавап язмадым. Җанымны өшеткәнгәме, саф хисләремне салып таптагангамы, мин аны гафу итә алмадым, хәтта дошман күрә башладым. Айлар буе бер җавап та ала алмагач, булмас дигәндер инде, теге хатынга өйләнде. «Балага уздым, өйләнмәсәң, эшеңнән кудыртам, партиядән чыгарттырам», — дигән. Мәҗбүри өйләнде, диделәр. Аңа карап бәхетләре булмады: ел ярым гына тордылар — аерылыштылар.

Әле шул ел ярым вакыт эчендә генә дә ике мәртәбә аерылышып алганнар. Уллары туган. Ул бала Хәйдәрнеке түгел, аңа хәтле үк ул йөкле иде, теге кешесе өйләнмәгәч, шундый юл белән баласына әти тапты, дигән кешеләр дә булды. Мин гөнаһысына кермим, анысын Ходай беләдер. Соңгы аерылышудан соң Хәйдәр, бөтен әйберен, хәтта киемнәрен дә калдырып, күлмәк-чалбардан гына икенче шәһәргә чыгып киткән. Эшкә урнашкан, фатир алган.

Минем һаман да кияүгә чыкмаганны белеп, яңадан хатлар яза башлады бу. Гафу үтенеп, кичерүемне, бергә булуны сорап.

Тәүге мәхәббәтем булганга, яратуым да һаман сүрелмәгәнгә күрә, йөрәктән алып ташлый алмадым мин аны. Онытырга күпме генә тырышсам да, оныта алмагангадыр инде, гафу иттем. Ялгышлардан беребез дә хали түгел, гафу итә белергә дә кирәк, бигрәк тә яраткан кешеңне дип уйладым. Хатларына җавап яза башладым.

Көннәрдән бер көнне безнең Казандагы фатир подъезды төбенә «Волга» машинасы килеп туктады. Әни тәрәзә янында тора иде — күреп алган. Мине чакыра:

— Кызым, кил әле. Бик матур машинадан кара чәчле берәү чыгып килә. Чәчәкләр тоткан. Киеме дә бик килешле. Кем булыр бу, кемгә килә икән?

Мин, ашыга-ашыга, әни янына килеп бастым. Карасам, машина янында Хәйдәр тора. Зур бәйләм чәчәк, күчтәнәчләр тоткан. Ишекнең биген барып ачып куйдым. Әни белән икәүләп дулкынланып көтәбез. Бераздан ишектә кыңгырау. Тыныч булырга тырышып:

— Керегез, ишек бикле түгел, — дидем.

Ишектән шактый сулган, әмма чибәрлеге һаман да сакланган Хәйдәрем килеп керде. Чәчәкне миңа, күчтәнәчләрне әнигә тоттырды. Әни, миннән чәчәк бәйләмен алып, кухняга кереп китте. Ишек төбендә икәү генә басып калдык. Бер-беребездән күзләребезне ала алмыйбыз, әмма якынаеп китеп тә булмый. Сүзне Хәйдәр башлады.

— Кадерлем, бердәнберем, Галимәм! Кабул итеп алам, дисәң, сиңа кияүгә чыгарга риза, дисәң, кил кочагыма. Озак тилмерештек, каршы килмә, зинһар, — дип кочагын ачты.

Мин шул кочакка кереп сыендым. Йөрәкләрнең ярсып типкәнен ишетсәң иде син. Чабыштан кайткан атлармыни! Күзләребездә — яшь. Ниһаять, кавышулар насыйп булды. Ничә елдан соң!!!

Шул килүдән алып китте бу мине. Әни бәхет теләп калды. Яңа алган фатирына бергәләп кайттык. Яшьлек хатасын шулай төзәтеп, матур гына яши башладык.

Күрәчәкләр алда булган икән әле.

Теге хатын тынычланмады, билгеле. Икенче шәһәрдән Хәйдәрнең эш урынына килеп, аны хурлап, мыскыл итеп йөрде. Бала белән ташлап калдырды, ярдәм итми, дип җәлләтмәкче булган.

Бер-бер артлы ике улыбыз туды. Ике егет үстерәбез. Хәзер зурлар инде. Берсе институт тәмамлады, икенчесе төгәлләп килә. Бер-беребезне яратып яшибез, Аллага шөкер. Шулай куанышып, матур гына яшәп ятканда, узган ел башында кинәт бик нык чирләп киттем. Табибларның төрлесенә күрендем — чиремне билгели алмадылар. Нинди чир икәнен белмәгәч, дәвалый да алмадылар! Шулай гаҗиз булып, саргаеп йөргәндә, Гөлнур исемле бер шәфкать туташына тап булдым.

Ул минем йөземә, күзләремә карау белән:

— Апа, сине бозганнар бит, — диде. — Мондый чирне табиблар дәвалый алмый шул, — дип тә өстәде.

Мине үзе дәваларга алынды — нәселдән килгән сәләте бар икән. Дәвалана торгач, шул ачыкланды: минем бу чирем күптәннән килә икән. Яшь чагымда сәламәтлегем нык булу сәбәпле генә ул мине җиңә алмаган. Нәрсә булган, дип баш ватасың инде син, әйеме, дускай? Уеңа да китерә алмассың: бозык ашатканнар миңа даими рәвештә. Кунакта да, өемдә дә. Берьюлы бәреп чыкмагач, өстәп торганнар. Кем диген әле син: көн саен өемә килеп, гаиләсе белән миндә ашап-эчеп, кунак булып йөргән дус хатын. Хәйдәрнең беренче хатыны кушуы буенча, билгеле. Аның белән дә күптәнге ахирәтләр икән. Иремне миннән, мине аңардан биздерергә булган исәбе.

Барып чыкмагач, соңгы чарасын күргән: мине юлыннан бөтенләй алып ташларга ниятләгән. Ниләр эшләткәнен, нәрсә ашатканнарын сөйләп тормыйм, озакка китә. Тик шунысын гына әйтә алам: эчемдә җыелган бу шакшы үтергеч чиргә әйләнгән. Гөлнур дәвалый башлагач, тәнем тугыз урыннан тишелеп, эчемдәге теге зәхмәт тышка агып чыкты. Шуннан соң тәнем дә, җаным да чистарып калды. Алланың кодрәте, Гөлнурның ярдәме, Хәйдәрнең мәхәббәте белән хәлем көннән-көн яхшыра башлады. Кемнең кем икәнен аерыр өчен күзем ачылды. Дөньяда, беренче чиратта, янәшәңдә йөргән кешеләрдән курык икән. Дошманның сиңа теләсә кайсы вакытта этлек эшләргә әзер булуын һәрвакыт белеп торасың, ә менә эчеңә кереп, дус булып, өеңнән китми яткан сатлык җаннарның теләсә нинди кара явызлыкка, кара эшкә әзер торуын белеп булмый икән. Кызганыч, мин моны олыгая башлаган көнемдә генә

аңладым.

Аллага шөкер, шушы чиремнән арынгач, тиктомалдан борып ала торган ярсуларым да, югары кан басымым да юып ташлагандай юкка чыкты. Гел тынычланып калдым, Алла рәхмәте. Гаиләмә дә тынычлык иңде.

Күңелем чиста, гел яхшылыкта булгангадыр, бу нәҗеслек мине җиңә алмады. Саф мәхәббәтне куркытып кына, боздырып кына сүндерә алмыйсың. Андый юл белән яулап алып та булмый. Бары тинтәкләр генә белмидер: бу этлек — эшләгән кешенең үзенә кире кайта. Үзенә булмаса, балалары, оныкларына кайта. Кешене боздыру — Ходай каршында зур гөнаһ. Бәлки, шуңадыр да андый кеше барыбер бу дөньядан тыныч кына китә алмый. Иң әүвәл  шуны белсеннәр иде бозык ясатучылар. Ясаучылар да. Мәхәббәт бит ул — Аллаһ тарафыннан бирелгән изге хисләр. Аңа тыкшынырга беркемнең дә хакы юк. Нинди генә бозыклык эшләсәң дә, кешенең йөрәгендә, кальбендә булган изге мәхәббәт беркая да китми, үлгәнче ярата ул сөйгәнен. Әле үлгәч тә бары аның төшенә генә керә, дөньяда бары аның гына барлыгын таный, үз янына «тегендә дә» аны гына көтә. Бу — хакыйкать.

Ә теге кара йөзләрнең күрәселәре алда әле. Андыйларга җәзаны Ходай үзе бирә. Инде татый башладылар үз этлекләре җимешен. Шатланып түгел, борчылып әйтүем. Ни булса да, мин аны туктата алмыйм.

— Менә ике җүләр, — диде ул, тәрәзәгә карап, — таң атып килә икән бит. Керфек тә какмыйча Мәскәүгә килеп җитә язганбыз. Әйдә, булмаса, калган ике-өч сәгатьтә бераз гына булса да черем итеп алыйк. Югыйсә, вагоннан төшкәч, атлап китәрлек тә хәл булмас.

Мин, аның белән ризалашып, урыныма сузылып яттым. Тәннәр, аяклар оеган, берьюлы тулы бер тормыш язмасы салынган баш авырайган. Икебез дә башларны мендәргә төртүгә йокыга чумганбыз.

— Чай будете пить? — дигән тавышка уянып киттем.

Көн яктырган. Галимәнең урыны җыелган, үзе юынырга чыгып киткән иде. Мин тиз генә сикереп торып утырдым. Җыенырга кирәк. Әнә Мәскәүгә дә җитеп киләбез.

*1996*

# Ташландык

— Әтиегез кайткач, тормышыбыз кешечә булыр, өстебез бөтен, тамагыбыз тук булыр, иншалла, — дип өметләндерә ана берсеннән-берсе кечкенә ач-ялангач өч баласын.

Күп вакытта атналар буе бары су гына эчеп, бер бөртек ризык күрмәгән хәлсез балалар әтиләрен сугыштан зур ашкыну, олы ышанычлар белән көтеп алалар. Тик әтиләре, балаларын ачтан үтермим дип, көнен төнгә ялгап эшли-эшли авыруга әйләнгән хатынының, балаларының өметен акламый — сугыштан кайтып алар белән бераз яшәүгә, икенче хатынга китеп бара. Әниләре бу хәлдән соң бөтенләй авыруга сабыша. Балалар яңадан ач-ялангач кала. Әтиләре өчен әйтерсең лә аның эти дип өзелеп торган балалары юк — сабыйларына булышмый. Аның хәлле генә яшәүче туганы да була югыйсә. Тик аларның да ярдәм кулын сузганын хәтерләми Татьяна. Алай гына да түгел, көннәрнең берендә әнисе бик нык авырып китеп урынга егылгач, ашыйсы килүдән ни эшләргә белмәгән Татьяна, шул хәлле туганнарының бакчасына кереп, бер уч карлыган җыя. Авыру әнисенә, ашарга сорап елый-елый шешенеп беткән энесенә дә авыз иттермәкче була. Нәкъ әкияттәгечә килеп чыга: кире чыкканда, бакча капкасына таба борылуы була, әби дип якын итеп йөргән явыз карчык — этисенең олы апасы, эләктереп алып, карлыганнарын җиргә ташлата. Өстәвенә кычыткан белән яра. Җан ярасына тән ярасы да өстәлә. Татьяна берничә көн утыра алмый интегә. Шуннан соң сабыйның күңеленә тирән үпкә генә түгел, үч алу теләге дә кереп кала.

Көннәрдән бер көнне Татьяна әбисенең өйдән чыгып киткәнен сагалап кына тора да, бакчасына кереп, түтәлләрендә ни үссә, барысын да йолкып, җиргә ташлап калдыра. Хәер, карчык тавышланып, ачуланышып йөрми, бәлки, үз гаебен, баланы рәнҗетүен аңлаган булгандыр. Тик шактый вакыт узгач, бабасы гына: «Ник әбиеңнең түтәлләрен утап чыктың инде, ә?» — дип шелтә белдерә. Татьяна каршы сүз дәшми.

Ачлык кына түгел, ялангачлык та тилмертә аларны. Булганы тузып бетә, яңасын алып булмый. Аптырагач, әнисе үзенең иске киемнәрен ямап балаларына кидерә. Балалар шуңа да шатлана.

Шулай бервакыт этисенең туганнан туган энесе хатыны белән читтән кайтып төшә. Алар кайтканда, Татьяна  алда телгә алынган әби белән бабайларында була. Абый тиешле кеше бөтен бүләкләрен,

күчтәнәчләрен Татьяна алдында өстәлгә чыгарып сала. Бик матур өч төргәк тукыма да алып кайтканнар икән. Шуны алып куйганда, абыйсы хатынына:

— Өч кисәктән дә бу кызга күлмәклек кисеп бир, — ди.

Бала, бу сүзләрне ишеткәч, бик шатлана. Көне буе алардан китмичә, кайчан кисеп бирер икән дип көтә. Зарыгып бетә, әмма теләгенә ирешә алмый — җиңги кеше һаман кисми дә кисми. Кичен, күз яшьләрен тыя алмыйча, өйләренә кайтып китә. Өйгә кайтып кергәч, үкереп елап та җибәрә.

Әнисе, тынычландырып:

— Елама, кызым, бирмәсә бирмәс, үзебез берәр нәрсә әмәлләрбез әле, Алла боерса, — ди.

Иртәгесен иртүк зур өметләр баглап тагын китә Татьяна. Кичен тагын елап кайта. Карт белән карчык та борчылып калалар бу юлы. Үзләре кисеп бирерләр иде — кеше әйберсе. Киленгә турысын әйтергә кыймыйлар.

Көчкә төнне үткәреп, өченче тапкыр китә Татьяна. Бәлки, бүген кисеп бирерләр дип уйлый ул. Килсә, җиңгәсе каядыр чыгып ук киткән.

Бабай түзми, улына әйтеп куя:

— Бирерлек булмагач, бу баланы тилмертеп ник йөртәсез?

— Бәрәч, бирмәдемени әле? — ди аптырап абыйсы.

Шуннан тукымалардан күлмәклекне үзе кисеп бирмәкче була, тик аларны таба алмый. Хатыны келәткә бикләп киткән икән. Карт белән карчык, моңа җен ачулары чыгып, ачкычны эзләргә керешәләр. Ниһаять, табып алалар. Яшергән урыннан абыйсы өч төргәкне дә алып чыгып, һәрберсеннән берәр күлмәклек кисеп бирә.

Кош тоткандай очып кайтып керә Татьяна өйләренә. Шатлыгының очы-кырые булмый.

Җиңгиләре кайткач, бу эшне белеп алып дулый дулавын. Әби белән бабайга да шактый эләгә. Аның дулавы Татьянаның шатлыгын сүрелдерми, билгеле.

Әнисе тиз арада бу тукымалардан күлмәк, итәк, кофта тегеп бирә. Алар тузганчы Татьяна башка кызлар арасында патша кызы кебек горурланып йөри, куанычыннан башы күккә тигән була.

Әтиләренең хыянәтеннән әниләре дә, балалар да бер ара миңгерәп калалар — бу хәл башларына сыймый. Ничек инде сугышка кадәр әйбәт кенә яшәгән әтиләре икенче хатынга китеп барсын? Үз балаларын чит күрсен?!

Чит күрмәгән, онытмаган икән онытуын...

Татьяна әле бүген дә хәтерли: беркөнне энесенең велосипеды ватыла.

Энесе моңа әйтә:

— Бар, әтигә барып төзәттереп кайт әле, үземнең никтер барасым килми, — ди.

Китә Татьяна, велосипед күтәреп. Ул барып кергәндә, әтиләре ишегалдында нидер эшләп йөри торган була.

— Әти, энемнең велигы ватылды, төзәтеп бир әле, — ди бу әтисенә.

Әтисе аңа беравык сүзсез генә карап тора да, кинәт чабып барып кысып кочаклый һәм елап җибәрә. Аннары, чәченнән сыйпый-сыйпый:

— Бар кайт, кызым, бүген-иртәгә үзем сезгә кайтам, бөтенләйгә. Кайткач, барын да ясап бирермен, — ди.

Татьяна шатлыгыннан өйләренә ничек кайтып җиткәнен дә сизми кала! Капкадан керә-керешкә:

— Әти кайта, иртәгә бөтенләйгә кайта, безнең белән торырга кайта! — дип кычкырып җибәрә.

Әтиләре кайта кайтуын, тик аларның бәхетләре озакка бармый — берничә айдан ул дөнья куя. Гомеренең ахыры җиткәнен сизенеп, хатыны, балалары янында үләсе килгәндер мәрхүмнең.

Теге хатын йөкле булып кала. Бераздан ул да малай таба. Ул хатынга нарасыен үзенә үстерергә насыйп булмый — баласын калдырып үлеп китә. Бу баланы балалар йортына илтеп тапшыралар. Шулай итеп, дүрт яшь бала әтисез ятим кала. Балаларның интегүе әле болар белән генә бетми.

Татьянага — унбиш, энеләренә унике тулгач, әниләре дә вафат була. Бер энеләрен һөнәр училищесына укырга урнаштыралар. Ә Татьяна, әнисе үлгәнче үк, әтиләре вафат булу белән, бала караучы булып эшли башлый. Монда аны ашаталар, эчертәләр. Әниләре үлгәч, кечкенә энеләрен әтисенең бер туганы алып китә. Ул анда әйбәтрәк тормышта яшәп, белем алу бәхетенә ирешә.

Уналты яшендә Татьяна «Спартак» берләшмәсенә эшкә урнаша. Кыз, авыр тормыштан котылу өчен, кияүгә чыгу турында уйлана башлый. Өстәвенә туганнан туган абыйсы аны үзенең дусты белән дә таныштырып өлгерә. Ошата Татьяна егетне. Озын-озак уйлап тормыйча, өйләнешәләр. Тик Татьянаны монда да бәхет дигән нәрсә кочагын җәеп каршы алмый. Озак та үтми, иренең элек йөргән кызы булуы беленә. Егетнең әнисе бу кызга өйләнергә рөхсәт итми, араларын үзе боза. Ә Татьянаны ошата, алар өйләнешсеннәр өчен бөтен тырышлыгын куя. Тик улының йөрәгеннән теге кызга булган мәхәббәтен генә алып ташлый алмый. Егет, сөйгәнен оныта алмыйча, бәргәләнә, өзгәләнә. Ул кыз да, бәлки,

онытылыр, дип йөргән егетенең дустына кияүгә чыга. Аның ире, боларның элек йөргәнен белгәнгә, һаман да очрашасыздыр, дип, хатынының теңкәсенә тиеп кыйный башлый. Ахыр чиктә, монда болай яшәп булмас дип, читкә чыгып китәләр. Аларның читкә киткәнен белгәч, Татьянаның ире үзенә урын таба алмый, эчә, гаиләсендә тавыш чыгара башлый. Хатынының балага узуы да аны тынычландырмый, ул, киресенчә, усаллана, явызлана гына төшә. Бала тумасын дип, эченә тибә-тибә кыйный.

Шул чакларда Татьяна:

— Тимә туасы балага, тусын. Үзем өчен табам мин аны, сиңа йөк булмас, үзем үстерәм, — дип ялвара.

Туасы бала дөньяга килсә дә, бәхете белән килми. Бала булгач, бәлки, үзгәрер дигән кечкенә генә өмете дә акланмый ананың. Ире теге хатын янына читкә китәм дип йөри башлый. Аңа да риза була Татьяна. Бәлки, ул киткәч, тынычлап яшәрбез дип уйлый. Тынычланырга язмаган икән: ире никтер китми кала.

Улына биш яшь дигәндә, теге хатын, иреннән аерылып, үзе Казанга кайтып төшә.

Көннәрдән бер көнне Татьянаның улы, урамнан йөгереп кереп:

— Әни, нинди апа ул? Һаман мине кочаклый да елый, кочаклый да елый. Ник минем улым түгел икән син, ди. Кем ул, әни, ә? — дип сорый.

Татьяна аның кем икәнен шундук аңлап ала, билгеле. Әмма улына серне ачмый.

— Сине бик ошаткандыр, улым. Син бик тәртипле малай бит. Бәлки, үзенең улы юктыр, — ди.

Теге хатын кайту белән, болар өенә яңа борчу өстәлә. Татьянаның ире инде көнләп кенә түгел, атналар буе югалып тора башлый. Тора-бара бер атна өйдә булса, бер ай бөтенләй күренми.

Ул хатын үзен барыбер бәхетле итеп тоймагандыр, күрәсең, мондый тормышка түзә алмыйча асылынып үлә.

— Чибәр, акыллы хатын иде. Әрәм булды. Мин бит аларның мәхәббәтләре, бер-берләре өчен үлеп торулары турында белмичә кияүгә чыктым. Белгәч, үземне гаепле санадым. Араларына мин кердем булды бит инде. Минем аркада бәхетсез булдылар дип уйладым. Шуңа күрә, ни генә эшләсә дә, иремнән көнләшеп теңкәсенә тимәдем. Теге хатын үлгәч, ирем кара кайгыга батты. Сөйләшми, безне бөтенләй күрми: без әллә дөньяда бар, әллә юк. Шулай йөри торгач, үзе кебек эчәргә яратучы бер хатын белән танышып, аның янына китеп-китеп яши башлады, — диде Татьяна, ул көннәрен искә төшереп.

Тик анда да рәхәт тормыш, тынычлык тапмый ул. Көннәрнең берендә исерек килеш суга батып үлә.

Татьянаның газаплары әле моның белән генә дә бетми. Үзен йөрәк авыруы интектерсә, улына каенатасыннан туберкулез иярә. Ярый әле өч авыруга ике бүлмәле фатир алып калалар. Югыйсә кешечә торыр почмаклары да булмас иде.

Каената яңа фатирга күчкәч, озак яши алмый, гомер буе интеккән авыруыннан үлеп китә.

Улын ел саен шифаханәләргә йөртә-йөртә аякка бастыра Татьяна, чиреннән дәвалый. Матур егет булып үсеп буйга җитә. Армиядән кайткач, өйләнеп тә җибәрә.

Инде Татьянага тыныч кына яшәргә вакыт җитте дип торганда, тагын хәсрәт — менә дигән улын, Татьянаның оныгын ятим итеп, ире өстеннән йөргән килене бөтенләй китеп бара. Йөргән кешесе алмагач, әнисенең бер бүлмәле фатирына кайта.

Язмыш шулай кабатлана, күрәсең. Иң әүвәл ятимлекнең бөтен ачысын үзе татый Татьяна. Аннары улы ятим үсә, инде оныгы үксез. Бәлки, ул бәхетле булыр дип тә әйтеп булмый. Чөнки бүгенге көндә ун яшьлек үсмер мәктәптән соң көннәр буе берүзе. Кая тели — шунда йөри, ни тели — шуны эшли. Әнисе дә, әнисе ягыннан әбисе дә аны күздән ычкындырдылар. Әтисе янына, дәү әнисе янына инде сирәк килә. Чөнки тегендә — ирек, дуслар, иптәшләр. Ни булып бетәсен Алла үзе генә белә.

— Гомерем буе үзем ташландык булдым. Бу «чир» нигәдер улыма да, оныгыма да күчте. Кайчан да булса безнең дә бәхетле яшәр көннәребез булыр микән? Безнең дә аңа хакыбыз бар лабаса? — ди Татьяна, өзгәләнеп.

*1995*

## Сагынуларым биниһая:
## Җирдән күкләргә ашкан!

Беркөнне эштән кайтып барганда, көтмәгәндә-уйламаганда, моннан егерме еллар элек

университетта бергә укып йөргән ахирәтем Санияне очраттым. Күрдем һәм таң калдым: шушы еллар эчендә бер дә үзгәрмәгән дип әйтү генә аз булыр, ул тагын да матураеп, яшәреп, нәфисләнеп киткән. Мин моның серенә төшенмәкче булып сораштыра башладым, әлбәттә.

Сания серле генә елмаеп куйды да, минем белән очрашуына куанганын белдереп:

— Серне шунда ачарбыз, — дип, үзенә кунакка чакырды. — Тагын кайчан очрашабыз әле. Менә хәзер утырып сөйләшмәсәк, серләшмәсәк, тагын аерылып китәбез дә янә бер-беребезне күрә алмыйча йөрибез инде. Әйдә иренмә, ерак тормыйм мин, — диде.

Минем икеләнеп торуымны күреп, тиз-тиз үз ягына аудармакчы булды:

— Әйдә инде. Тормышымны, балаларымны күрерсең. Казанда яшәвеңне, әле бездән ерак түгел генә эшләвеңне дә белгән булсам, әллә кайчан эзләп тапкан булыр идем үзеңне, — диде.

Әйе, кайчандыр без бик дуслар идек. Студент чакның бөтен мәшәкатьле, бәхетле һәм газаплы еллары бергә узылган. Серләребез дә уртак иде. Сөйләшәсе сүзләр күп, билгеле. Аны очратуыма мин дә бик шатландым һәм, тәвәккәлләп, шулай да озак тормаска дип, Саниягә ияреп кунакка киттем.

Саниянең фатиры, чынлап та алай ерак булмыйча, шәһәр уртасында иде. Гаҗәп, икебез дә ничә еллар буе бер юлда йөреп, моңарчы ничек очрашмаганбыздыр.

Килеп керүгә, фатирының шактый зурлыгына, зәвык белән җиһазланган булуына игътибар иттем. Ишек төбеннән үк бар җирдә чисталык, пөхтәлек күренеп тора. Бер генә артык әйбер дә юк: бар да үз урынында, бар да тәртиптә.

— Уз әйдә, Фәния, уз! Менә шушы башмакларны киярсең, аякларың бераз ял итсен, көне буе йөрисең бит биек үкчәдә. Арыйдыр аякларың, — дип, бик матур башмаклар тоттырды да тизрәк кухняга кереп китте. — Чәйне куеп җибәрим әле, кайный торсын, — диде.

Мин залга уздым. Йомшак диванга барып утырдым. Чынлап та арылган. Рәхәт булып китте.

Сания залга бер кочак альбомнар күтәреп керде.

— Бөтен гаиләм, бөтен тормышым шунда минем. Кая барсак та фотога төшәбез. Шушы фотоларга карап, безнең тормыш юлы турында китап язарга була, — дип көлеп җибәрде. — Балаларым, ирем белән дә таныштырырмын, фотодан гына инде. Өйдә үзем генә бүген.

Сания, балалары, ире белән горурланып, фотоларын күрсәтеп чыкты. Ә ире студент елларында бергә йөргән егет икән бит. Сания янына бик еш килә иде ул. Кайчакларда бергәләп йә киногa, йә концертка барып кайта торган идек. Эше командировка белән бәйле булып, бүген дә шунда икән. Иркенләп утырырга, иркенләп серләшергә мөмкинлек булганга да өзелеп чакыргандыр инде мине Сания. Янәшәңдә кеше булганда, барыбер әллә ни ачылып китеп булмый бит.

Ул арада чәй дә кайнап чыкты. Без, шактый зур кухняга кереп, сый тулы өстәл янына утырдык. Ахирәтем, чәй ясый-ясый, мут елмаеп:

— Менә, минем яшь торуымның, һаман чибәрләнә баруымның серен беләсең килгән иде. Әйтсәм әйтим инде: беренчедән, әйбәт ирнең хатыны картаймый. Икенчедән, аның сере — мәхәббәттә! Ирем белән бик тату, бик яратышып яшибез. Эше генә командировка белән бәйле. Бәлки, шуңадыр да, ул чыгып киттеме — өзелепләр бер-беребезне сагынабыз, кайтып кердеме — сөешеп туймыйбыз. Бөтен гомеребез менә шулай үтә. Сиңа, бәлки, көлке дә тоелыр: ул озаккарак киткән чакта, сагынуга түзә алмый, хатлар язышабыз әле. Менә бүген дә хатымны яздым да, конверт алып керим дип, киоскка чыккан идем. Бәхетемә, шатлыгыма диимме, син очрадың. Чәйләп бетергәч, күрсәтермен әле сиңа ул хатны. Кызыксынсаң, укып чыгарсың. Яле, җитеш әле барына да, коры чәй эчеп утырма инде. Нәрсә инде кыстатып торасың? Чит кешедә түгелсең лә, — диде.

Сания өстәлдәге ризыкларны минем алга китереп тезә башлады.

— Буең җитми мәллә? Әйдә, ашап-эч инде, — дип кыставыннан туктамады. — Син бит эштән соң.

— Сания, кыстама, эштән соң булсам да, әллә ни ашыйсым килми. Чәй генә эчәм. Мин синең тормышыңның шулай матур, түгәрәк булуына чын күңелемнән шатмын, Сания. Алга таба да шулай яшәргә язсын! Күз генә тидермәсеннәр! Шуңа күрә булган нәрсәне саклап тотарга кирәк. Кайбер чакта кеше күзеннән дә. Чәең өчен рәхмәт. Инде бездә эчәргә язсын чәйне, — дидем дә өстәл яныннан тордым.

— Әйдә, алайса, залга чыгыйк. Сиңа хатны күрсәтим әле, — диде Сания.

Залга чыккач, шкафтан хатын алды да миңа сузды.

— Мә, укып чык. Рөхсәт итәм. Син иҗат кешесе бит. Бәлки, кирәге чыгар...

Мин хатны кулыма алдым. Шактый калын хат. «Исәнме, ничек яшисең, сау бул!» дип кенә язылган хат түгел инде бу. Башта икеләнеп торсам да, журналист, язучы буларак та, хатын-кыз буларак та кызыксынуым үзенекен итте: хатны алып укый башладым.

*«...Бүген тагын төшемә кердең, җанкисәгем. Синең белән әллә ничә бүлмәле икенче бер йортта*

*яшибез икән, дим. Син кайдандыр кайтып кына кергәнсең. Буш кул белән кайткансың икән (гомердә булмаганны). Мин, сине көттереп, икенче бүлмәдә нидер эшлим, чыкмыйм, имеш. Үпкәләгәнмен. Озак йөргәнеңәдер инде. Ишетәм, син яңадан киенә башладың. Буш кул белән кайтуыңа яхшысынмыйча, кибеткә чыгып, ни дә булса алып керергә икән исәбең, дим. Күңелем белән шулай дип тоям. Эшемне ташлап синең янга чыгып җитә алмадым, ишекнең ябылган тавышы гына ишетелеп калды. Шул ишек тавышы шундый куркытты мине: кинәт, барысын да ташлап, исемеңне сузып кычкыра-кычкыра, сине кире алып керергә теләп, йөгерә-йөгерә коридорга чыктым — син юк, урамга чыктым — син юк. Үзәкләрем өзелде — үксеп елап җибәрдем. Күңелем белән синең әйләнеп кайтасыңны да сизәм, кибеткә генә барып киләсеңне дә тоям югыйсә. Шуңа да карамастан синсез үткән көннәр газабыннандыр инде һәм кабат синсез калудан куркыптыр, йөрәгем жу итте. Уянып киттем. Ходаем, төшемдә исемеңне шулкадәр дә каты итеп кычкырдым, балалар ишетмәде микән дип, куркуга калдым хәтта. Әллә әни җүләрләнәме дип уйлаулары бар. Әмма аны-моны сиздерүче булмады. Борчылып ята торгач, тагын йокыга киткәнмен. Янә сине күрәм. Син янә минем янда. Әйләнеп кайткансың икән. Кайтуыңа шатланып, әй иркәлим үзеңне, әй назлыйм. Синең күңелләр күтәренке, җаның тыныч. Мине сөеп туймыйсың, имеш. Нәкъ өндәгечә.*

*Йа Хода, бер-береңне сөеп яшәүдән дә рәхәтрәк, ләззәтлерәк нәрсә бармы икән дөньяда?! Яраткан, җаныңның бер кисәге булган кешеңнең сөеп каравы гына да күңелләрне җиде кат күккә күтәрә. Назлы кулларының кагылып кына китүе дә җаныңны эретә. Шундук хискә бирелеп китеп сөеклеңнең муенына барып сарыласың, янып торган күзләреннән, кайнар иреннәреннән шаша-шаша үбәсең, бармакларың ирексездән чәч араларына кереп югала. Синең шулай яратуыңа җанын бирергә әзер сөйгәнеңнең көчле куллары җилтерәтеп күтәреп ала да бүлмә буйлап әйләндереп йөри башлый. Татлы итеп үбә, назлы сүзләргә күмә. Башны авырайта башлаган бу яратышудан айнып өчен, икәү кочаклашкан килеш ләззәт диңгезенә чумасың...*

*Кабат уянганда сәгать сигез тулып килә иде инде. Ярый әле ял көне, эшкә чыгып чабасы юк. Төштәге халәт шундый нык тәэсир иткән ки, инде уянгач та шактый вакыт айный алмый яттым. Җаным да, тәнем дә синең озаклап китеп йөрүеңне күтәрә алмый, бердәнберем минем. Сагынам, өзелеп сагынам. Сыкрый-сыкрый сагынам! Нәкъ җырдагыча:*

Сагынуларым биниһая:
Җирдән күкләргә ашкан!
Тизрәк кайтсаңчы!..»

Хатны укып чыккач, мин хәйранга калдым. Ничә дистә ел бергә яшәп, инде шактый яшькә җитеп тә, мәхәббәтләре сүнмәгән-сүрелмәгән, бер-берләрен кадерләп, назлап кына яши торган парлар да була икән дөньяда. Ахирәтемнең бәхетле тормышы шатландырды да, куркытты да мине. Берүк күз генә тия күрмәсен! Болай да картайганчы шулай матур яшәүчеләр саны елдан-ел кими бара. Ни сәбәпледер мәхәббәт, сөю дигән якты хисләр күпләрдә бик тиз сүрелә. Хәтта өйләнешеп яши башлау белән үк бер-берсеннән суынучылар байтак. Югыйсә үлеп яратышалар иде кебек. Кая китә ул өйләнешкәнче күкләргә чөйгән мәхәббәт, наз? Кайдан барлыкка килә ул салкын караш, битарафлык, ахыр килеп, бер-береңне күралмау? Дөньяда Санияләр кебек тә яшәп була икән ләбаса.

Мин ахирәтемнең тормышына, сүрелмәс мәхәббәтенә сокланып, кунак итүенә рәхмәт әйтеп, изге теләкләр теләп, саубуллашып, инде үзен кунакка чакырып чыгып киттем. Юл буе бер генә сорау борчыды мине: бу ике көнлек тормышта нигә без кешечә яши белмибез?

*1993*

## Килеп тезләнәселәре алда әле

Гөлия мәктәпкә килеп керүгә, аны ишек төбендә дус кызлары каршы алды.

— Син беләсеңме әле, безнең сыйныфка Фәнис дигән малай килә икән. Әтиләре белән шәһәрдән авылга торырга кайтканнар, — дип чыркылдадылар сыйныфташлары, берсен-берсе бүлә-бүлә.

Шул ук көнне алар укыган дүртенче сыйныфка матур гына бер малай килеп утырды. Гөлиянең генә түгел, сыйныфтагы башка балаларның да игътибарын үзенә җәлеп итте ул: кызлар сокланып караса, малайлар бераз көнләшеп тә куйдылар.

Үсә төшкәч, Фәнис белән Гөлиянең мөнәсәбәтләре ничектер үзеннән-үзе үзгәрде: бер-беренә карата игътибарлы, күзәтүчән, сабыррак булып киттеләр. Әй сигездә укыганда инде Фәнис Гөлияне өенә

кадәр озатып куйгалый башлады. Шулай итеп, ике арада дуслык һәм мәхәббәт җепләре сузылды.

Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, Гөлия укырга дип Казанга китте. Тик конкурстан үтә алмады. Кире авылга кайтырга оялды. Киез итек фабрикасына эшкә урнашты. Атна саен авылга кайтып йөрде. Ә Фәнис тракторчы булырга укыды, аннан армиягә китте. Гөлия, көтеп алырга исәбе булмаса да, Фәнисне армиягә озатып калды. Көтәргә исәбе булмавының сәбәбе — егет артык чибәр иде. Югыйсә Гөлия үзе дә матур кыз, моңлы итеп җырлый. Шулай да ул үзен аңа тиңсенмәде. Тормышыбыз ялганмас, аннан бер хатын да калмас, дип уйлады ул. Һәм ялгышмады...

Әле армиягә киткәнче үк кызлар аңа сарылып, үзләрен тәкъдим итеп йөрделәр. Бер караганда, кызык та инде: теге кызлар һушларын югалтып аның артыннан чаба, ә ул, аларның берсенә дә карамыйча, Гөлияне генә яратып йөри. Көнләшүчеләр, араларын бозарга теләүчеләр күп булды ул чакта...

Фәнис армиядә вакытта, Гөлия акыллы гына бер баянчы егет белән танышып, матур гына йөреп китәләр. Концертларда гел бергә катнашалар: Гөлия җырлый, ул өздереп баянда уйный. Инде өйләнешәбез дип торганда гына, армиядән Фәнис кайтып төшә. Гөлиянең кияүгә чыгарга йөрүен ишеткәч, башка кешегә бирмим мин аны дип, кайтуының унынчы көнендә үк, аны урлап, туганнарына алып кайтып куя (ул якларда кыз урлау гадәте әле һаман да бетмәгән була).

1979 елның үтә дә салкын 1 гыйнвар төне. Гөлиянең әнисе, кызы вакытында клубтан кайтмагач, хафаланып эзли чыга. Төне буе эзли, аяк тавышлары ишетелмәс микән дип, карга ятып тыңлап та карый (салкын төндә кар шыгырдавы еракларга ишетелә). Гөлия юк та юк.

Ул вакытта инде аны бер бүлмәгә бикләп куйган булалар. Өс киемнәрен дә салмыйча, таңга кадәр йөреп чыга Гөлия.

— Җибәрегез, юкса судка бирәм, — дип янап та карый.

Әмма аны тыңлаучы да булмый. Таң белән егетнең әнисе кыз ябылган бүлмәгә килеп керә. Гөлияне үгетләргә керешә.

— Кал инде, Гөлия! Кеше көлдермик, зинһар. Яратышкан идегез бит. Чит түгел бит ул сиңа, — дип ялвара.

— Юк, апа, калмыйм. Кала алмыйм мин. Беренчедән, мин аңа ышанмыйм. Тормышымны аңа ышанып тапшыра алмыйм. Икенчедән, егетем бар минем. Кайтарып җибәр мине, апа, барыбер ризалыгым юк, — дип елый Гөлия.

— Апа дип әйтмә инде, Гөлия. Әни дип әйт. Ярата бит ул сине. Яратмаса мондый адымга барыр идемени? Ризалаш инде, зинһар өчен. Мин дә бит сине якын итәм. Әйдә, өйгә кайтыйк, — ди булачак каенана.

Фәниснең әтисе дә кереп үгетли.

— Кызым, без бит төшеп калганнардан түгел. Нигә безгә килен булып төшәсең килми? Армиягә киткәнче Фәнисне ярата идең бит. Бөтенләй сүрелмәгән булсаң, кал, зинһар! Кеше арасында яманат таратмыйк. Сиңа да кызык булмас, әгәр берәр кирәкмәгән сүз сөйләп йөри башласалар. Әйдә, өйгә кайтыйк, — ди ул да.

Ахыр чиктә риза була Гөлия. Егетнең өенә бергәләп кайтып китәләр.

Икенче көнне үк никах укыталар. Кызның әти-әнисен дә алып киләләр. Аннары яшьләр Казанга китеп бара. Шулай итеп, яңа тормыш башлана.

Дөрес, баштарак бик яратышып, матур гына яшиләр. Бөтен җиргә бергә йөриләр. Хәтта кибеткә ярты ипигә барасы булса да хатынынннан башка чыкмый Фәнис. Һәрчак күрше апалар артларыннан «итәк белән җитәк» дип калалар. Кызлары дөньяга килгәч, тормышларына тагын да ямь өстәлә.

Дүрт еллап шулай матур гомер иткәннән соң, Фәниснең кыңгыр эшләре беленә башлый. Күпме генә яшерергә тырышсаң да, без капчыкта ятмый шул. Малай алып кайтып бирсәң иде син, дигәч, күңеле булсын дип, икенче баласын табарга уйлый Гөлия. Тик аңа карап иреннән элекке назларны, яратуны көтеп ала алмый. Рәнҗетелүдән, кимсетелүдән күңеле ката Гөлиянең. Бала тудыру йортына кергәндә, шуннан кайтмасам ярар иде, дип эченнән генә тели. Гомер бетмәгән булгач, алай тиз генә үлеп китеп булмый икән шул. Сабыйлары хакына Аллаһы Тәгалә Гөлиягә яшәү дәрте өстәп җибәрә.

Тупырдап торган улын күргәч, ата кешенең дә күңеле нечкәрә. Шактый вакыт шатланып, кәефләнеп йөри, гел бала тирәсендә кайнаша, сөя, уйный. Әмма гаиләсеннән бер суынган ирне берничек тә бәйләп куеп булмый икән. Ике бала белән дә, биш бала белән дә. Фәнис яңадан читкә йөри башлый. Соң кайта яки бөтенләй кайтмый кала. Гөлия өчен яңадан газаплы көннәр башлана. Көтеп-көтеп тә ирең кайтмагач, борчылып үткәргән төннәрнең авырлыгын әйтеп кенә бетереп буламыни?! Тора-бара атналап күренми Фәнис. Өйләнешүләренә алты ел дигәндә, ике яшь баланы ятим итеп, аерылышырга судка бирә. Нәкъ суд буласы көнне кечкенә сабый, температурасы кырыкка җитеп, кинәт авырып китә. Саташып яткан баланы күрше әбигә калдырып, елый-елый судка барырга мәҗбүр була Гөлия. Аерылышып кайтканда да күз яшьләре бите буйлап тәгәри. Бала янына килгән

табиб ярты көн буе аның үзен тынычландырып утырырга мәҗбүр була. Бичара бала! Әтисенең үзләрен бөтенләй ташларга җыенуын сизеп, бу авырлыкны күтәрә алмый авырып киткән диярсең.

Бәхеткә, бала тиз сәламәтләнә. Гөлиянең йөрәгендә генә тирән яра уелып кала.

Берьюлы ике хатын (үз хатынынннан башка) артыннан чапкан Фәнис башта берсе белән торып карый. Фатирлары юк, кайда буш урын табалар, шунда яшиләр. Тик «бәхетләре» озакка бармый. Ике еллап яшәгәч, Фәнисне ниндидер гаебе аркасында кулга алалар. Хөкем карары катгый — унбер ел. Шуның алтысын утыргач чыгаралар. Фәнис, башын иеп, Гөлиягә килә.

Хатын-кыз нишләсен, балаларының атасы дип җәлләп, Гөлия ирен кабул итә, куып чыгармый. Бәлки, яшәп китәрбез дигән өмет чаткысы да күңелендә кабынып китә. Күпме абынып-сөртенеп яшәргә була? Тик, бер киселгән икмәк кире ябышмый, дип, бик дөрес әйтәләр икән — биш кенә ай торып калалар. Фәнис яңадан икенче бер хатынга китеп бара. Анысы да туйдыргач, өченчесенә, дүртенчесенә, бишенчесенә китә...

Кырык яшенә җиткән ирнең, аяк терәп, бу минеке дип әйтерлек ни торыр урыны, ни гаиләсе булмасын әле! Шуңа күрә аны юксыну, аннан көнләшү хисе калмый Гөлиядә. Бары тик гомере заяга узган, киләчәге булмаган ир буларак аны кызганырга гына кала.

Дөрес, балалар янына килгәли. Кайчакларда акча да калдырып китә. Үзе алар белән бергә дә тормый, килмичә дә булдыра алмый. Кайчакларда сагына да, ә вакыты-вакыты белән бөтенләй битараф.

Әмма Фәниснең Гөлия алдына килеп тезләнәселәре алда әле. Картаеп егәре беткәндә, аның вакытлыча гына торып алган бер генә хатынга да кирәге булмаячак. Аның киләчәге ышанычлы түгел. Хәтта көнлекче хатыннарга да олыгайган көндә мондый ир кирәк түгел. Туны тузгач, Гөлия дә, балалары да аны кочак җәеп көтеп тормаячак. Әти дип кечкенәдән яратып үсмәгән балалар инде хәзер аның өчен үлеп тормыйлар. Өстәвенә әниләрен авыруга сабыштыруын да бик яхшы күреп торалар. Алиментка бирмичә, берүзе нинди авырлык белән ике баланы аякка бастырганын да беләләр. Аллага шөкер, тәртипле булып үсеп киләләр, инде шактый зурлар. Әниләре авырып киткәндә, айлар буе тормышны үзләре алып баралар.

— Иремне әти-әнисе үз вакытында ныграк тотмады, ни эшләсә дә, үзләре ирек бирделәр. Бәлки, игә дә кергән булыр иде, каты тоткан булсалар, — диде Гөлия ханым, уфтанып. — Гомерем үтте, балаларымның әтисез үсүләренә хәсрәтләнеп. Әтиләре белән чыгып киткән башка балаларны тәрәзәдән карап калганда, үзәкләрем өзелеп куя торган иде: минекеләргә шулай йөрергә насыйп булмады. Малай кешегә әти бигрәк тә кирәк бит. Әти сүзе, әти җилкәсе, әти яклавы кирәк. Әтиләре булмау аркасында күпме рәнҗү, кимсенү, газап кичерделәр алар. Берсендә улымны, син әтисез, дип әйтеп елатып керткәннәр иде. Балакай үзе бирешми тагын: аларның әтиләре алкаш, андый әти булганчы булмавы яхшы, әйе бит, әнием, дип, үзен дә, мине дә юаткан була.

Кызым беренче сыйныфка укырга кергәндә дә күңелсез хәл килеп чыккан иде. Укытучы апасы кызымнан, әтиең кайда эшли, дип сорагач, тегесе кычкырып торып елап җибәргән. Соңыннан гына, әтием юк минем, дип әйтә алган. Менә шулай интектеләр инде бәгырьләрем. Әле дә ярый, Аллага шөкер, балаларым бик акыллы, бик ярдәмчел — күз генә тимәсен. Әллә ниләр сорап җаныма тимиләр. Хәлне аңлыйлар, рәхмәт төшкерләре. Тора-бара гына үзгәрмәсәләр инде, — дип сүзен бетерде Гөлия ханым.

*1994*

## Булачак кәләшемне төштә күрдем

— Яшь чакта йөрелә инде, сеңлем, үз тиңеңне эзләп тапканчы йөрисең инде ул кызлар артыннан, — дип кеткелдәп куйды Исмәгыйль абзый. — Матур кызлар күп бит, кайсын сайлап алырга белмисең башта. Кызлар күбен күп, ә өйләнергә теләгәнең юк та юк. Күп егетләрнең өйләнәм дигән кызлары кинәт кенә килеп чыга торгандыр инде, минеке кебек.

Исмәгыйль абзый, чал кергән сакал-мыегын сыпырып, янә кеткелдәп куйды. Мәхәббәт турында сөйләшү, бигрәк тә яшь чакларын искә төшерү, нинди яшьтә булса да, бер генә кешене дә битараф калдырмый, күрәсең. Сиксәнгә якынлашып килүче Исмәгыйль абзыйның да күзләре очкынланып, йөзләре алсуланып китте.

— Мин үзем, мәсәлән, өйләнәсе кызымны иң әүвәл төшемдә күрдем. Ничек итеп дисеңме? Имеш, мин инде өйләнгән, хатыным бала табып ята икән, дип. Япь-яшь егет чак бит әле. Башында — бик матур итеп бәйләгән ап-ак яулык. Йөзен күрмим әле. Минем аңа төбәп карап торуымны сизеп, ахры, ул, башын күтәреп, миңа борылып карады. Түм-түгәрәк, бит очлары алсуланып торган ак йөз. Елмаеп

баш какты да янә үз газапларына чумды. Әнием дә аңа ярдәм итеп йөри, имеш. Бала тугандырмы, юктырмы, анысын күрә алмадым — уянып киттем. Уйланып ятам инде хәзер: йөргән кызларымның кайсына охшаган — берсенә дә охшамаган. Әһә, мәйтәм, яңа кыз белән танышам икән, шул кыз миңа хатын була икән, дим. Инде күңелгә корт төште: кая барсам да, төштә күргән кызга охшаш йөзне эзлим.

Исмәгыйль абзый, хәйләкәр елмаеп, бераз уйга калды. Фикерләрен тәртипкә салды булса кирәк.

— Шактый вакыт йөрдем шулай. Таба алмавыма ачуым килә башлады.

Көннәрдән бер көнне күрше кызлары аулак өй ясарга ниятләгәннәр. Моны белеп алган дус егет Фәрит безгә килеп керде дә:

— Исмәгыйль, бүген кич сезнең күрше Гөлҗамалларда аулак өй була. Кунак кызлары да бар икән. Керәбезме? — ди.

Кунак кызы дигән сүзне ишеткәч, мин сикереп тордым.

— Карале, Фәрит, кунак кызлары нindirәк? Матурлары бармы? Түгәрәк ак йөзлесе бармы? — дим, тәкатем бетеп.

— Син нәрсә, Исмәгыйль, — ди бу миңа. — Мин кайдан белим инде, кызларны күрмәдем бит әле. Менә кергәч күрербез, — диде ул миңа, сәерсенеп карап.

Кич җиткәч, егетләр белән җыелыштык та киттек аулак өйгә. Башта кертми маташкан булдылар. «Алайса, без киттек!» — дип куркыткач кына ишекнең келәсе ачылды.

Өйгә килеп кергәч шаккаттым: минем сеңел янында төшемә хатыным булып кергән кыз утыра. Башына, нәкъ төштәгечә, матур итеп ак яулык япкан. Алсуланып торган түм-түгәрәк ак йөз. Күрше авылдан килгән кунак кызы булып чыкты. Исеме Мөршидә икән. Шул. Күрү белән — минеке, дидем. Егетләргә шундук әйтеп куйдым: Мөршидә минеке, берегез дә якын киләсе булмагыз. Юкса борынсыз йә тешләрсез калырсыз, дидем. Шуннан Мөршидәне биюгә чакырып, танышып киттек. Матур гына йөреп өйләнештек. Инде менә кырык елга якын гомеребезне бергә уздык. Ике бала үстердек. Хәзер оныкларыбызны үстерешәбез. Аларга карап шатланып туймыйбыз, гомеребезне озайтабыз, — дип, гаҗәеп матур итеп елмаеп, карчыгы Мөршидә әбигә карап куйды.

Мөршидә әби, тәрбияле татар хатыннарыннан да тәрбиялерәк булып, карты сүз сөйләгәндә каршы төшеп яки җөпләп бер генә сүз дә әйтмәде. Бары тик түм-түгәрәк матур йөзендә нindidер серле балкыш кына уйный иде.

Кинәт Исмәгыйль абзыйның йөзе караңгыланып китте. Ни булды икән дип уйларга да өлгермәдем, үзе сүз башлады:

— Менә хәзерге яшьләргә карыйм да һич аңлый алмыйм. Күп чакта ачуым кайный: эчәләр, тарталар, шул хәлләрендә бала табалар. Балаларын бишектән үк үзләре йөргән төрле җирләргә йөртәләр. Тәрбия күрмәгән, ач балалар. Елый башласа, дөмбәсләп аталар. Бервакыт урамнан барам — бер исерек хатын кулындагы яшь баласын, елый башлагач, кышкы суыкта карга атып бәрде. Ярый әле бала кар өеменә туры килде, асфальтка төшсә нишли иде? Янәшәсендә барган бераз айныграк ире баланы алды да мыгырдана-мыгырдана хатыны артыннан китте. Йә, бу баланы нинди тормыш көтә инде?! Ул сабыйлар ни күреп үсә? Үскәч кем була? Шуларны жәлләп, йөрәгемә кан сава. Киләчәгебез кемнәр кулына кала? Шуларны уйлыйм да иманеп китәм. Инде бүген үк тормыш вәхшилекне, азгынлыкны, җавапсызлыкны, ялганны алга куя башлады. Нинди заманга чыктык?!

Ә без яшь чакта бөтенләй икенче тормыш иде. — Исмәгыйль абзыйның йөзе кабат яктырып китте. Кабат яшьлегенә кайтты. Җыерылып килгән маңгае, кашлары язылды.

— И-и-и, без яшь чакта кызларның кулын гына тотсаң да зур бәхет була торган иде. Бит очыннан гына булса да үбү бәхетенә ирешсәң, башың күккә тиеп йөри инде. Әле куркасың, үбеп алган өчен йөргән кызың үпкәләп, ташлый күрмәсен дип борчыласың. Бар иде саф чаклар. Кызлар да бик итагатьле, оялчан иде. Әле шулар арасыннан да өйләнер өчен иң әйбәтен эзлисең, үзеңә тиңен генә сайлап аласың. Шуңа күрә элеккеләр арасында берсенең дә, аерылышу турында сөйләү түгел, башларына да кереп чыкмый иде. Аерылуның ни икәнен белмичә, үз ярлары белән үлгәнче гомер кичерде. Мин шул замандагы саф мәхәббәтне, изге хисләрне янә кайтарыр идем.

Кайтыр алар, Исмәгыйль абзый, кайтырга тиеш. Майлы ботка да туйдыра бит. Әнә Америкада, Көнбатыш илләрендә, бозыклыктан, вәхшилектән, теләсә кайда, хәтта кеше күз алдында теләсә ни эшләп торулардан туеп, саф мәхәббәт, инсафлыкка кайта башлаганнар. Яңача фильмнар төшерәләр икән. Классик матур әдәбиятка әйләнеп кайтканнар, ди. Безгә дә, бүгенге тәрбиясезлек чоры үтеп, матурлык, шәфкатьлелек, изге хисләр чоры әйләнеп кайтыр, иншалла!

*1999*

# Яшь чак — кайнар чак

Шифаханәгә килгәнемә атнага якын вакыт үтеп китте. Иртәнге ашны ашаганнан соң, һәрберебез төрле процедураларга тарала. Авылдан килгән әби-бабайлар гына түгел, әле кайбер яшьрәкләр дә, килгән-килгән алыйк инде, дип ахылдый-ухылдый дәвалау курсларының барысына да йөрергә тырыша. Табибларның, ярамый, өзлегерсез, дип кисәтүе дә файдасыз.

Мин алай «комсызланмыйм», үземә кирәк берничә дәваны алам да, тиз генә бүлмәмә кайтып, эшкә чумам. Шифаханә шартларында әйбәт языла: ашарыңа әзер (вакыт үткәреп пешереп йөрисе юк), беркем борчымый, арымас өчен кичен аллеялар буйлап саф һавада, хуш исле чәчкәләр исен иснәп йөреп керәсең. Аннары рәхәтләнеп яз да яз.

Шундый ял итеп йөрүләрнең берсендә, арттан берәү куып тотты.

— Исәнмесез! Зинһар, гафу итегез. Сезнең янәшәдә барырга рөхсәтме?

Мин, уйларымнан арынып, аңа күтәрелеп карадым. Озын буйлы, чибәр генә, чәчләре агара башлаган урта яшьләрдәге бер ир. Гаепле кеше сыман, янәшәмдә барыр өчен, минем рөхсәтемне көтеп тора.

— Рөхсәт, — дидем, уйларымны бүлдерүенә ачуым килсә дә. Чөнки сүтелә башлаган йомгак очын яңабаштан эзләргә, фикерләрне өр-яңадан тупларга туры киләчәк. Шуңа күрә фикеремне бүлдергәнне бер дә яратмыйм.

— Рәхмәт. Беләсезме, без сезне инде ничә көннәр күзәтеп йөрибез. Килгән көнне үк сезнең кем икәнне белдек. Шуңа күрә яныгызга килеп сүз кушарга да кыймыйбыз. Сез шундый кырыс, шундый горур. Өстәвенә чибәр. Безнең ише гади халыкка төкереп кенә карыйсыздыр кебек тоела. Менә бөтен батырлыгымны җыйдым да килдем әле яныгызга. Сөйләшәсегез килмәсә, сразы куып җибәрегез. Үпкәләмәм.

— Беренчедән, без дигәнегез кем була инде?

— Без инде менә, бергә җыелышып йөри торган ир-егетләр. Сезгә күзе төшмәгәннәр юк бит биредә. Беренче кичтә клубка чыгып, барысының да ушын алып биеп кайтып киттегез. Көн саен сезнең биюне карарга дип киләбез, ә сез күренмисез. Нигә йөрмәс булдыгыз клубка?

— Мин монда, нигездә, эшләргә дип килдем. Язуга бер кереп киткәч, ташлап булмый, фикерне өзәсе килми. Шуңа күрә хәтта биюгә дә чыгып булмый. Ул да минем иң яраткан шөгыльләремнең берсе.

Ә менә, икенчедән, сез минем турында ялгыш фикердә. Мин барлык кешегә дә тигез карамасам да, әйтик, алкашлар белән ялкауларны, хатын җилкәсендә яшәгән ирләрне, мактанчыкларны, ләһүрә хатыннарны һәм шуңа охшашларны кешегә санамыйм, аларныерактан ук танып, сөйләшү түгел, борылып та карамыйм, нормаль кешегә төкереп үткәнем юк. Тыңлыйм сезне.

— Рәхмәт. Илнар мин. Сезнең дәрәҗәдә үк булмасам да, төшеп калганнардан түгелмен. Миңа да сөйләшеп фикер алышырлык кеше аз монда. Әгәр риза булсагыз, сезнең белән сөйләшеп йөрер идем. Сезгә комачау итмәм, туйдыра башласам, әйтерсез — сүземнән туктармын.

— Ярар, сөйләштек, килештек. Бүген озак йөри алмыйм. Язып бетерәсе әйберем бар. Иртәгә шул вакытта йөрергә чыгармын. Хушыгыз, — дидем дә борылып китеп бардым.

Ул, кыяр-кыймас кына:

— Сау булыгыз! — дип, артымнан карап калды.

Икенче көнне әйткән вакытта ул көтеп тора иде инде. Тирә-юньгә хуш ис бөркеп торган аллы-гөлле чәчкәләр янында. Аллеялар чиста, матур. Илнар, исәнләшеп, күчтәнәч итеп алып килгән шоколадын миңа сузды да:

— Күптән көтәм инде мин сезне, чыкмыйсыз дип торам. Алданрак килдем бугай.

— Әйткән сүз — аткан ук. Озак йөри алмаган хәлдә дә килеп әйтеп киткән булыр идем. Мин — сүз кешесе. Башкалардан да шуны таләп итәм. Сүзендә тормаган кешене үзем дә яратмыйм.

Хәл-әхвәлләрне сорашканнан соң, Илнар болай диде:

— Мин сезнең язучы икәнне беләм. Үзем дә аз-маз сызгалыйм. Сезгә җитеп булмый инде анысы. Никтер сезгә яшьлек елларымдагы маҗараларны сөйлисем килә. Берәр әсәрегезгә кушып җибәрергә дә ярап куяр, бәлки. Кушмасагыз да сүзем юк. Сезнең белән фикер уртаклашасым килә. Рөхсәтме?

— Сөйләгез, әйдә. Тик мин тыңларлык булсын.

— Хөкемегез нинди булыр бит. Ошамаса, сөйләгәндә үк бүлдерерсез. Шулай да сезгә ошар төсле.

*** * ***

Мин яшьтән үк, егет чактан шифаханәләргә, ял йортларына йөрергә яраттым. Элек юлламаларны бушлай бирү гадәте бар иде, яхшы эшләгәннәргә. Шуңа күрә миңа ел саен нинди дә булса шифаханәгә бару мөмкинлеге ачылды. Союзда булмаган җир калмады, дисәм дә була.

Шулай бер елны, чибәр, яшь, өйләнмәгән егет чак, мастер чакыртып кертте дә:

— Илнар, Баку тирәсендәге бер ял йортына яна торган юллама бар, барасыңмы? — ди.

Ялга китәм дип торганда, минем өчен бәхет инде бу юллама.

— Барам, ник бармаска андый җиргә, — дим. Рәхмәтемне әйттем дә, юлламаны алып, ярты көн дигәндә бөтен кирәк-яракны, медицина кенәгәсен әзерләп, икенче көнне чыгып та киттем.

Булганыгыз бармы Бакуда? Юкмыни? Жәл. Бик матур шәһәр. Менә шул, Бакуга килеп төштем самолет белән. Автобус каршы алырга килгән. Утырдым да киттем. Беренче көнне үк шифаханәдә бер кызга күзем төште. Яшь чак бит инде — кайнар чак. Озак уйлап торыш юк. Кыз чибәр: куе сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле, озын буйлы, сылу гәүдәле, сөйкемле йөзле. Кем кызыкмас. Мин килгәнче сүз кушып караганнар үзе — берсенә дә күз салмаган. Балтыйк буеннан икән, Ригадан. Эллина исемле ярым татар кызы. Күршем шундук кирәкле мәгълүматны биреп алды.

Ашханәгә килеп керүе булды, барысы да — ирләр дә, хатын-кызлар да — аңа борылып карады. Матур кешене кем яратмый. Кызым, үз дәрәҗәсен белеп, горур гына күрше өстәл янына килеп утырды. Минем шунда, эх, ник мине алар өстәле янына утыртмадылар икән дип, ачуым килеп китте. Ярар, кыздан күземне ала алмыйм бит инде. Әллә минем карап утыруымны сизде, миңа күтәрелеп карады һәм үзе дә кызарып китте. Әһә, мәйтәм, ошатты бу мине. Кешегә битараф булсаң, йөз кызармый. Борчак пеште. Болай булгач, сүз катарга була моңа дип уйлап алдым.

Шулай иттем дә. Тиз генә ашап чыктым да аны көтеп тора башладым. Ишектән чыкканда ул да мине күрде, янә кызарды. Мин, әтәчләнеп, янына ук килеп кунакладым.

— Исәнмесез, добрый день! — мәйтәм.

Кайсына җавап бирер икән дип тикшерәм моны. Татарчасын да беләме, янәсе.

— Исәнмесез! — ди бу миңа.

Әһә, мәйтәм, белә икән. Барыбер үз кеше инде, дим. Мөселман ич.

— Сез татармыни?

— Мин татарчаны бик белеп бетермим. Әтием генә татар, әнием латышка, — ди бу.

Шуннан сөйләшеп киттек инде. Күбрәк русча сөйләшәбез. Анда-санда татарчасын да кыстырып җибәрәбез. Аның дөрес әйтмәгән сүзеннән рәхәтләнеп көләбез. Шактый дөрес сөйләшергә өйрәттем мин аны киткәнче. Ай буе бергә йөрдек, экскурсияләрдә булдык. Бер-беребезгә үлеп гашыйк иде. Иреннәр иреннән китмәде. Әмма шуннан артыгын эшләмәдек. Хисләрем тулып ташканга, хәтта аңа багышлап шигырьләр яза башладым. Язам да бирәм, язам да бирәм үзенә. Әле хәзер дә кайберләре истә.

Гашыйк булдым: эчмәсәм дә,
Исереп йөрим хисемнән.
Каным кайный, йөрәгемә
Әйтерсең ут төртелгән.

Иреннәреңне үбәмен,
Һәрчак елмайсын, диеп —
Иртәнге чыклар эчендә
Уянган чәчкә кебек.

Гади генә булсалар да, беренче шигырьләр бит, йөрәктән чыкканнар. Менә мин шундый да әле, дип шаккатырасым килә. Чынлап та бу шигырьләр аңа бик көчле тәэсир итте. Ул аларны үбә-үбә укыды, җыеп барды. Хәзер җыеп утка яккандыр инде. Ярый. Ял йортында көннәр санаулы гына бит. Кайтыр вакыты якынлашкан саен моңая барды Эллинам. Кайчакларда елап та ала.

— Илнар, как же я без тебя буду жить. Мин моңарчы шулай каты итеп беркемне дә ятратканым булмады, — ди.

— Борчылма, бәгырь җимешем. Без бит синең белән очрашачакбыз. Әллә миңа җиңел дип беләсеңме? Мин дә сине яратам бит. Килеп алам мин сине, килеп алам, бер дә борчылма, — дим.

Ул тынычлангандай була. Иреннәремнән, күзләремнән үбә. Чәчләремне сыйпый, иркәли, назлый, нишләтергә белми. Үзем дә шул хәлдә инде. Минем йөрәктә дә ут. Аннан калып берничә көн ничек яшәрмен монда дип уйлыйм. Әллә бергә китәргәме? Шулай да ял вакытын бетереп кайтырга булдым.

Эллина киткән көн бик авыр булды. Елый-елый аерылыштык. Муеныма сарылып үкседе Эллина. Самолетка утыртып җибәргәч, кире ял йортына кайтканда үләм дип торам: йөрәкне сагыш басты, күзләрдә яшь, артыннан җәяүләп чабасы килә.

Калган ике-өч көнне көчкә түздем дә өйгә кайтып киттем. Шылтыратырмын, хат язармын, көт, дигән иде. Инде көтәм. Бер көн көтәм, ике көн, атна көтәм. Көн саен хатлар язам — бернинди хәбәр юк. Үзем шылтыратам инде. Телефоннан ни сөйләшеп бетерәсең. Тагын ике-өч көннән хаты килмәсә, чыгып китәм Латвия якларына дип уйлап йөри башладым.

Бер-ике көннән, мине куандырып, төрле көннәрдә язылган өч хаты берьюлы килеп төште. Менә күрсәтергә алып килдем әле. Өчесе дә шунда, бәлки, укып карарсыз әле.

Хатлар русча язылган. Менә аларның кыскача тәрҗемәсе.

*«Хәерле иртә, җанкисәгем!*

*Синең турыңдагы уйлар белән йокыдан тордым. Кәефләрең ничек икән дип борчылып куйдым. Чөнки бездә һава торышы нык үзгәрде: көн ямьсез, яңгырлы, салкын, шыксыз, күңелгә бетмәс-төкәнмәс сагыш сала. Безнең икебезнең ике җирдә булуны табигать тә авыр кичерә бугай — ике көн елый инде. Күңелем күтәрелмәсме дип, синең хатларыңны кабат-кабат укыйм. Сине күз алдына китерәм. Хатларыңа салган җылы хисләреңнән бераз җиңелрәк булып китә. Ярый әле эшем, шөгылем бар, югыйсә саташып үләр идем. Сагынам, чыдап булмас дәрәҗәгә җитеп сагынам. Үзеңне күрәсем килә...»*

*«Хәерле көн, җанкисәгем!*

*...Эшкә килеп утырсам да, җаным тыныч түгел, эшләп китә алмыйм. Күз алдымда һаман син. Шылтыратып хәлләремне белгән өчен рәхмәт сиңа. Тавышыңны ишеткәч, күңелем тула. Аерылышкандагы кебек, башымны иңеңә салып, үксеп-үксеп елыйсым килә. Беләсеңме, кайтканда юл буе сине күз алдымнан җибәрмәдем: озатып калгандагы күз карашың, яшь аралаш елмаерга тырышып басып торуың мине өйгә кадәр озатып кайтты. Инде синең турында уйлый-уйлый, синең белән серләшә-серләшә эшкә, кибетләргә йөрим. Саташам бугай... Эштән кайтып керсәм, телефон шылтырый. Йөгереп барып, төрепкәне алдым. Син икәнне беләм ич мин, йөрәгем белән сизәм, әмма тавышың ишетелми. «Алло, алло!» дия-дия гаҗиз булдым. Ниһаять, бөтен киртәләрне үтеп, синең матур, йөрәккә якын тавышың, назлы сүзләрең миңа килеп ирешә. Шигырең белән шаккатырдың: монысы тегеләреннән дә матур. Югалтма, очрашкач, үземә бирерсең. Синең шулай мине уйлап, мине сагынып, мине яратып йөрүең нык куандырды. Рәхмәт сиңа. Беразга гына булса да тынычланып калдым. Мине онытма, башкаларга күз салма, дисең. Шундый баһадирым булганда, миңа беркем кирәк түгел. Бары син, син генә минем уемда. Үбәм, үбәм, үбәм...»*

*«Хәерле кич, җанкисәгем!*

*Бүген иртән хатымны язарга өлгермәдем. Тиз генә җыендым да институтка чыгып чаптым. Эшләрем җайлы булды, Аллага шөкер. Син дә теләп торгансыңдыр, бәлки. Менә, эштән кайткач, тиз генә киемнәремне салып элдем дә сиңа хат язарга утырдым: каләм аша гына булса да синең белән серләшәсем килде. Кәефләрең ничек бүген? Яңгыр сездә дә явамы? Бездә атна буе коя, кәефне җибәрә. Ярый әле дөньяда мине уйлап, мине сагынып йөрүче берәү бар дип юанып яшәү мөмкинлегем бар.*

*Сине сагынып, сине уйлап йөри-йөри ябыгып беттем инде. Тизрәк килсәңче! Мөмкинлек булу белән телеграмма сугармын, очып килеп җитәрсең, яме! Очрашу мизгелләрен күз алдыма китереп, һуштан язарлык хәлгә килəм...*

*Сиңа татлы йокылар, төшеңдә мине күрүеңне, мине назлавыңны теләп, мин — сине өзелеп сөйгән Эллина булыр».*

Сүз дә юк: матур хатлар. Мин аларны Илнарга кайтарып бирдем.

Хатларны укыгач, бигрәк тә соңгысын, күңелгә корт керде. Барам, телеграмма гына килсен. Эштә алдан ук сөйләшеп куйдым. Ялым беткән иде бит инде, үз хисабымнан алырга булдым. Ризалаштылар тагын. Телеграмма без аерылышкан көннән ай ярым үткәч килеп төште. Озак көткәнгә ачу да килә башлаган иде инде, шулай да рөхсәтсез кеше янына барып булмый бит инде. Әти-әнисе бар. Туганнары бар дигәндәй.

Алдан сөйләшенгән булгач, андый-мондый каршылык килеп чыкмады. Билет алдым да очтым Ригага. Эллина аэропортка килеп каршы алды. Бер-беребезне күрү белән, кочаклашып елаштык. Шундый якын, шундый сагынылган.

Әтисе белән әнисе аерылышканнар икән. Миңа никтер әйтмәгән иде. Әнисе белән генә яши икән. Кич җиткәч, берничә туганы килде. Кызыксынып, «кияү» карарга килгәннәр инде. Бар да ошатты тагын үземне.

— Егет шәп, егәрле дә. Тормышыгызда терәк булырлык. Ычкындырмагыз моны, — диләр, миңа карап елмаеп. Үзләренчә дә өстәп куялар шунда. Мин аңламыйм. Утырам инде елмаеп, тиле кебек.

Эллина да, әнисе дә минем янда бөтерелеп кенә йөриләр.

Кунаклар киткәч, Эллина белән урамга чыктык. Ул кечкә шәһәрне күрсәтергә исәп итте. Сөйләшеп йөргәндә, кызым миңа:

— Сине туганнарым да, әни дә булачак ирем дип кабул иттеләр. Бәлки, монда гына калырсың, — дип куйды. — Дөресен әйтим: син бүген миңа никадәр куаныч, күпме шатлык алып килдең. Яратуымның чиге юк. Син дә яратасың бит. Яратмасаң, шулкадәр еракан очып килмәгән булыр идең, әйе бит? Кал монда! — диде.

Мин нәрсә дияргә дә белмәдем. Килгән көнне үк шундый сөйләшү. Бераз кәефем китте. Шулай да сиздермәдем.

Урамнан әйләнеп кайтканда, әнисе йоклаган, безгә урынны бергә җәйгән иде. Хәзерге заман булса, мин аптырамас та идем. Бу бит моннан утыз ел элек булган хәл. Әле артык булмаса. Моңарчы кагылмаганмын икән, мөнәсәбәтләр хәл ителмичә кагылмаячакмын дип, күңелгә беркетеп куйдым. Эллинадан урынны аерым җәйдердем.

Иртәгесен иртүк, аннан-моннан капкалап кофе эчтек тә, мине бакчаларына җир казырга җибәрделәр. Төшке ашка чакырып алдылар да, ашап-эчкәч, тагын шул эшемдә булдым. Эллинаны рәтләп күрмәдем дә. Кичен, эт булып кайтканнан соң, бер чынаяк чәй эчтем дә урыныма кереп яттым. Алар әниле-кызлы сөйләшә калды. Бакчаларында алма бик күп икән, коелганнарын җыйдырып, иртәгесен базарга сатарга чыгарып җибәрделәр. Ике-өч көн шулай алма сатып йөргәч, башка уй төште: бу ни хәл бу? Моны ничек аңларга? Эллинаны мин күрмим дә диярлек. Рәтләп сөйләшкән дә, назлашкан да юк. Нәрсә, мин базарда алма сатып утырыр өчен килдемме монда? Өйдә дә эшләмим мин аны. Миндә дә бар горурлык, дидем дә Казаныма кайттым да киттем. Шуның белән мәхәббәт тә бетте. Мин киткәндә, Эллина елап озатып калса да, күңелемдә элекке хисләр юк иде инде. Яшь чак — кайнар чак. Озын-озак уйлап торылмый. Күзләр аннары гына ачыла башлый икән...

Кичке ашка барыр вакыт җиткәнгә, шул урында хикәятне тәмамлап, җыенып өчен икебез дә бүлмәләребезгә кайтып киттек. Кичке аштан соң мин эшемә утырдым, кабат йөрергә чыкмадым.

Икенче көнне шул ук вакытта, шул ук урында кабат очраштык. Илнарның икенче хикәятен сөйлисе бар иде.

* * *

Үзем Казанда эшлим, үзем атна саен авылга кайтып йөрим. Кичен клубка чабабыз. Мин баянчы да бит әле. Үзем уйныйм, үзем җырлыйм. Тавышым да матур минем, менә, бер җаен туры китереп, җырлап та күрсәтермен әле. Клубка чыгарга тоткарлансам, кызлар хәтта өйгә килеп алалар. Араларында миңа гашыйк булганнары да байтак. Мин теге хәлләрдән соң бер кызга да җитди карамыйм, күз төшми, бетте-китте. Ничек кенә ачу килсә дә, Эллинаны онытып бетереп булмый. Ну түзәм.

Беркөнне апа кунак кызы алып кайтты. Ул гәүдә, ул чибәрлек. Минем сразы күз төште. Ул да мине ошатты. Йөреп киттек бит. Атна саен кайтам, ул да кайта. Кич буе клубта биибез, җырлыйбыз. Аннары бергәләп кайтабыз.

Бер атнада мин авылга кайта алмадым. Теге кыз кайткан. Клубка чыккан. Электән үк аңа күз салып йөрүче Илгиз дигән егет, мин юктан файдаланып, озатып куйган бит кызны. Капка төбендә сөйләшеп тә торганнар.

Икенче атнада авылга кайткач, бу турыда миңа бәйнә-бәйнә сөйләделәр. Синең теге кызың Илгиз белән чуалды, диделәр.

Кич җиткәч, киттем клубка. Кесәдә ике төймәле пәке. Клубка бәреп тә кердем, Илгизне, утырган урыныннан суырып алып, урамга алып чыктым да коймага китереп сыладым. Яшь чак — кайнар чак.

— Йә, әйтеп җибәр, кабахәт, аның минеке икәнен белә идеңме? — дип сорыйм, зәһәремнән зәңгәрләнеп.

— Белә идем, — диде Илгиз, гырылдап.

— Белгәч, ник озаттың? Ник капка төбендә сөйләшеп тордың?

— Соң бит, Илнар, аннан бернәрсә дә булмаган. Арабызда берни юк. Син булмагач, кайтмагач, сиңа кирәкми икән дип уйладым. Кирәк булса, кайткан булыр иде, дидем.

— Нинди хәл булмас. Бер атнада кайтмаганмын икән, бетте, ташлады дигән сүзмени? Менә кайттым ич.

Шул арада теге кыз да йөгереп килеп җитте. Безнең арага кермәкче булган иде дә, мин аны этеп кенә җибәрдем. Көчне исәпләп бетермәгәнмен — кызым җиргә барып төште.

— Арабызда берни булмады, Илнар, Илгизгә тимә. Озатып кына куйды, — дип ялына.

Минем янә җен ачуларым чыкты. Әһә, озатып куйдымы? Илгизнең кулларын күтәртеп, коймага терәдем дә, кулына чамалап, пәкене китереп кададым. Ярый әле кулына тимәгән, ике бармак арасына эләккән. Аннары сөйрәп алдым да изгәнче кыйнадым. Өстенә төкереп, өйгә кайтып киттем. Илгиз бик озак аңына килә алмыйча

яткан. Кызга да эләкте — сүз белән. Иртәгесен китеп тә бардым.

Икенче атнада кайтсам, әти дә, әни дә минем белән сөйләшми. Аңгыраеп тик торам. Ни булганын да әйтмиләр. Киттем клубка. Анда мәгълүм булды: мине судка чакыру кәгазе килгән икән. Илгиз судка биргән булып чыкты. Инде кунак кызына ялыныч төште.

— Судка бар инде, хәлнең ничек булганын аңлатып бир, зинһар. Мине утыртсалар, мин аннан барыбер кеше булып чыкмаячакмын, миңа бит әле егерме икеләр тирәсе генә. Чыккач, сиңа көн булмаячак, уйла, — дидем.

— Бармыйм. Син миңа да кул күтәрдең, — ди.

Бу кыз белән әни дә сөйләшеп караган. Бармыйм, мине дә рәнҗетте, дигән әнигә дә.

Берничә көн үткәч, үзе килде безгә:

— Ярый, барырмын, аңлатып бирермен, — диде.

Судьяга дөрестән дә барган. Барын да энәсеннән җебенә кадәр сөйләп биргән, аның гаебе юк, без үзебез гаепле, дигән. Шуннан соң Илгиз гаризасының көче бетте, суд булмый калды.

Егет чак — кайнар чак. Үзеңнеке дип санап йөргән кызга чит куллар тидертәсе килми шул. Гөлт итеп кабынып китәсең. Соңыннан ни буласын уйларга вакыт буламыни андый чакта.

Бу кыз белән дә мәхәббәт шунда бетте. Элеккечә якынаеп китеп булмады. Кыз да курыккандыр, бу кадәр дуамал кеше белән аралашмавың хәерле дип уйлагандыр...

Хикәятне сөйләп бетергәч, миңа җиңел булып китте. Ярый әле җинаятьнең зурысы кылынмаган. Утырткан булсалар, бу кызулык белән Илнарның кемнәргә әйләнеп бетәсен чамалап та әйтеп булмый хәтта. Күпме кеше зыян күрер иде. Ходай саклаган.

— Мондый кайнарлык, мондый кызулык белән ничек өйләндегез соң? — дидем мин, гаҗәпкә калып. — Курыкмыйча сезгә кияүгә чыккан хатын йөрәкледер.

— Монысы инде өченче хикәят, — диде Илнар. — Аның да үз тарихы бар.

— Болай булгач, иртәгә — тагын шул ук урында һәм шул ук вакытта. Әлегә сау бул, — дидем дә бүлмәмә юнәлдем. Бу юлы ул мине безнең корпуска кадәр озатып куйды.

* * *

Иртәгесен Илнар мине ашханә ишеге төбендә көтеп алды.

— Гафу итегез, минем озакламый Казанга кайтып китәсем бар. Мөмкин булса, хәзер сөйләшик, — диде.

— Ярый алайса, сөйләшик соң, — дидем дә акрын гына аллея буйлап киттек.

— Беләсезме, минем өйләнү бик кызык кына килеп чыкты, — дип башлады сүзен Илнар. — Мин ул чакта йөреп арыган, егерме тугызны тутырган идем инде.

Бервакыт бергә эшли торган иптәш малаем Павел әйтә:

— Илнар, әйдә бүген кызлар янына барабыз, — ди. — Бауман урамында минем сөйгән кызым яши. Аның белән чибәр генә татар кызы тора. Минем Олямның туган көне. Безне кунакка чакырдылар. Барабызмы?

— Баруын барырбыз да, минем бүләгем юк бит. Бүләксез ничек барасың инде кешегә. Вакыт та аз калган, җитмәсә.

— Аптырама юкка. Бауман тулы кибет. Керәбез дә алабыз. Мин үзем дә әле күчтәнәчләрне шунда гына алырмын дип торам.

— Ярый алайса. Тиз генә кырынып алам да — киттек.

Әйбәтләп кырындым да, яңа матур костюмымны киеп, чыгып киттек кызлар янына. Үзем барам, үзем уйлыйм: монысы нинди кыяфәттә икән тагын? Ошар микән? Әйбәт кыз микән?

— Павлик, карале, ул кыз нindирәк соң? Минем күз төшәрлекме?

— Төшәрлек, төшәрлек. Бик чибәр, акыллы да.

— Алай булса, сразы өйләнәм. Менә әйтте диярсең. Артык акыллы гына булмасын.

— Бик кызулама әле, башта барып күр, — диде Павлик.

Бауманга килеп җиткәч, кибетләргә кереп чыктык та кызлар фатирына юнәлдек. Ишекне Павликның сөйгән кызы Оля ачты. Үзем бүләкләремне, күчтәнәчләремне бирәм, үзем теге кызны күзлим. Юк, күренми. Түргә уза башлагач, кухня ишегеннән күреп калдым. Ул анда нидер эшли иде, шундук күңелемә кереп утырды. Эчемнән, бу минем хатыным булачак, дип куйдым.

Һәм шулай булды да. Шул ук көнне мин аны, әти-әнигә күрсәтергә дип, авылга кунакка чакырдым. Ул риза булды.

— Туктале, тукта! Сүзеңне бүлгән өчен гафу ит. Ничек инде бер белмәгән егеткә шундук әниләренә кайтырга ризалык бирергә кирәк. Танышуыгызга бер генә атна була бит әле.

— И ханым! Сез минем яшь чагымны күргән булсагыз, бу сорау башыгызга да кереп чыкмас иде. Беләсезме, мин нинди чибәр идем. Кызлар үзләре өерелеп чапты артымнан. Шуларның һәрберсе миңа кияүгә чыгарга риза иде, холкымның кызу булганын белгән өстенә. Сез ул чакта мине күргән булсагыз, үзегез дә гашыйк булган булыр идегез әле. Ә мин сезгә өйләнмәгән булыр идем, чөнки сез чибәр генә түгел, артык акыллы да. Ирләр үзләреннән өстен хатыннар белән яшәргә курка. Кимсенә, аннан түбән булуына хурлана. Гомер буе хатыныңнан кимсенеп яшәү — ирләр өчен үтергеч җәза. Сез аны аңламыйсыз гына.

Шулай итеп, мин аңа тәкъдим ясадым, ул риза булды. Әтиләр дә ошатты. Дөресен әйткәндә, типтереп яшәүдән дә туйган идем инде. Гаилә корасым, балалар үстерәсем килде.

— Балагыз күпме соң?

— Берәү генә шул. Бер малай белән калдык. Баладан соң хатынымны кан басымы борчый башлады. Табиблар башка бала тапмаска куштылар. Менә шулай итеп яшьлек узып та китте. Минем китәр вакыт җитеп килә икән. Гафу итегез, мин китим инде. Иртәгә иртүк килеп җитәм мин.

— Хикәятләрегез өчен зур рәхмәт. Чынлап та шактый кызыклы. Башыма киртләп куйдым. Кайчан да булса басылып чыкса, укырсыз, иншалла. Хушыгыз, исән-сау йөрегез! Минем дә китәр көнем җитеп килә.

— Хушыгыз, ханым! Әле сез киткәнче очрашырбыз. Казанда да очрашмый тормабыз, Алла боерса. Хәзер бер-беребезне беләбез бит инде. Мин сезнең язмаларны бик яратып укыйм.

Илнар шулай диде дә, электричкага соңга калмыйм, дип йөгерде. Әле бүлмәсенә кереп кайбер әйберләрен дә аласы бар.

*2006*

## Мине генә ярата, димә икән

— Минем ирем мине генә ярата, чит хатыннарга борылып та карамый, миннән башка, гомумән, яши алмый, дип, бер генә дә әйтеп булмый икән. Ә мин ирем турында гел шулай уйлый идем, уйлап кына калмыйча, туры килгән саен мактана идем, — диде Әлфия ханым, моң тулы күзләрен миннән яшерергә тырышып. — Дөрестән дә, мин ирем белән бик бәхетле яшәдем. Менә дигән ике ул үстердек. Ирем лаеклы ялга чыкса да, яраткан эшен дәвам итте. Яхшы белгеч иде — җибәрмәделәр. Эше командировкалар белән бәйле булганга, күп чакта мин дә аның белән дөнья гизеп йөрдем. Гомерем бернинди сикәлтәләрсез, җайлы гына узып бара иде. Кем уйлаган: алтмыш яшенә җиткән ирем башын югалтып гашыйк булыр һәм миңа гомер баешымда иремне югалту куркынычы янар, дип.

Әлфия ханым, фикерләремне җайга салыйм диптер, сөйләвеннән туктап калды. Әле күптән түгел генә башыннан кичергән газаплы көннәрен искә алу, яңадан кичерү авырдыр, билгеле. Мин, аның уйларын читкә җибәрмәс өчен, бер сүз эндәшмичә генә янәшәсеннән атладым. Ул бер көрсенеп алды да сүз йомгагын сүтте дә сүтте.

— Соңгы командировкасында булды бу хәл. Китте дә югалды. Бу юлы аның белән бара алмый калган идем. Баштарак хатлар язып, шылтыратып, мине үз янына чакырып торган иремнән ун-унбиш көн узгач — бер хәбәр дә юк. Кинәт бар да өзелде: үзем язам — җавап бирми, сөйләшергә телефонга чакырам — килми. Хәсрәткә төштем — гомер булмаган хәл бит. Ни булыр бу, дим. Кайгыга батып, нервымны ашап өйдә утыруның мәгънәсе юк дип җыендым да киттем ирем янына. Каршы ал, дип, телеграмма суктым. Үзем барам, үзем уйлыйм: каршыларга килерме, юкмы? Килде килүен, әмма йөзендә — канәгатьсезлек, мине сагынуның әсәре дә юк.

— Нигә әле тиктомалдан киләсе иттең, бер-бер хәл булмагандыр бит? — ди бу миңа, күзләремә карамыйча гына.

— Синнән хәбәр булмаганга борчылып килдем, — дим. — Ни хатка җавап язмыйсың, ни телефонга килмисең. Үзеңә ни булды синең?

— Ник язмаска, яздым. Алмагансыңдыр гына, — дип тынычландырырга маташа.

Ярар, шулай, чит кешеләр кебек, төксе генә сөйләшә-сөйләшә кайттык аның торган бүлмәсенә. Мин килгәнне белеп, кичен иптәшләре җыелды. Араларында Казаннан килеп эшләүчеләр дә бар. Кайберләре бер миңа, бер аңа карап елмаешып утыралар. Мин моны күрәм бит инде.

Берсе түзмәде:

— Нәрсә, Булат, бүген бер җиргә дә бармыйсыңмыни инде? — дип куйды, мыскыллы елмаю белән.

Йөрәгемне пычак белән сызып үттеләрмени — сызлап, әрнеп авырта башлады. Иремә карадым.

Иремнең йөзе җыерылып килде. Ачуы чыкты. Ул усал сүз әйтмәсен дип, мин тизрәк:

— Барыр, барыр, мин килде дип планнарын үзгәртмәс бит инде, — дип куйдым. Үзем эчтән янам инде.

Бу сүзләрдән соң иремнең бөтенләй кәефе китте. Моны күргәч, минем арып килүемне сылтау итеп, иптәшләре таралыша башлады.

Алар чыгып китүгә, мин сак кына бу турыда сүз кузгатып телен ачмакчы булып карасам да, ул бер сүз дә әйтмәде. Күреп торам: газабының иге-чиге юк. Үземнең дә йөрәктә ут яна. Әлләниләр әйтеп ташлыйсым килә — түзәм. Авыр сүз белән иремне үземнән бөтенләй читләштерәсем, араны өзәсем килми. Түзәм, көтәм.

Әлфия ханымның дулкынлануы йөзенә, бөтен хәрәкәтенә күчте. Өерелеп килгән күз яшьләре әйтәсе сүзләрен туктатып калды. Тамак төбенә килеп тыгылган төерен йотып җибәрә алмый газапланды. Үксеп елап җибәрмәс өчен, куллары белән битен җилпәзәләп, үзен тынычландырырга тырышты. Күзләрендә мөлдерәгән яшьләрен сыпырып төшерде дә:

— Беләсеңме, айлар буе күрешми сагынышсак та, ни яратышу, ни ачылып китеп сөйләшү булмады ул кичне. Дөрес, мине ташлап чыгып та китмәде. Әмма бөтен хәрәкәтендә, күзләрендә — чиксез хәсрәтләнү. Үзенә урын табалмый интекте. Янды, көйде. Боларны күрү миңа да авыр тәэсир итте.

Ярар, шулай яшәдек берничә көн. Кешесе барын сиздем бит инде. Ник килгәнемә дә үкенеп куйган мәлләр булды. Яраткан иреңнең газаплануын, ул газапларның чит хатын аркасында булуын күрүдән дә авыр нәрсә бар микән? Кичләрен беркая бармаса да, көндезләрен өйдә юк бит инде ул. Иртүк эшкә дип чыгып китә, кич кенә кайта. Аның кайларда йөргәнен кем тикшергән. Очрашканнардыр инде, аңлашканнардыр. Сизәм бит: элеккечә сөйми, иркәләми — миннән бөтенләй читләшкән, бизгән. Боларны агу йоткандай йотып, түзәргә, җанын ашамаска булдым. Күрә торып йөрәк ярасына тоз салмадым. Ireңне бөтенләй югалтасың килмәсә, түз, күпме кирәк, шулкадәр көт, дидем үз-үземә. Гомердә булмаган хәл: алты дистәне тутырган иремнең күзләрендә яшь, моң, сагыш, ризасызлык. Күрсәтмәскә тырышса да, күрәм, сизәм — гомер иткән хатыны лабаса. Аның шулай газаплануын күтәрә алмыйча, әллә кайтып китим микән барысына да кул селтәп, дип тә уйлап куям кайчакта. Китә дә алмыйм. Шул китә алмавым хәерлегә булган икән, тәки саклап калдым бит иремне. Командировкасы беткәнче тордым да үзем белән алып кайтып киттем. Кешегә сөйләп йөреп дөньяга фаш итмәдем, зарланмадым, аны битәрләмәдем.

Киресенчә, тегесен оныттырырга тырышып, үзем күбрәк иркәләдем. Беркем белми калды. Өйгә кайтып бер ел үткәч кенә сөйләде ул үзенең мәхәббәте турында.

Әлфия ханым, ниһаять, елмаеп куйды. Зур алышта җиңеп чыккан баһадир кебек, канәгатьләнү кичерә иде.

— Олы яшьтәге кеше яшь чагындагыга караганда да ныграк, тирәнрәк итеп ярата икән. Башын югалтып, үзен-үзе белештермичә, бөтен дөньясын онытып, тирә-юнендә беркемне дә күрмичә гашыйк була икән. Хисләр катлаулы, газаплы булып, бөтен җаны-тәне, акылы белән сөя икән. Үзем күрмәсәм, кеше сөйләгәнгә генә ышанмас идем.

Шулай көн артыннан көн үтеп, аралар җайлана дип кенә торганда, беркөн ирем мине тетрәндергән сүзен әйтеп куйды:

— Әгәр теге юлы син үзең килмәгән булсаң, мин Казанга кайтмый идем инде, — диде.

Бу сүзләрдән йөрәгем жу итеп китте: безнең мөнәсәбәтләр чыннан да кыл өстендә булган икән ул көннәрдә. Минем тарафтан бер генә ялгыш адым, кирәксез сүз, кычкырыш-бакырыш булган булса, өзеләсе булган икән бу кыл. Әле дә ярый Ходай сабырлык белән камил акыл биргән. Хәзер шуңа шатланып бетә алмыйм.

Белмим, бәлки, хәзер дә аралары өзелеп бетмәгәндер. Бәлки, шылтыратышып, язышып торалардыр. Тикшермим дә, сорашмыйм да. Беркайчан да үчләшмәдем, исенә төшереп сүзләшмәдем. Нигә яраны тырнап, һәрдаим канатып торырга. Үземә карата нәфрәт уятыр өченме? Аннан кемгә файда? Араларыбыз җылынды, Аллага шөкер, мөнәсәбәтләребез элеккечә үк булмаса да, шактый әйбәтләнде. Шуңа канәгать булып торам инде. Балаларыбыз гаиләле булды, инде оныклар бар. Алга таба ни булыр — тормыш үзе күрсәтер. Әмма бер хакыйкатьне аңладым: беркайчан да, ирем мине генә ярата, миннән башка беркемгә дә карамаячак, дип әйтергә ярамый икән. Мин үзем шулай кабатларга, мактанырга ярата идем. Бәлки, шуңадыр да Ходай, чү әле, ашыкма, артык мактанма, дөньяда болай да була, дип күрсәткәндер миңа бу хәлләрне. Башкалар да моннан гыйбрәт алсын иде. Ирем мине генә ярата, дип һаваланмасын иде.

Әлфия ханым, менә шулай дигәндәй, башын кыңгыр салып, миңа карап елмайды. Әмма иреннәре елмайса да, күзләрендә яраткан ирен югалту куркынычыннан калган шомлы шәүләләрне күреп, борчылып куйдым: тынычланырга иртәрәк икән әле.

Әлфия ханым сөйләгән бу вакыйга миңа ирексездән икенче бер вакыйганы исемә төшерде.

* * *

Фәйрүзәнең заводка килеп эшли башлавына бер-ике ел булгандыр. Бүлекләрендә олы яшьтәге хезмәткәрләр белән беррәттән, әле кияүгә чыкмаган, тормышның ачысын-төчесен күрмәгән яшь кызлар да эшли иде. Бар да һавалы — мин кем, янәсе. Кыз чакта шулай буласың бит инде.

Көн дә ясанып, матур киенеп кенә, эштә дә елмаеп кына йөри торган Фәйрүзә көннәрдән бер көнне агарынган йөз, кызарган күзләр белән эшкә килеп керде. Моны кайберәүләр сизмәделәр, әмма яшь кызлар Фәйрүзәдәге бу үзгәрешне бик тиз күреп алдылар.

Бер ишесе борчылудан, кайберләре, кызыксынып:

— Фәйрүзә, ни булды сиңа? Мондый хәлдә сине моңарчы күргән юк иде. Нәрсә булды? Авырыйсыңмы әллә? — дип сораша башлады, теләктәшлек белдерде.

Фәйрүзәгә шул җитә калды. Ничә еллар тормыш авырлыгын, газапларын беркемгә дә, хәтта әти-әнисенә дә сиздермичә йөрәгендә яшереп, һаман саен үзен бәхетле дип күрсәтергә тырышып йөргән Фәйрүзә «шартлады»: күзләреннән яшьләре атылып чыкты, тугарылып, бик тиз үксүгә күчте. Үксүе аркасында тотлыга-тотлыга өендәге мәхшәр турында үзе дә сизмичә сөйләп бирде. Соңыннан үкенде үкенүен, әмма сүз авыздан ычкынган иде инде. Кызларның бер ишесе аны җәлләде, ә Гөлнур дигән кыз, үзен артык горур тотып:

— Җүләр икәнсең, шушы чибәрлегең, шушы акылың белән ник торасың ул ир белән? Сиңа тиң түгел бит ул, шуны үзең күрмисеңмени? Мин, мәсәлән, ирем шундый булса, ярты көн дә тормас идем, шундук ташлар идем. Хурланмыйча үземне кимсетеп тораммы соң! — диде.

Фәйрүзәнең бу сүзләргә нык хәтере калды, үзе дә сизмәстән рәнҗеде.

— Ничек шулай дип әйтә аласың, Гөлнур? Балабыз бар бит. Ничек ташлап китим инде? Бу уйның минем башыма да кереп чыкканы юк. Бәлки, үзгәрер әле, эчүен дә ташлар. Дөнья гел болай бармас, — дип куйды Фәйрүзә. — Менә тиздән син үзең дә кияүгә чыгасың. Күрербез, бәлки, синең ирең минекеннән дә начаррак булыр, ташлап китә алырсың микән?

Бу сүзләрдән Гөлнур, отыры кызып:

— Күрерсез, күрерсез. Андый булса, тормаячакмын да, аннан бала да тапмаячакмын, — дип өстәде.

Берничә айдан Гөлнур елга якын йөргән егетенә кияүгә чыкты. Туйны бик зур итеп уздырырга уйладылар. Бер ресторанның банкетлар залын матур итеп бизәделәр. Килгән кеше күп булды: туганнары да, дуслары да, хезмәттәшләре дә җыелышты. Һәм көтмәгәндә матур гына барган бәйрәмнең ямен җибәрерлек хәл булды: туй барган залга урамнан бераз салмыш ике пар кереп утырды. Мәҗлес халкы моңа башта гаҗәпләнсә дә, урын җитәрлек булганга, ярар, утырсыннар дигән фикергә килделәр һәм бераздан алар турында оныттылар да. Ләкин алар үзләренең барлыгын бик тиз сиздерделәр: кияү буласы кеше, үзенең кәләшен ташлап, шул чибәр кызларның берсе янына килеп утырган да аңа бәйләнә башлаган, үзе белән чыгып керергә чакырган. Кыз үзе риза булса да, аның белән килгән егетенә бу ошамаган: кияү балакайга салып торып җибәргән икән, тегесе идәнгә барып төшкән. Монысы — без күрмәгәне. Шуннан китте сугыш, китте кычкырыш. Шулчак Гөлнур, бу хәлгә хурланырга тиешле Гөлнур, булачак ире Рәмис янына йөгереп килеп, бөтен кеше алдында кочаклый-кочаклый үбәргә, үзенең аны ничек яратуы турында сөйләргә кереште. Рәмис аны төртеп кенә җибәрде дә урамга чыгып китте. Бик озак торганнан соң гына әйләнеп керде һәм кәләше янына яңадан килеп утырмады. Туйның яме китте. Бу хәлгә шаккаткан кунаклар берәм-берәм таралыша башлады.

Хезмәттәш кызлары, Гөлнурның Фәйрүзәгә әйткән сүзләрен исләренә төшереп, китәр, тормас мондый ир белән дип уйладылар.

Китмәде Гөлнур. Калды. Гафу итте. Ире кая барса, артыннан ияреп йөри башлады. Тегесе эчте, кулын да уйнатты. Гөлнурны урамда калдырып, барган җирендә сәгатьләр буе торып чыкканнан соң, аны күрмәмешкә салынып китеп барган чаклары да еш булды. Ул һаман артыннан йөрүен дәвам итте. Тора-бара балага узган Гөлнур ире артыннан ияреп йөри алмас булды. Ире ireккә чыкты. Хәтта бала табар вакыты җиткән Гөлнурның берүзен өйдә калдырып, төннәр буе, икешәр көн, атналар буе өенә кайтмады. Гөлнур көтте, елый-елый көтте. Читтә йөргән исерек ире әйләнеп кайткач та, үбә-үбә иркәләде. Гафу итте. Әмма ташлап китмәде.

Бала табар көн җитте. Хастаханәгә илтергә ире юк. Йөри кайдадыр. Күршеләр илтте. Рәмис баласын алырга да килмәде. Бертуган абыйсы барып алды.

Гөлнур янә гафу итте. Ташлап китмәде.

Берничә айлап вакыт узгач, балага да исе китмичә, ире үзе Гөлнурны ташлап китте. Ике балалы бер

хатынга барып керде. Гөлнур анда да гафу итте. Үзе янына анда-санда булса да килгәләп йөргүен үтенде.

Көннәрнең берендә Рәмисне кулга алдылар. Үзе кебек бер төркем ирләр белән кызлар көчләгән өчен шактый вакытка төрмәгә ябып куйдылар. Теге хатын аның янына бармады. Гөлнур тагын гафу итте. Барды ул аның янына. Баласын да алып килде. Шулай йөри торгач, кыз янына малай да алып кайтты. Малай булгач, тормыш рәтләнер дип уйлады Гөлнур. Юк, алай гына рәтләнми икән. Төрмәдән чыккач, Рәмис Гөлнур янына кайтмады. Яңадан теге хатынга — үзе янына төрмәгә бер мәртәбә дә барып карамаган хатынга әйләнеп кайтты. Үз кызы белән малае аңа чит иде. Үстерешергә дә ярдәм итмәде. Аның каравы чит хатынның балаларын караштьы. Шулай булса да, Гөлнур аннан баш тартмады: очраган саен үзенә чакырды, ә тегесе килмәде.

Җәйнең бер матур көнендә кибеттән чыгып барган Фәйрүзә (заводтан китеп күптән икенче эшкә күчкән булса да, кызлар белән гел аралашып торып, барлык хәлләрдән хәбәрдар иде) чүт кенә Гөлнур белән бәрелешмәде. Икесе дә аптырап киттеләр. Гөлнур Фәйрүзәнең хәлләрен сораштырды. Фәйрүзә үзе турында сөйләгәннән соң:

— Гөлнур, синең ирең минекеннән мең мәртәбә начар. Ник ташламыйсың? Шундый була торып ник икенче балаңны таптың? Әле, берсен дә тапмаячакмын, дигән идең бит, — дип, йөзенә бәреп әйтте.

— И Фәйрүзә! Син мине, зинһар, гафу итә күр. Уйламыйча, тормышның ни икәнен белмичә әйтелгән сүзләр булган ул. Бер бәйләнгәч, балаларың да булгач, алай тиз генә китеп булмый икән шул. Бөтен әшәкелеген, җәбер-золымын күрә торып гафу итәсең икән, — диде дә елап җибәрде. — Булмады, рәхәт күрмәдем. Балаларыма ни язгандыр. Алар минем язмышны кабатламасалар гына ярар иде.

Шушы очрашудан соң Гөлнур белән Фәйрүзә шактый вакыт үткәч, тагын берничә мәртәбә күреште. Гөлнур, ниһаять, араны өзгән, балалар үсеп, кайсы кая укырга кергән. Рәмис исә, дөньяда үз урынын таба алмыйча тегендә-монда сугылып йөри торгач, теге хатынга да кирәк булмыйча, аннан да куылып, сукбайга әйләнеп беткән. Соңгы гомерләрен урам чатында хәер сорашып уздырырга язгандыр, күрәсең.

Бу хәлләр минем хәтер сандыгымнан өченче бер вакыйганы тартып чыгарды.

*** * ***

Нәсимә иреннән уңмады. Рәсәйнең бер төбәгеннән укырга килгән зифа буйлы, зур кара күзле, бөрелеп торган иренле гаҗәеп чибәр Нәсимә, үзе артыннан акны-караны күрми, артыннан калмый чапкан матур егетләрне читкә тибәреп, шактый ямьсез Казан егетенә кияүгә чыкты да куйды. Беренчедән, Казанда каласы килде, икенчедән, ямьсез булгач, читкә карамас, мине генә яратып яшәр дип уйлады.

Тик өмете акланмады: Казанда калуын калды, әмма ире Кәрим йөремсәк ир булып чыкты. Нәсимә түзде. Бала булгач туктар әле, диде. Кызлар кебек матур малай алып кайтып бирде иренә. Улы Нәсимәнең үзенә охшаган иде. Сабыйны күргәч, Кәрим баладан бизде. Ул малаеның үзенә охшавын теләгән иде. Улы туган көннәрдә берара азуыннан туктап торган Кәрим — бераздан тугарылды. Яшь бала белән җәфаланган, өстәвенә ир ярдәме дә күрмәгән, ә бәлки, киресенчә, нервыларын ашап, йөрәгенә кан саудырып торганга, Нәсимә нык авырып китте. Ир, озын-озак уйлап тормыйча, тормыш иптәше белән баласын хатынының әниләренә илтте дә куйды: сәламәтләнгәнче шунда торып торыгыз, янәсе. Үзе бернинди контрольсез, иркен тормышка күчте. Берничә айдан соң хатыны сәламәтләнгәч, баласы шактый үскәч, алып кайтты ул аларны. Тик алар юкта күңелгә сеңеп калган гадәт калды. Араларының мондый булуын күреп-белеп торган, гаиләләре белән аралашучы дус хатыны Мөслимә, беркөнне боларга килгәч, үзенең яхшы тормышы белән мактанасы, иренең үзен ничек яратуын күрсәтәсе килептер, кинәт әйтеп куйды:

— И Нәсимә җаным! Бигрәкләр дә интегеп яшисең инде. Әллә аерыласыңмы? Кыяфәте дә юк бит, ичмасам. Бу хатыннар кайсы җиренә карый торгандыр Кәримнең. Менә минем Равилем нинди чибәр булса да, үземнән башка бер генә хатынга да карамый. Әле мин синнән күпкә ямьсезрәк булсам да. Минем өчен үлеп тора. Бөтен теләгемне үти. Улыбызны да ярата, эштән кайтса, алдыннан төшерми. Бергә уйныйлар, йоклатуын да үзе йоклата хәтта, — диде.

Бу сүзләре белән, әллә ни матур булмаса да, чибәр Нәсимәдән күпкә өстенлеген күрсәтәсе килде аның.

Нәсимәнең йөрәге чәнчеп куйды. Шундый тормыш көткән идемени ул?! Ниндидер хатыннан шундый сүзләр ишетергә туганмыни? Шуңа гына лаекмыни? Йөрәге әрнесә дә, тышка күз яшен чыгармады. Ачуыннан эчтән генә уйлап

куйды: Равил әле күзе төшәрлек хатын очратмагандыр. Очратса, син зәхмәткә карап тормас. Ахирәтем Айгөлне күрсәтәм әле мин аңа, күрербез шунда нишләвен.

Озакка сузмый, уен тормышка да ашырды. Туган көне җитеп килә иде — кунаклар чакырырга булды. Мөслимәнең ире Равил Нәсимәнең Кәриме белән бергә эшләгәнлектән, алар беренче чиратта чакырылырга тиешле кунаклар булганга, Нәсимә иң әүвәл аларга хәбәр итте. Тагын берничә пар чакырылганнан соң, ире үлеп ялгыз калгач, моңарчы мәҗлесләргә дәшәргә кыймаса да (ире күз төшермәгәе), бу юлы Нәсимә ахирәте Айгөлне дә чакырды. Һәм алдан ук, бер канәгатьләнү хисе белән, нәтиҗәне көтә башлады.

Туган көн килеп тә җитте. Күршеләрендә генә торган Айгөл, кешеләр килә төшсен дип, бераз соңрак керде. Җәйнең матур бер көне. Ак җирлеккә кара борчаклар төшкән, нечкә билләрен күрсәтеп, гәүдәсенә бик килешеп торган, җиң урынына «канатлар» куелган сарафанын, биек үкчәле матур туфлиен киеп туган көнгә кергәндә, кунаклар җыелышкан, урамда гөр килеп сөйләшеп торалар иде: әйтерсең Айгөлне каршы алырга чыкканнар.

Фәрештәдәй очып килгән Айгөлне күреп, кунаклар сөйләшүдән туктады. Ирләр арасында пөхтәлеге, чибәрлеге белән аерылып торган Равил кинәт Айгөл килгән якка борылып карады. Карады да, сүз әйтергә дип ачкан авызын ябарга да онытып, катып калды. Өй хуҗасы Кәрим, тиз генә аның янына килеп:

— Авызыңны яп, Равил. Дөньяңны онытма. Хатының белән балаңны ал да кереп утыр, — диде.

Читтән генә күзәтеп торган Нәсимәнең күңеле булды: нәтиҗә көткәнчә килеп чыкты. Буласы алда әле дип уйлап куйды ул, бер канәгатьлек белән.

Кунаклар бер-бер артлы өйгә кереп тулдылар. Кәрим белән Нәсимә барысын да урыннарга утыртып чыкты. Кинәт бөтен кешене гаҗәпкә калдырган хәл булды.

Хатыны, баласы белән янәшә утырган Равил сикереп торды да, алар яныннан китеп, башкаларны этә-төртә, Айгөл янына килеп тә утырды. Дөньясын онытып, бөтен кеше алдында Айгөлгә игътибарын күрсәтә башлады.

Айгөл уңайсыз хәлдә калды. Ул Нәсимәнең астыртын уйларын белми иде — күршесе сөйләмәде. Шуңа күрә Равилнең бу кыланышына кеше алдында ничек җавап кайтарырга белми аптырады. Бу кешене ул беренче күрә иде.

— Зинһар, үз урыныгызга утырыгыз. Мине чыгып китәргә мәҗбүр итмәгез, — диде Айгөл Равилгә һәм аның хатынына карап куйды, ник берни дә эшләмисез, янәсе.

Мөслимә, хурлыгыннан аска карап, ни дип әйтергә дә белмичә, кара янып утыра иде.

— Мин сезгә комачауламам. Бары тик сезнең янда гына буласым һәм сезгә теләгән нәрсәгезне биреп торасым килә. Башкасына игътибар итмәгез, — диде Равил, утырган урынында кала биреп. Хатыны янына күчеп утырмады.

Мәҗлес башланып китте. Кәрим, андый-мондый хәл булмасын тагын дигәндәй, Мөслимәне иренең икенче ягына үзе күчереп утыртты. Равил аңа борылып та карамады: әллә бар ул дөньяда, әллә юк. Айгөл торып чыгып китәргә дә уйлаган иде, ни хуҗалар, ни кунаклар рөхсәт итмәделәр. Калса да, тагын ни булыр икән дип, ут йотып утырды. Равилнең сыйлавына, үзеннән күзен дә алмый утыруына игътибар итмәскә тырышты. Мәҗлес дәвам итте.

Кинәт, бу уңайсызлыкны бетерергә теләгәндәй, берәү җырлап җибәрде. Равил үзе белән алып килгән баянын тиз генә алды да аңа кушылып уйный башлады. Өздерә, каһәр! Айгөлгә ярарга тырышкандай, бөтен күңелен биреп уйнады. Җырга Айгөл дә кушылды. Моңлы матур тавышы чишмәдәй агылды. Аның тавышын уздырырлык тавыш юк иде мәҗлестә. Равил моңа шулай ук игътибар итте. Күңеле җилкенде. Баянында уйный-уйный, үзе дә җырга кушылды. Җырлавы да матур икән. Ике матур тавыш мәҗлескә ямь өстәде.

Җыр беткәч, бераз капкалап, хуҗабикә саулыгына күтәреп куйдылар. Кунаклар, бер-берсен күптән белгәнгә, уртак тел, уртак тема табып, кычкырып сөйләшергә, гәпләшергә тотынды. Равил түзмәде, ишек төбенәрәк барып утырды да бию көен уйнап җибәрде. Хуҗа хатын Нәсимә, шуны гына көткәндәй, биеп килде дә Айгөлне чакырды. Айгөлнең аягы идәнгә тимичә матур биегәнен белә иде ул. Чибәрлеген генә түгел, ә бар яктан да булганлыгын күрсәтәсе килде аның Равилгә. Мөслимәгә үпкәсе шулкадәр көчле иде, аның борчылып утыруына да игътибар итмәскә тырышты Нәсимә.

Бу минутларда ул үзе әзерләгән планны тормышка ашыру белән генә мәшгуль иде. Мөслимә иренең дә фәрештә түгеллеген, күңеленә ошаган хатын-кыз күрсә, аның да аңа гына карап тормаячагын исбатларга тырышты. Планы барып та чыкты. Ул да булмады, Равил баянын икенче берәүгә тоттырды да, бию көен дәвам итәргә кушып, биеп килеп, Айгөлне Нәсимәдән аерып та алды, өермәдәй очыртып та китте.

— Кайда булдың син моңарчы? — диде бии-бии, «син»гә күчеп. — Күпме эзләдем бу тормышта

үземә туры килгән тиң хатын. Таба алмадым.

— Ничек таба алмадыгыз? — дип сорады Айгөл. — Ә хатынызгыз?

— Менә шул үзем таба алмаганга, әниләр өйләндергән хатын ул. Торабыз инде, бер өйләнешкәч. Ә минем хыялымдагы хатын — син булып чыктың. Кайда йөрдең моңарчы? Соңрак очраштык. Зыян юк, хатаны кайчан төзәтсәң дә соң түгел, — диде Равил, Айгөлне әйләндерә-әйләндерә.

Шулчак алар янына Кәрим килеп басты да аларны биюдән туктатты.

— Син, Равил, шулай да чаманы бел. Минем өйдә гауга чыга күрмәсен. Әнә хатының кайтып китәм дип җыена. Бар, тынычландыр үзен, — диде.

— Бик яхшы, китсен. Мин аны монда бәйләп куймаган бит. Кайта торсын, — диде Равил. — Кайткач сөйләшербез.

Айгөл дә дәшми калмады.

— Барыгыз, Равил, тынычландырыгыз хатынызгызны. Алай яхшы түгел, чакырыгыз үзен биюгә, югыйсә мин китәм, — дигәч, Равил, җилләнеп, икенче бүлмәгә хатыны янына кереп китте.

Айгөл, аның юклыгыннан файдаланып, китәсен Нәсимәгә әйтте дә өйләренә чыгып чапты. Ул инде үзе дә, эш зурга китәр дип куркып, риза булды, кунаклар киткәч, иртәгә иртән кереп чыгармын, дип калды. Бу кадәресе дә җиткән иде Нәсимәгә. Раслады ул Мөслимәгә барын да, үзе кичергән газапларның бер өлешен булса да татытып каратты, икенчеләй аның мактанырлык рәтен калдырмады.

Эш чынлап та зурга китте. Равил хатынына әйтәсе сүзләрен әйтеп, залга чыкса, Айгөл юк. Кая китте? Өенә китте, дип җавап бирә Нәсимә. Равил Айгөл артыннан чыгып йөгерә. Аның кайда торганын белмәгәнгә, анда йөгереп бара, монда йөгереп килә — тапмый. Яңадан кереп, Кәрим белән Нәсимәдән аның кайда торганын сорый, тегеләр әйтми. Шулай итеп, ул бик күңелсезләнеп, тәмам ачуы чыгып кайтып китә. Иртәгесен Нәсимәләргә янә килә. Айгөлне чакыруларын үтенә.

— Теләсәгез нишләтегез, егетләр! Гомер буе эзләгән мәхәббәтемне таптым. Хатынга борылып карыйсым да килми. Кәрим, син беләсең бит инде минем аны яратып тормаганны. Шуңа күрә икенче баланы да таптырмадым. Чакырыгыз Айгөлне, күреп кенә булса да китим, — ди.

Кәрим белән Нәсимә, бәласеннән башаяк дип, барыбер чакырмыйлар Айгөлне.

Өченче көнне дә, дүртенче көнне дә килә. Атна үтә. Ай үтә.

Бервакыт Айгөл, эштән кайтып ашап-эчкәч, табак-савытларны юарга әзерләнеп йөргәндә, ишектә — звонок. Барып ачса, ишек төбендә, гаепле кеше сыман башын иеп, Кәрим тора. Моңарчы аның бер генә мәртәбә дә үзе генә кергәне булмаганга, Айгөл куркып китте:

— Әстәгъфирулла, тәүбә! Нишләп йөрисең бу вакытта кеше куркытып. Нәсимә авырып китте мәллә?

— Юк, Нәсимәгә берни дә булмады. Исән-сау. Сине бер кеше чакыра иде, үзе керергә уңайсызлана, мине кертте. Әйдә әле, биш кенә минутка чык әле.

Айгөл эшне бик тиз сизеп алды.

— Син нәрсә инде, Кәрим. Беләм мин синең кем янына чакырганыңны. Чыкмыйм да, сөйләшмим дә. Бар чыгып әйт, вакыт уздырып йөрмәсен. Гаилә бозмыйм, баласы яшь.

Катгый итеп әйткәч, Кәрим шундук борылып чыгып китте. Биш минут та үтмәде, ишектә яңадан звонок. Айгөл ишекне ачса, яңадан Кәрим басып тора.

— Айгөл, жәллә инде кешене. Чыгып кара гына, нинди хәлдә икәнен үзең күрерсең. Айлар буе йокламый бит. Ашаудан калды. Ябыкты. Эшендә рәтләп эшли алмый. Чыгып, хет ике генә сүз әйтеп кер. Авырмы сиңа шуны эшләү?

— Чыкмыйм, Кәрим. Ике сүз янына өченчесе өстәлә. Аннары өмет кабына. Ә минем өметләндерәсем килми. Тагын берничә көн газапланыр да бетәр. Барыгыз, китегез, — диде Айгөл.

Кәрим чыгып китте. Ул көнне башка борчымадылар.

Берничә көн үткәч, ишегалдында күршеләр йөреп торганга ишекләрне ачып куеп керләр юып ятканда, Айгөл, баскыч шыгырдавына борылып карарга да өлгермәде, ниндидер ир кешенең кереп килүен чамалап, куркуыннан һуштан язар хәлгә җитте. Кем икәнен танымыйча, кычкырыр өчен авызын ачуы булды, теге ир аны кочагына алып, авызын иреннәре белән каплады, аннан күзләреннән, муеннарыннан үбәргә кереште. Шунда гына аның Равил икәнен танып алды Айгөл. Бу назлаудан айнып китеп, Равилне этеп җибәрде.

— Тукта, Равил, тынычлан, — диде Айгөл. — Ник килдең? Мин бит сиңа әйттем сүзләремне. Сиңа тапшырмадыларммыни?

— Тапшырдылар. Тик мин аңа риза түгел. Син бер күрүдә гашыйк булу дигән нәрсәне беләсеңдер. Менә мин шул хәлдә. Минем моңарчы болай яратканым булмады. Синең беренче һәм соңгысы булуыңны телим. Чык миңа кияүгә. Без бер-беребезгә бөтен яктан да туры килгән парлар. Бөтен яктан да. Чык, зинһар! Йөрәгем тулы яра. Төзәт яраларымны, — дип, Айгөлнең аякларын кочып елады.

— Юк, болай булмый, Равил. Әйдә утыр. Аңлашыйк. Әүвәл шуны бел: минем үз өстемә, гаилә таркатучы, сабыйны ятим итүче дигән исемне дә, аның гөнаһысын да аласым килми. Аннары, кияүгә чыгар өчен син миңа туры килеп тә бетмисең. Эшеңне яратмыйм мин синең. Без икебез ике дөнья кешесе. Ә яраларыңны вакыт төзәтер, — диде Айгөл.

— Төзәлерлек булса, төзәлгән булыр иде инде шушы вакыт эчендә. Мәхәббәтемне син кабул итмәгәч, хисләремне бастырырга, үземә-үзем боерык биреп, онытырга тырышып карадым. Алай гына булмый икән. Күр мине, беренче очрашканда мин шундый идемме? Кибеп үләм бит инде.

Айгөл аның суырылган йөзенә, күз төпләренә яткан кара шәүләләргә һәм сөю ташып торган күзләренә карады. Бер уйлаганда, жәл иде Равил. Кешегә чын мәхәббәт, үлеп ярату гомерендә бер генә килергә мөмкин. Бәлки, Равилнең дә шундый саф мәхәббәттер. Башка гашыйк та була алмас, бәлки. Ә мин аның бу хисләрен үтерергә тиеш, дип уйлап алды Айгөл. Әмма бүтән чарасы юк иде. Бала яшь. Бала, җитмәсә, ир бала әтисез кала. Юк, бара алмый бу адымга Айгөл.

— Эшне алыштырырга була анысы. Ул проблема түгел. Юкны сылтау итмә, зинһар. Бала шулай ук комачау түгел, үзебезнекеләр белән бергә үстерешербез. Мин аны ташлыйм димим бит.

— Куй, Равил. Сөйләшмик бүтән бу турыда. Хатыныңны белмәсәм бер хәл иде. Белгән кешенең ирен тартып ала алмыйм бит инде. Юк-юк, тагын бер мәртәбә юк. Бар да үтә торган. Колак сал сүзләремә. Минем сүзләр үтәрлек булмаса, яклаучыларым аңлатып бирерләр. Сөюең чын булса, зинһар, мәҗбүр итмә мәхәббәтеңә усаллык белән кайтарырга. Әйдә, ачуланышмыйча гына ноктаны шунда куйыйк. Тынычлан, бар кайт. Башка килеп йөрмә. Бу минем катгый сүзем, — диде Айгөл.

— Бәгырьсез икәнсең. Күрәләтә мине бәхетсез итәсең. Хуш! Моннан соң сине борчымам. Ничек тә түзәргә тырышырмын, — дип ярсып чыгып китте Равил.

Әле шуннан соң да берничә мәртәбә килде. Җитмәсә, очраклы рәвештә, бәлки, очраклы да булмагандыр, урамда да очраштылар. Тик сүз дусларча хәл-әхвәл белешүдән, бер-берләренә саулык, бәхет теләүдән ары узмады. Хәзергесе ничектер, ул чакта гаилә шулай сакланып калды. Әмма Равил күңеленә Айгөл озак елларга сузылган тирән яра салып калдырды. Җавапсыз мәхәббәт ярасы.

* * *

Бу өч язмыш бер-берләренә әллә ни охшамасалар да, аларны бәйләп торучы уртак яклары да җитәрлек. Гыйбрәт өчен дип, сүзләрне үлчәп сөйләргә, кыласы гамәлләреңне мөмкин булган кадәр алдан бәяләргә өйрәтүче бер мисал булсын дип, аларның өчесен дә сезгә җиткерергә булдым, хөрмәтле укучыларым!

*1995—2000*

## Килделәр

Бу араларда кая карама НЛО, ут чәчеп торган «тәлинкәләр», әле озын, әле кыска буйлы «кунаклар», аларның ялтыравыклы киемнәре, кеше урлап китүләре турында шактый еш яза башладылар. Демократия булгач рәхәтләнәләр. Ә элегрәк ни карап торганнар икән «тегеләр». Әллә алар да Горбачев заманын көттеләр микән? Мөгаен, шулайдыр, Сталин белән Брежнев заманында теләсә нәрсә сөйләп иркенләп йөреп кара Союз буйлап. Йөрсәң, бер көн йөрерсең, икенче көнне инде тимер рәшәткәле тәрәзәдән карап торырсың. Ә хәзер... Әле өй түбәсенә, әле шәһәр эчендәге паркка, әле юл кырыена «тәлинкәләр» рәхәтләнеп төшеп утыралар да үзләренә ошаган җир кешесен, иреннән, хатыныннан да рөхсәт сорап тормыйча, алып та китәләр.

Мин дә укыйм бу хәлләр турында. Кызыксындыра бит. Әле бик тә кызыклыларын, тәрҗемә итеп, газетага да биреп барам. Менә бит дөньяда нинди хәлләр бар, башкалар да белсен, янәсе.

Укый торгач, яза торгач, минем башка да әллә нинди уйлар керә башлады: «тәлинкәләр» Татарстан җиренә ник төшмиләр икән? Әллә бездә аларга ияреп китәрлек кеше юкмы? Ә, оныткаңмын икән. Килделәр бит Татарстанга. Валлаһи, килделәр. Үз күзләрем белән күрдем. Кайчан, дисезме? 1991 елның август аенда. Мин ул чакта Чистай районының Яуширмә авылында ялда идем. Кичкә таба безгә, хәл белергә дип, кызы белән Наилә апа килеп керде. Шул, чәйләр эчеп сөйләшкәч, мин аларны озата киттем. Сәгать кичке тугызлар тирәсе. Күпердән чыгып, тауга күтәрелә башлаган гына идек, Наилә апа: «Карале, ай ник монда тора икән? Җитмәсә, яшел», — ди. Ул күрсәткән якка карасам, чынлап та, көньякта, офыктан бераз өстәрәк янып торган йолдыз янында ниндидер ай яшелләнеп тора. Бәлеш, бу ай ник мондый төскә кергән дип әйтергә дә

өлгермәдем, чын аебыз гел икенче якта көлеп тормасынмы? Ул да булмады, яшел айның ике ягына аннан кечерәк берәр яңа ай кызарып килеп чыкты. Без авызыбызны ачып шаккатып карап торган арада, бу айлар да яшелләнә башлап, инде аларның янына, ярымтүгәрәк ясап, тагын берәр ай кызарып чыкты. Алар боларыннан да кечерәк иде. Урамда кеше аз: яшьләр клубка китеп беткән, олылар йокларга җыена. Бу галәмәтне күрсәтер кеше юк. Берәүне күреп, ни икән бу, дип киңәшләшә башлаган идек, анысы да сәрхуш булып, фикер алышырга ярамады. Дөрес: «Хәзер матайны кабызам да менеп төшәм. Төшкәч әйтермен», — диде диюен. Шуннан ни булыр икән дип, күзәтә башладык без биш «чит айны». Күпме вакыт узгандыр, калганнары да яшелләнә башлап, тоныклана төштеләр. Бераздан, гел тоныгаеп, әкрен-әкрен күздән дә югалдылар. Бу күренеш безне нык тәэсирләндерсә дә, бу турыда бераз сөйләшеп алгач, тормыш темасына күчеп, моңа кабат әйләнеп кайтмадык. Мин бу турыда хәрби очучы энемә, су асты көймәсе офицеры абыема сөйләп күрсәттем күрсәтүен, алар үзләренең профессиональ күзлекләреннән чыгып нидер аңлаттылар да, шуның белән вәссәлам.

Мин «аларның» ул чакта ник килгәннәрен әле яңа аңладым. Ул вакытта алар мине күзләргә: кайда, нишләп, кем белән йөри дип тикшерергә килгән булганнар икән. Ә менә өченчекөн үзләре белән алып китәргә дип килеп җиткәннәр. Чынлап әгәр. Әйткәнемчә, алар турында укый-яза торгач, минем арттан да килми калмаслар болар дип көтеп йөри башлаган идем инде үзем дә. Инде ничә көн йокларга ятуым була, бүлмәмдә ялт-йолт, ялт-йолт нәрсәнеңдер ялтырап йөрүен хәтта ябык күзләр белән күреп ятам. Эх, майтәм, болар минем уянганны көтеп йөри инде. Шулай да күзләрне ачмыйм. Бераз куркам да, ачсаң, алар белән бәйләнешкә керергә кирәк бит. Күзләр белән очрашкач, сөйләшми яхшы түгел бит инде. Ярый, бер төн яттым шулай, ике төн. «Тегеләр» йөри бит һаман ялтырап, сизәм бит инде мин моны. Шулай да йоклаган кешене уятырга кыймыйлар икән, искиткеч тәрбиялеләрдер. Ә өченче төндә түзмәдем, булмый, майтәм, болай белмәмешкә салынып ятып, үпкәләп китмәсеннәр тагын. Ачтым күзләрне.

— И-и, кунаклар бар икән, хуш килдегез! — дигән булам.

«Тегеләр» дә миңа җавабында:

— Рәхмәт, рәхмәт, бик күркәм яшисең икән, — дигән булдылар.

Бераз бер-беребезгә карашып, елмаешып торгач, «тегеләр»:

— Без сине теге юлы ук ошатып калган идек, ә хәзер үзебез белән алып китәргә дип килдек. Син моңа ничек карыйсың? — димәсеннәрме.

Билгеле инде, акаеп-акаеп карыйм, дип әйтә алмадым, миндә дә тәрбия дигән нәрсә бар бит әле, Җирнеке булсам да, төшеп калганнардан түгел. Үзем уйлыйм, нишлим икән, риза булсам, мәңгегә алып китәләр инде болар, әйләнеп кайтырмын димә. Инде берәм-берәм укыган-язганнарымны искә төшерә башладым: кем ничек җавап биргән дә кем ничек котылып калган. Тик торганнан гына китәсе килми бит әле. Бала бар, тормыш бар дигәндәй.

— Ни бит әле, — мин әйтәм, — кинәт кенә китеп булмый бит әле. Бердән, эш күп, икенчедән, бу дөньядан бер дә китәсе килми. Сез унбиш-егерме еллардан соң килсәгез, сөйләшеп карарбыз, — дигән булам.

— Син нәрсә, егерме елдан соң булырга мөмкин. Ахырзаманга кадәр китеп калсаң каласың. Кабат-кабат килеп йөреп булмас. Безнең дә эш муеннан. Болай да, синең уянганыңны көтеп, өч төн вакытыбызны әрәм иттек. Без теләсә кемне чакырмыйбыз. Хәл ит, үкенмәссең, — диделәр.

— Ярый, — майтәм, — башта барып карап кайтыйм инде алайса, ошатсам, бөтенләйгә күчәрмен. Тик иртән эшкә киткәнче әйләнеп кайтыйк. Эштә, кайда йөри бу дип, битәрләрлек булмасын.

Риза булдылар тагын, рәхмәт төшкерләре. Алып киттеләр мине, «тәлинкәләренә» утыртып. Әй очабыз, мин сиңайтим, әй очабыз. Рәхәтлекләре! Селкетми дә, тавышын да ишетмисең. Үзебезнең самолетларга да утырган бар минем: бердән, гүләп тилмертә, икенчедән, колак тонып бетә. Юк инде, янәшә куярлык түгел инде.

Ярый, «әһ» дигәнче барып та җиттек без «боларга». И-и, анда бездән күчкән халык бик күп, җәмәгать. Бер дә куркып торасы түгел икән. Җирдән килгән кешене бик хөрмәтләп каршы алалар икән.

Мин аягымны «тәлинкәдән» төшә торган баскычка куярга да өлгермәдем, Җир кешеләре мине сырып та алдылар. Әй сораштыралар, әй сораштыралар. Андагы тормыш бик әйбәт булса да, сагыналар икән. Белгән кадәр сөйләдем инде, бераз күңелләре булды. Кайтыгыз соң болай сагынгач, дигән булам. Юк, кайтасылары килми үзләренең.

Мине алып китүчеләр һәрнәрсә белән таныштырып йөрделәр. Чынлап та, күчеп килсәң, үкенерлек түгел икән. Бу турыда, вакытыгызны алып, тәфсилләп язып тормыйм инде, яза китсәң, китап булыр. Китапка вакыт та, акча да күп кирәк. «Тегеләр» үз сүзләрендә тордылар тагын, эш башланганчы өйгә китереп куйдылар. Тиз генә җыендым да эшкә киттем. Кәеф юк, йокы туймаган, башта уй. Нишләргә? Төрле уйлар башны бораулый. Җитмәсә, эштәгеләр дә: «Нәрсә боектың, нигә сөйләшмисең, нигә кәефең китте?» — дип теңкәгә тияләр. Нинди кәеф булсын инде монда. Сөйләп бирер идең, ышанмыйча, көлкегә калдырырлар дип шикләнәм. Көлкегә генә калдырсалар ярый ла, «сары йортка» илтеп тыкмасалар. Менә сезгә чишелергә булдым әле, сез ни диярсез тагын?

*1995*

## Менә сиңа хикмәт!

Беркөн шулай әнидән «кунаклар җыям, тегесен-монысын алып кайт, бераз булышырсың да» дигән хат килгәч, ул сораган әйберләрне алдым да авылга кайтып киттем. Ярый әле тиз генә машинасы туры килде: иртәнге тугызларда өйдә идем инде. Өйдә дигәннән шуны әйтергә кирәк: безнең өйдә күптән кеше тормый. Әти үлгәч әнинең чыгып киткәненә, кече кызында яшәвенә дә байтак. Шулай да әни, елга бер кайтып, Коръән укытып китә. Үзенең күңелен, өйне явыз рухлардан чистарта, әти рухына дога кылдыра.

Кайту белән җиң сызганып эшкә керештем: идәннәрне юып чыгардым, тузаннарны сөрттем, әйберләрне әзерләп куйдым, әзер ризыкларны өстәлгә тезеп чыктым. Карыйм: тәлинкә-чынаяклар, кашыклар җитми.

— Әни, кайда безнең тәлинкәләр? — дим. — Кашыклар да җитми икән.

— Җитми шул, кызым, — диде әни. — Инде гел монда тормагач, бераз гына, үзебезгә кирәк кадәрен генә калдырып таратып бетергән идем шул. Күршеләргә кереп чыгарга туры килер инде.

— Ярар, әни, мин, алайса, бу эшемне бетерим дә, Хәлимә апаларга кереп чыгармын. Әллә ни күп кирәк түгел, биреп торыр әле, — дидем.

Бераздан, кунаклар килә башлаганчы дип, ни кирәген яздым да күршеләргә керим дип болдырга чыгып бастым. Кинәт көн караңгыланып китте. Күккә карасам, шактый зур бер болыт безгә таба килә. Курка калдым: нинди болыт микән бу кояшлы көндә? Җил чыгып, болытның килү тизлеген арттырды. Күз ачып йомганчы килеп җитте бу, йорт өстендә асылынып калды. Котны алып, түбән төшә башлады. Паралич суккан кебек селкенә дә алмый торам: ни өйгә кереп китә алмыйм, ни урамга чыгып йөгерә алмыйм. Нишләргә? Әнине чакырып, аны куркытасым килми. Олы кеше, куркудан ни булмас. Әле, үзе чыкмаса ярар иде, дип, Аллаһыдан сорыйм. Ул да булмады, болыт бераз янтайды да аның өстеннән, шалдыр-шолдыр, чалтыр-чолтыр килеп, кашык-чәнечкеләр, тәлинкә-чынаяклар коела башлады. Бар да коелып беткәч, болытым аякланды да (кыска гына йонлач аяклар үсеп чыкты), койманы атлап чыгып (койма аша чыкканда аяклары озынайды), бакча аша китеп тә барды. Тиздән бөтенләй юкка чыкты. Тагын «тегеләр» эшедер инде, мәйтәм. Кешегә кереп йөрмәсеннәр интегеп, дигәннәрдер инде. Авызымны ачып, телсез калып, бер өем савыт-сабага карап торганда, ишектә әни күренде.

— Нишләп торасың инде катып, бар тизрәк, кеше килер вакыт җитте бит, ә син һаман кермәгән, — диде.

Кинәт җирдә өелеп яткан тәлинкә-чынаякларга күзе төште.

— И Ходаем, бетергәнсең икән кеше әйберен, ничек төшереп җибәрдең соң, ныгытып тота алмадыңмыни? Кулларың кайда иде? И Раббым, ничек түләрбез, — дип, мине битәрли башлады.

— Туктале, әни, — мәйтәм, — Хәлимә апаныкы түгел болар. Зур гына болыт китереп китте менә. Җыеп алырга гына кирәк, ватылып бетмәгән булса, — дидем дә тәлинкә-чынаякларны җыя башладым.

Инде әни телсез калды. Аңына килгәч:

— Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла! Тәүбә, тәүбә! — дип төкеренеп, өйгә кереп китте.

Вәт Ходайның рәхмәте: чалтыр-чолтыр килеп төшкән тәлинкә-чынаякларның ник берсе ватылсын, чатнаган җире дә юк хәтта. Тиз генә җыеп алдым да өйгә алып кереп киттем. Шушы тәлинкәләр, чынаяклар, кашыклар белән кунакларны сыйлап җибәрдек. Килгән кунаклар: «Мондый матур чынаякларны буш өйдә ничек калдырып йөрисез, курыкмыйча», — дип борчылды да әле.

Болыт китергәннәрнең барысы да бездә калды. Килеп сораучы да, алып китүче дә булмады.

Менә сиңа хикмәт!

Берничә көннән урамга чыксам, безгә табан тагын болыт килә. Монысы караеп, дулап, чатыр-чотыр яшен яшьнәтеп, дөбер-шатыр китереп, дөньяны каплап килә. Куркудан верандага йөгереп кердем. Тәрәзәдән күзәтәм тегене. Аһ, мин әйтәм, монысы нинди болыт инде тагын? Шул ук болыт әйләнә дә киләме? Бөтен нәрсәне җимереп китә икән бу. Өй чыдавын чыдар, әмма түбә калайлары очар инде, агачларны да суырып алып әллә кая илтеп ташлар, дим.

Килеп җитте болыт аждаһадай: дулапмы-дулады, утларын тирә-якка чәчте, яңгырын да чиләкләп койды һәм кинәт бөтен дөнья тынып калды. Әйтерсең лә берни булмаган. Мин, бу хәлгә аптырап, болдырга чыктым. Бәрәч, давыл булмадымыни, яңгыр яумадымыни, дип шаккатып торам: бар нәрсә үз урынында, бөтен җир коп-коры. Күтәрелеп, күккә карадым. Куркып киттем: зәп-зәңгәр күк йөзендә,

озынча түгәрәк эчендә ир кеше портреты. Сөбханалла, мәйтәм, бу кешене Аллаһы Тәгалә миңа тәгаенли микән әллә, дим. Ник аны миңа күрсәтә икән дип уйлап куюым булды, портрет юкка чыкты. Күккә кулымны сузып ялварам: «Тукта әле, тукта, Ходам, мин бит аны рәтләп карап өлгермәдем, исемдә калмады», — дим. Тикмәгә генә күрсәтмидер, бер-бер сере бардыр дип уйлыйм бит инде. Шулай диюем булды, портрет яңадан килеп чыкты. Бу юлы җентекләп карадым. Шуңа күрә әле бүген дә күз алдымда тора: кара чәчле, кара сакал-мыеклы, озынчарак йөзле урта яшьләрдәге чибәр генә ир-егет. Шактый эленеп торганнан соң, кинәт кенә яңадан юкка чыкты. Кабат күренмәде. Кем булды инде бу? Нинди уй-ният белән күрсәтелде, белмим. Бәлки, «тегендә» киткәч очрашырга тиешле агенттыр. Анда да бит разведка булырга тиеш. Шымчылардан башка дөнья барамыни? Монысы да дөнья, «тегесе» дә дөнья бит аның. Юкка гына «теге дөньяда» дип сөйләшми кеше.

Менә сиңа хикмәт!

Икенче бервакыт (монысы Казанда) кич белән, саф һава сулап керим дип, йоклар алдыннан урамга чыктым, каршыма ике яшь кыз килә. Үзләре матурлар, ягымлылар, үзләре таныш та кебек. Исәнләштеләр болар минем белән.

— Апа, — ди берсе, — без сезне алырга бара идек. Менә өр-яңа милли җырларыбызны өйрәнмәкче идек тә, көйләрен белеп бетермибез. Безгә ярдәм итмәссез микән? Сез белмәгән җыр юк бит.

— Ник ярдәм итмәскә, итәм, — дим. Гозерләп сорап торганда, бигрәк тә милли җырларыбызны белергә теләкләре булганда, ничек ярдәм итмисең ди. Хәзерге яшьләр арасында андыйлар әллә ни күп түгел. Киттек. Күрше йортта гына торалар икән. Килеп керсәк, шундый якты бер бүлмә, шундый матур җиһазлар — бар да җем-җем килеп тора. Яшь кенә татар кызлары җыелып җыр өйрәнеп утыралар. Араларында гармунчы да бар. Мин боларга «Сөюемне аңлар идең», «Туган көн», «Аерылмагыз» һәм башка матур җырларны өйрәттем. Кайберләренең көен генә түгел, сүзләрен дә белмиләр икән. Бөтенесен үзем дә белеп бетермәгәнгә, иртән эшкә барышлый кертеп чыгармын, дип кайтып киттем. Кызлар рәхмәт әйтеп озатып куйдылар. Ярар, иртүк торып яздым мин бу җырларның сүзләрен. Эшкә барышлый сугылсам, ишекне бөкрәеп беткән бер карчык ачты.

— Әби, — мәйтәм, — кичә мин сезнең кызларга җыр сүзләре язып кертермен дип вәгъдә биргән идем. Менә шул кәгазьләрне генә аларга бирерсез әле, — дим.

Әбием аптырап миңа карап тора.

— Нинди кызлар, нинди җыр? — диде карчык. — Монда кызларның булганы да юк. Үз балабыз да юк безнең. Гомер-гомергә бабаң белән икәү генә торабыз. Ышанмасаң, әйдә кереп кара.

Кердем әбигә ияреп. Менә мин кичә булган бүлмә. Ул да кебек, түгел дә кебек, чөнки кичәге күк җем-җем килеп торган җиһазлар юкка чыккан. Шуңа бүлмәсе дә караңгырак.

— Балам, квартир нумерын оныткансыңдыр, ялгыш кергәнсеңдер, — диде карчык.

— Бәй, ничек ялгышыйм ди. Кая кергәнемне беләм ич мин. Әле онытмыйм дип, квартир номерын кат-кат карадым, 40 нчы номер иде. Безгә каршы йорт. Сезнең йорт яныннан ничә дистә ел йөрим бит. Шул инде, бүлмәнең ишеге дә шул, люстра да шул, — дим. Гафу үтендем дә чыгып киттем инде. Үзләре кереп чыкмасмы дип, берничә көн көтсәм дә, керүче булмады.

Менә сиңа хикмәт!

«Тегендәгеләр» белән күптән түгел генә кабат очраштым мин. Һаман шул Күккә, Айга, Кояшка карап йөргәнгәдер инде. Йолдызнамә буенча да һава кешесе бит мин. Шуңа якын итәләрдер, бәлки.

Урысларның ниндидер бәйрәме иде. Тагын чыктым һава суларга. Матур кич. Бу юлы үзем генә түгел, янымда берничә туган-тумача да бар. Бездән башка да кеше күп иде — бәйрәм бит. Чыгып басуыбыз булды, күк йөзендәге матурлыкны күреп, хәйран вә вәйран калдык. Күз алдына китерегез: зәп-зәңгәр күк йөзе, андагы йолдызларның исәбе-хисабы юк, бар да балкып яна, әйе-әйе, балкып яна, җемелдәп кенә тормый. Шулар арасыннан Киек Каз Юлы кебек юл үтә, бормаланып-бормаланып. Ул юлның нинди матур икәнен күрсәгез иде сез: юлны тутырган һәр «тузан бөртеге», җем-җем килеп, юлны аккан суга охшатып, тирбәлеп-тирбәлеп ага. Шунысы кызык, ул юл безгә таба агып төшә. Гаҗәеп матур күренеш! Аны аңлатып булмый, үзеңә күрергә кирәк. Күп тә үтмәде, зәңгәр күк йөзендә ап-ак тап пәйда булды. Ул, зурая барып, билгеле бер үлчәмгә җитте һәм аннан үтә дә нәфис озын бармаклы гаҗәеп матур кул күренде. Бер караганда, хатын-кыз кулына охшаган иде. Барыбыз да куркышып калдык. Кинәт бу кул безгә таба озаеп килә башлады. Без, өнебез алынып, өйләребезгә таба йөгердек. Әмма кереп өлгерә алмадык. Шул вакыт әлеге кул минем аркама килеп кагылмасынмы. Мин котым алынудан туктап калдым. Тын алырга да куркам. Нишләтә инде хәзер бу мине, дип көтә башладым. Кул исә, җылы кофтам астыннан үтеп, ялангач тәнемә кагылды. Аркамны сыйпап шуышып менүен бөтен тәнем белән тойдым.

Беттем, мине күктәге теге тишеккә суырып ала икән бу, дип уйлап куйдым. Котым очты дип әйтү

генә аз монда. Шул куркудан, шул тойгыдан бермәл аңга килә алмый тордым. Кулның шуышып кергәне, аркамны сыйпаганы әле дә булса тоела. Нәрсә икән инде бу?

Менә сиңа хикмәт!

*1994*

# Эчтәлек

**Тамырлар**


Тамырлар ................................
Тукай язмышы .............................
Җәлил .................................
Пәйгамбәрләр кебек... .........................
Яшә, халкым! ..............................
Башланмасын иде набаттан ......................
Көзге урман ...............................
Вәхшилек ................................
Этләр ..................................
Сандугачлар мине юата .........................
Саба юлы ................................
«Дөнья матур, дөнья киң...» ......................
Син сәфәргә янә җыенасың .......................
Үтә гомер ................................
Фатыйх Нурлатының икмәге ......................
Юллар буйлап китте тик үйлар ....................
Әни ..................................
И әнием! ................................
Саулармы сез, газиз милләттәшләр! .................
Ирхан белән Җәмилә ..........................
Бала зары ...............................
Фин җирендә кабат җырлый Хәйдәр ................
Исеңдәме? ...............................
Гаҗәп якын идең... ...........................
Дуслар булып калыйк гомергә .....................
Ике Аккош ...............................
Исеңнән чыгарма берүк .........................
Якташым ................................
Сигез дистәң тулган көннәрдә .....................
Күңелеңдә ярату белән наздыр .....................
Син миңа сөю телисең ..........................
Кабат язлар җитте ............................
Җырлап җибәр .............................
Нурлар .................................
Миләш белән Нарат мәхәббәте .....................
Меңнәр йөрәгенә сыйгансыз ......................
Асия ..................................
Борчыма ................................
Хуш, көллият! .............................
Вәгъдәләрең шампан күбегедәй ....................
Салырбыз тик яралар ..........................
Бу ни җанвар? .............................
Янымда йөри зур бәхет .........................
Җырларга күчкән идем... .......................
Китәбезме? ...............................
Хәзер син бөтенләй башка .......................
Ай өстендә күрәм йөзеңне .......................

Акыллы Патшаның зирәк уллары ...................


**Шәрык поэзиясе үрнәгендә**


Робагыйлар ..............................
Газәлләр ................................
Мөсәмманнәр .............................
Мөстәзадлар ..............................
Мөхәммәсләр .............................

Мөрәббәгъләр .............................
Тәрәҗҗибәнд .............................
Кыйтгалар ...............................
Мөсәддәс ................................
Мөсәббә .................................

**Ялгышлардан торган язмышлар**

Сагыш үрләде йөрәккә *(Эссе)* ....................
Ана табан асты — оҗмах, диләр *(Парча)* ..............

**Хикәяләр**

Югалган алтыннар ..........................
Яшь бабай ...............................
Упкын .................................
Үкенү .................................
Соңгы хәбәр ..............................
Мәхәббәт фаҗигасе ..........................
Фатыйма үче ..............................
Яшьлек хатасы ............................
Ташландык ..............................
Сагынуларым биниһая... ......................
Килеп тезләнәселәре алда әле ....................
Булачак кәләшемне төштә күрдем ..................
Яшь чак — кайнар чак ........................
Мине генә ярата, димә икән ......................
Килделәр ................................
Менә сиңа хикмәт! ...........................

Литературно-художественное издание

***Тарханова*** *Флёра Габдрахмановна*

Судьба

Казань. Татарское книжное издательство. 2007
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Тарханова*** *Флёра Габдрахман кызы*

Язмышлар язылганда

Мөхәррире *Р.В.Сабирҗанов*
Рәссамы *А.Р.Хисмәтова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 25.05.2007.
Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 12,60.
Шартлы буяу-оттиск 13,02. Нәшер-хисап табагы 11,25.
Тиражы 2000 д. Заказ С-528.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420059. Казан, Оренбург тракты урамы, 20 а.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.